ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘРҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№ 3 (339)
МАРТ 2020

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

РУШАН СӘЙРАНОВ: «ҺӘР МАКСАТКА ЧАРА БАР»

4 612750 670011

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары: Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Олеся Бондаревская, Ольга Туманская, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Мөршидә Кыямова, Илшат Фәйзрахманов
Фотографлар: Александр Ефремов, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: Кайбыч районы Кошман авылы фермеры Рушан Сәйранов. Чулпан Гарифуллина фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
1 150 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-638
Басарга кул куелды: 27.03.2020
Басмадан чыкты: 31.03.2020

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе: Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе: Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru тел.: (843) 222-09-79

Коммерция директоры: Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга. Гомуми тираж: 3500 данә.

Реклама 16+

Бухгалтерия: Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ТАССР

МАЯКОВСКИЙ ЯРДӘМЕ БЕЛӘН!

Маяковский Казанда өч тапкыр булган. 1914 елда футуристлар сәфәре белән. 1927 елда – Союз шәһәрләре буйлап лекцияләр укып йөргәндә, ә 1928 елның 28 февралендә революция шагыйре Казан университеты студентлары алдында чыгыш ясаган. Казанга сәфәрләренең нәтиҗәсе булып «Казань», "Три тысячи и три сестры», «По городам Союза» шигырьләре калган.

Казанга һәм аның халкына багышлап җырлаган мәдхияләргә караганда, Маяковский шәһәрне ошаткан. Шагыйрь үзе язганча, ул бигрәк тә «татарның чисталыгы-пөхтәлеге»нә сокланган. Чөнки Владимир Маяковский үзе дә чисталыкны яраткан, хәтта ки җирәнүчәнрәк тә кеше булган: һәрвакыт үзе белән сабын һәм сөлге йөрткән, ә инде кул юу мөмкинлеге юк икән, кесәсендә одеколон һәм йод булган.

1929 елда Медицина әдәбияты дәүләт нәшрияты реклама плакатлары ясату буенча Маяковскийга мөрәҗәгать итә, ул шунда ук 35 текст язып бирә. Лебедев рәсемнәре белән 12 текст «Шәхси гигиена» дигән исем астында аерым серия булып басылып чыга.

Кадерле дуслар, безнең редакция әлеге агитацион киңәшләрнең беркайчан булмаганча нәкъ менә бүген – бөтен дөнья коронавирус белән көрәшкәндә актуаль булуына тамчы да шикләнми.

Вирусны һичшиксез җиңәчәкбез, дип ышанабыз. Без көрәшкәндә, тормыш дәвам итә. Шуңа да безнең яңа санны укыгыз, анда төрледән-төрле темаларга язмалар табарсыз. Киләчәккә өметләнеп кенә калмыйча, аны бүген үз куллары белән булдыручы яшь фермерлар кәефегезне күтәрер. Биредә без күренекле якташыбыз, композитор Җәүдәт Фәйзине искә алырбыз. Аның турында укып, ихтимал, композиторның «Башмагым» музыкаль комедиясен яңадан ишетәсегез килер. Онлайнда гына булса да, әлеге классик әсәр кәефегезне күтәрәчәгенә иманыбыз камил. Безнең даими рубрикада тарихыбыз турында укып уйланырсыз. Ә укып уйлангач, тирәюнебездәге кешеләрне яхшы кәеф белән рухландыру һәм кулларны ешрак юу – иң мөһиме, дип уйлыйбыз. Бу чаралар бүген генә түгел, һәрвакытта да кирәкле һәм файдалы гамәлләр.

Укыгыз һәм сәламәт булыгыз!

СЕЗНЕҢ ЧИСТАЛЫК СӨЮЧЕ РЕДАКЦИЯ

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фарит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъсум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **933 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 100 ЯШЬ

WWW.PROTATARSTAN.RU



КОСМОНАВТ ЧЕРНУШКА

1961 елның мартында Чернушка кушаматлы эт, галәм гизеп, ТАССРның Зәй районы Иске Тәкмәк авылы янына төшеп утыра. Бу кешене беренче мәртәбә гамәлгә очыру алдыннан генераль репетиция була. Барлык исәпләүләр буенча Чернушка Самара өлкәсенә төшәргә тиеш була, ләкин нәрсәдер килеп чыкмый. Әмма исәпләүләрдәге әлеге хилафлык аркасында Иске Тәкмәк авылы дан казана, ә Чернушкага бүген Зәйнең төп мәйданын ямьләп торган һәйкәл куела.

© «Татарстан» журналы

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Пандемиягә каршы тору чарасы буларак блокчейн-чишелешләр
Цифрлы икътисад авыр минутларда ничек булыша ала

8. Дөньяга күзләрне ачып...
Татарстанда офтальмология проблемалары ничек хәл ителә

10. Грантлар программасы
«Акча күктән төшми»

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

14. Әбиләребез ничек үзгәрә
«Татарстан» журналыннан «матурлык десанты»

22. «Ел хатын-кызы» бәйгесе
Уңышка рухландыручы гүзәлләр

26. Кече Ватан патриотлары
Җәүдәт Фәйзи пианиносы кайда тора

32. Җиңүнең 75 еллыгын каршылап
Окопчы кыз

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

10. Казан. Параллель дөньялар
Башкалабыз 80 нче елларда ничек яшәгән

14. Соңгы каһарман
Герой «Йолдыз»ын әфганчы ни өчен 25 елдан соң гына ала

18. Ирекле сәяси тоткын
Чистайда утырган совет диссиденты кайчан азат ителә

22. Су буенда учак яна...
Хәтер буенча фотосәяхәт

28. Хыял корабы
Камал театры Кабан ярына ничек «йөзеп» килә

34. Фатирга алыштырырлык техника
Клиентлар видеосалон хуҗаларына нинди табышлар китерә

38. 80 нче еллар афишасы
Ни өчен казанлылар кинотеатрга иртәнге биштә йөриләр

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

21.03

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты, – ТР Хөкүмәт Йортында үткән республика киңәшмәсендә:

– Агымдагы санитар-эпидемиологик вазгыятькә карамастан, дәүләт хакимияте органнарының барысы да гадәти режимда эшләргә тиеш. Гражданин теге яки бу ведомствога мөрәҗәгать итә алмый калырлык булмасын.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

16.03

Дамир Фәттахов, Татарстанның яшьләр эшләре министры, – балаларның сәламәтләндерү лагерьларында үткәрелгән күчмә киңәшмәдә:

– Быел без берьюлы 35 объект төзибез һәм ремонтлыйбыз (сәламәтләндерү лагерьлары – ред. иск.). Эш күләме зур, әмма без бу эш конвейерга куелырга тиеш түгел, лагерьлар барысы да бер типта булмаячак. Без һәр урынның үзенчәлегенә, фәлсәфәсенә ярашлы уникаль проектлар эшлибез.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

07.03

Патрик Йосвиг, немец актеры, – Тимур Бекмамбетовның «Җәһәннәмнән качу» фильмын төшергәндә:

– Әлеге кинода төшкәнче, мин Михаил Девятаевның кем икәнен белми идем – ул чын герой! Безгә үткәннәрне онытырга ярамый, югыйсә хаталарның кабатлануы ихтимал.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Цифрлы икътисад авыр минутларда **НИЧЕК** булыша ала

Смарт-контрактлар технологиясе **НИ ӨЧЕН** кирәк

Татарстанда офтальмология проблемалары **НИЧЕК** хәл ителә

Авыл җирлекләрендә **НИНДИ** грантлар эшли

ЦИФРЛЫ ИКЪТИСАД КОДЫ

– Цифрлы икътисад ясалма интеллект турындагы ниндидер мифик әкият, киләчәк турындагы сөйләшүләр генә түгел. Ул бүген һәм бирелә бара, – диде ТР дәүләт идарәсенең цифрлы үсеше, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин шул ук исемдәге милли проектның асылы турында. «Татарстан» чыннан да бу «бүген» һәм «биредә» барамы-юкмы икәнлегенә төшенергә тырышып карады.

Автор:
Ксения Сёмина

Фотолар Иннополис Университеты сайтыннан алынды

ОНЛАЙН АЭРОДРОМ

Короновирус аркасында очышларны чикләү Россия авиакомпанияләренә 70 млрд сумнан да ким булмаган күләмдә зыян китерәчәк. Дөнья күләмендә һава юлы белән пассажир ташучыларның югалтулары 110 млрд доллардан да артып китәргә мөмкин, дип фаразлана. Бу турында егерменче март тирәләрендә, Росавиациягә якын чыганакларга таянып, РБК басмасы хәбәр итте.

Беренче карашка, мондый гадәттән тыш вазгыятьтә бизнеска зур югалтуларны урап узу мөмкин түгел кебек. Әмма аның, көчәя баручы трендны анализлау белән бергә, зыянны киметергә ярдәм итә торган чаралар да эшли ала торган системасы булса? Мәсәлән, буш торган ресурсларны яңадан бүлергә яисә яңа вазгыятьтә хезмәттәшлек итүнең шартлары үзгәрүе турында партнерларга алдан ук хәбәр салырга сәләтле системасы? Юк, моның өчен фәнни-фантастик фильмнардагы һәм китаплардагы суперкомпьютер түгел, бәлки смарт-контрактларның яхшы итеп көйләнгән технологиясе генә таләп ителә. Ягъни шул ук килешүләр, әмма цифрлы мохиттә имзалаштырыла һәм гамәлгә ашырыла торган. Авиакомпанияләр һәм короновируска килгәндә исә, мәсәлән, смарт-контрактлар системасы очышлар булмый калган очракта алдан сатылган билетларның акчаларын кире кайтару процедурасын тизләтә ала.

Болар барысы да турыдан-туры Татарстанга карый. Хәзерге вакытта Иннополиста блокчейн-чишелеш эшләнә. «Аэрофлот» ГАҖ аны самолетларга ягулык салулар белән идарә итүдә кулланырга планлаштыра.

Иннополис Университеты белгечләренең блокчейн-системалар өлкәсендә эшләре әлеге проект белән генә чикләнми. 2020 елда РФ Цифрлаштыру министрлыгы Университетка «Блокчейн өлкәсендә цифрлы икътисадның әйдәп баручы тикшеренү үзәге» статусын, шулай ук «Цифрлы икътисад» милли проектының «Цифрлы технологияләр» федераль проекты кысаларында смарт-контрактларны урнаштыру өчен платформа төзү өчен грант бирде. Гамәлдәгеләрдән аермалы буларак, әлеге платформага верификация функциясе, ягъни контрактның хатасыз булуын, легитимлыгын һәм башка күрсәткечләрен тикшерү мөмкинлеге кертелгән. Әлеге аудит берничә минут эчендә башкарылачак, ә бүген исә «кулдан» тикшерә торган консалтинг компанияләренә моның өчен озак вакыт таләп ителә. Платформаның төп өстенлеге шунда: ул компанияләрнең бизнес-процессларына, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләргә тиз арада кушыла ала, дип саный әлеге платформаны эшләүчеләр. Аннан сәламәтлек саклау, төзелеш, сәнәгать һәм башка өлкәләргә караган предприятиеләребез файдалана алачак. 2021 елга кадәр бу технология Россия цифрлы икътисадының – алты тармагында, 2022 елга сигезендә эшләп китәргә тиеш. Татарстанда платформадан иң беренчеләрдән булып Сәламәтлек саклау министрлыгы файдалана башлаячак.

– Бу бик перспективалы эшләнмә. Ул финтехпроектларга инвестицияләр кертүнең яңа форматын төзергә һәм яңа хезмәт күрсәтүләр оештырырга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, сәламәтлек саклауда – пациентлар турындагы мәгълүматны саклауда, мәгарифтә – дипломнар һәм таныклыклар бирүне күзәтүдә, авыл хуҗалыгында һәм сәнәгатьтә продукциянең санын-күләмен исәпкә куюда, сертификацияләүдә, маркировкалауларны контрольдә тотуда. Иннополис Университетының блокчейн-чишелешкә корылган смарт-контрактлары төзелештә эскроу-счетлар белән идарә итәргә булыша. Мондый схема проектлы (элегрәк – өлешләп) финанслаудагы куркынычларны киметергә мөминлек тудыра, – дип шәрехли Иннополис Университетының

проект һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлеге идарәсе башлыгы **Искәндәр Бариев**. Тулаем ил икътисады өчен платформаны гамәлгә кертүнең күренеп торган өстенлеге – базарда катнашучыларның барысын да күләгәдәге икътисадтан чыгару. Россия Цифрлы үсеш министрлыгында блокчейн илдә контрафактлар күләмен 2024 елга 853 млрд сумга киметергә, ә турыдан-туры икътисадый нәтиҗәлелекне (процессларны цифрлаштыру һәм арадашчылар санын кыскарту нәтиҗәсендә чыгымнарны киметү, өстәмә керем хисабына) 782 млрд сумга җиткерергә тиеш, дип саныйлар. Тулаем алганда – 1,635 трлн сум. Даруларны блокчейн-платформада маркировкалау мөмкинлеге турында аерым әйтергә кирәк. Бу базарны контрафакттан, шулай ук наркотиклы һәм башка контрольдә торырга тиешле даруларны урлаулардан коткарачак. Ниһаять, нәкъ менә блокчейн ТКХ өлкәсендә ахыргача тәртип урнаштырырга ярдәм итәргә тиеш. Технология ТКХ хезмәтләрен күрсәтүче төбәк тәэминатчыларын һәм хезмәттән файдаланучыларны бердәм челтәргә берләштерергә сәләтле. Моның белән хезмәт күрсәтүләргә бәя формалаштыру һәм түләүләрнең үтә күренмәлелеге артачак, ә ИК яисә ТМШ вәкилләре тарафыннан түләү кәгазьләрен игътибарсыз һәм дөрес тутырмауда чагылыш таба торган кеше факторы минимумга китереләчәк.

«ЦИФР»ЛАР ӘЛИФБАСЫ

«Бүген үк product-менеджер белгечлеге буенча 1310 вакансия бар, «продакт»ларның уртача хезмәт хакы – 130 000 сум...» – IT сферада белем бирү онлайн-проектларының берсенең сайтында шулай дип хәбәр ителә. Әлеге белгечлекне теләге булган һәркем үзләштерә ала, әгәр... 4,5 айлык онлайн-курсларны үтү өчен, 90 000 сумнан алып 135 000 сумга кадәр акча чыгарып бирү мөмкинлегең бар икән.

Татарстанда әлеге һәм башка цифрлы белгечлекләрне бер ел эчендә үзләштерергә мөмкин. Аның каравы, бушлай! 2019 елда 22 IT-юнәлешнең берсе буенча белем алу өчен мең цифрлы сертификат бирү каралган программа старт алды. Безнең республика РФнең программада катнашырга тиешле биш пилот төбәгенең берсе булып тора. Юнәлешләр арасында компьютер һәм мобиль уеннар эшләүче, цифрлы дизайнер, ясалма интеллект буенча белгеч һәм башка шундый бүгенге көндә кирәкле, таләп ителә һәм яхшы түләнә торган белгечлекләр бар. Уку өчен акчалар (бер сертификатның номиналы – 15 мең сумга кадәр) «Россия Федерациясенең цифрлы икътисады» Милли программасының «Цифрлы икътисад өчен кадрлар» федераль проекты акчалары хисабыннан түләнә. Татарстанда проектның төбәк операторы булып Иннополис Университеты санала.

Республика өчен әлеге проектның эшләп китүе – IT-кадрларга кытлыкны киметү юнәлешендә бик яхшы мөмкинлек.

– Бүген Татарстанда мәгълүмати технологияләр өлкәсендә биш меңгә якын кеше эшли. Дәүләт учреждениеләренең, бизнес һәм сәнәгатьнең әлеге белгечләргә ихтыяҗы – ике мәртәбәгә күбрәк, – диде журналистларга ТР дәүләт идарәсенең цифрлы үсеше, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министры урынбасары **Радик Гыйсмәтов.**

Кайбер белгечлекләр, мәсәлән, күләмле мәгълүматны анализлау яисә ясалма интеллект өлкәсендәге проектлар белән бәйләнгәннәр алдан фундаменталь әзерлек таләп итәләр, шуңа күрә яшь белгечләр сертификат ярдәмендә үзләре өчен алга таба үсеш юлын билгели алалар. Сүз уңаеннан, платформада Россиянең IT-өлкәдә махсуслашкан вузларының һәм урта һөнәри белем бирү оешмаларының әлеге юнәлешкә караган шактый күп белем бирү программалары урын алган. Гариза бирер өчен, башта платформада теркәлергә кирәк. Шулай да программаның максаты – заманча белгечлек алырга теләге булган, ләкин нәрсәдән башларга белмичә югалып калганнарга яңа мөмкинлекләр кырында юл табарга булышу.

– Яшьләр инде IT-технологияләр белән таныш. Безнең бурыч – 45 һәм аннан да өлкәнрәкләргә мәгълүмати технологияләр өлкәсендә белем бирү, бүген мондый белемне бушлай алу җиңел түгел, – дип билгеләп китте гаризалар алу кампаниясе башланыр алдыннан Искәндәр Бариев.

Күпмедер дәрәҗәдә әлеге максатка ирешелгән. Программага кертелгәннәр арасында яшь зурлыгы буенча түбәндәге картина күзәтелә: 18–24 яшьлекләр – 9%, 23–43 яшьлекләр – 44%, 35–44 яшьлекләр – 28%, 45–54 яшьлекләр – 12%, 55–64 яшьлекләр – 7%. Гаризаны 18–65 (хатын-кызлар өчен – 60 яшь) яшьтәге югары яисә урта махсус белеме, теләге булган һәркем тапшыра ала иде.

Иң популяр юнәлешләр арасында (һәркайсы буенча 50 дән артык кеше) «Персональ белешмәләрнең мәгълүмат системасында мәгълүматларны эшкәрткәндә аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү», «Программалаштыру нигезләре һәм Python ярдәмендә мәгълүматны анализлау» һәм «SMM-менеджерларның төп компетенцияләре» бар.

Вебинарлар формасындагы укулар КФУ, КМТТУ (КХТИ), Казан элемтә техникумы, IT-парк һәм «Софтлайн»-компаниясендә үткәрелә. Иннополис Университеты үзе 180 кешене укыта: «Программалаштыру нигезләре» курсында – 64 укучы, «Клиентлар яратырга тиешле цифрлы продуктларны эшләү һәм алга этәрү» курсында – 96, «Мәгълүмти куркынычсызлык буенча crash-курс» курсында 20 кеше укый.

Дәрес ахырында лектор өй эше бирә. Биремнәрнең барысы да тикшерелә. Әгәр курсларда укучы дәресләрне калдыра икән, куратор өй эшләре турында искә төшерә һәм алар үтәлмәгән очракта квалификацияне күтәрү турындагы документның бирелмәве турында кисәтә. Һәр курс ахырында белемнәр тест яисә проектны шәрехләү формасында тикшерелә. Курсны тәмамлаучылар квалификация күтәрү турында дәүләт таныклыгын ала.

Федераль проектның максатчан күрсәткечләренә ярашлы, 2024 елга Татарстан вуз, техникум һәм көллият тәмамлаучы 10 мең кешене цифрлы икътисадның төп компетенцияләренә һәм республикада яшәүче эшкә сәләтле 13 мең кешене яңадан укытырга тиеш.

– Быел 12 вузда, 18 техникум һәм көллияттә без 10 студентка белем бирергә тиешбез. Кадрлар – ул программистлар, инженерлар гына түгел, бәлки теләсә кайсы тармак белгече – медиктан алып авыл хуҗалыгы хезмәткәренә кадәр. «Цифр» бөтен өлкәләргә дә үтеп керә. Шуңа күрә проектны бергәләшеп гамәлгә ашырачакбыз, – диде «Цифрлы икътисад өчен кадрлар» проекты буенча планнар турында **Айрат Хәйруллин.**

Милли проект исә 2014 елга цифрлы икътисад компетенцияләренә ярты миллионга якын кешене өйрәтүне күз уңында тота. Хәзерге вакытта 2020 елда сертификатлар алырга тиешле төбәкләрнең исемлеге төзелә.

Александр Расческов, «Расческов күз хирургиясе» клиникасының баш табибы.

ДӨНЬЯГА **КҮЗЛӘРНЕ** АЧЫП...

Дөньяда ике миллиардтан артыграк дөм сукыр яки күзләре начар күрә торган кеше яши. Шуларның яртысы диярлек профилактика юклыктан яки тиешле дәва алмаганлыктан азап чигә. Югыйсә күбесенең күрү сәләтен бер көн эчендә кайтарып була да бит... Россиядә офтальмология проблемасы бигрәк тә авыл җирендә көн кадагында торучы проблема булып кала бирә. Шулай да Татарстанда аны хәл итү юллары табылган.

КАБАТЛАУ ӨЧЕН ҮРНӘК

Менә сигез ел инде республикада ил өчен уникаль булган «Күз хирургиясенең районара үзәкләре» проекты гамәлгә ашырыла. Аның төп бурычы – авыл җирендә яшәүче халыкка югары технологияле офтальмология ярдәме күрсәтү. Проект дәүләт һәм шәхси партнерлык принципларына таяна, аны Россия офтальмологиясендә күз авыруларын дәвалауда яңа технологияләр куллану буенча пионерларның һәм лидерларның берсе – «Расческов күз хирургиясе» клиникасы башкара.

Бүген Татарстанда әлеге клиниканың биш югары технологияле үзәге гамәлдә. Ул бөтен республиканы, шулай ук тирә-як төбәкләрне дә колачлый.

Казан, Әлмәт һәм Алабуга шәһәрләрендәге үзәкләргә төньяктан Шәмәрдәндә, көньяктан Хузангайда районара үзәкләр кушыла. Аларның барысында да дөньядагы иң алдынгы җитештерүчеләрдән кайтартылган иң яңа диагноз кую һәм хирургия җиһазлары тора. Ә бу исә моңа кадәр беркайда да булмаган күренеш әле.

– Безнең үзәкләрдә аларның башкалада яки Татарстанның эре шәһәрләрендә, алардан читтә урнашуына карамастан, офтальмология ярдәменең барлык төрләре дә күрсәтелә, – дип ышандыра «Расческов күз хирургиясе» клиникасының баш табибы Александр Расческов. – Шуны да ассызыклап китәм: бирегә сүз медицина хезмәтләндерүенең тулы комплексы турында бара. Диагноз куюдан башлап, дәвалауга кадәр. Моңа күз кабаклары һәм мөгез катлавы авыруларыннан алып, иң катлаулы витреоретиналь патологияләр, травмалардан соң күз структурасы бөтенләе белән бозылган очракларны дәвалауга кадәр керә...

ЯҢА ТРЕНД. АВЫЛЧА

«Авылча» проекты кысаларында нинди уникаль очраклар булганы бар, дигән сорауга Александр Юрьевич елмая гына:

– Сезнең бер күз белән килеп, өч күзле булып кайтып киткән кеше турында ишетәсегез киләме? Беләсезме, безнең өчен иң мөһиме – уникальлек түгел (гәрчә горурланырлыгыбыз да бар), ә авыл халкының тормыш сыйфатын яхшырту. Кеше үз җирендә үзен бәхетле итеп сизсен. Туган җирен ташлап китмәскә тагын бер сәбәп булсын, дип телибез.

Клиника моңа ярдәм итә. Пациентларга офтальмологта даими рәвештә

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

Реклама

Фотолар «Расческов күз хирургиясе» клиникасыннан алынды

күз авырулары аркасында гына күзәтелеп тору таләп ителми, аларга кан әйләнеше системасы, нерв һәм эндокрин системаларында килеп чыккан авырулар, шикәр авыруы аркасында да күз табибына килергә кирәк… Балаларга да кирәк. Россиянең Сәламәтлек саклау министрлыгы статистикасы мәгълүматларына караганда, аларның ун процентка якыны мәктәпкә «күрә карау» диагнозы белән килә, ә укып бетергәндә, өчтән бере күзлек кия башлый. Шуңа да клиниканың барлык төбәкара үзәкләрендә балалар бүлекчәләре дә эшли башлады, ә инде авыл балаларына офтальмолог ярдәме әти-әниләрнең хыялыннан гадәти көнкүрешкә әйләнде.

Сүз уңаеннан, төбәкара үзәкләрдә балалар диагностиканы бушлай үтә, бу исә бәләкәй пациентларга югары квалификацияле ярдәмне үз вакытында, гаиләнең кесә калынлыгына карамыйча да алып була дигән сүз. Алай гына да түгел, Шәмәрдән белән Хузангай районара үзәкләрендәге авыл кешеләренә күрсәтелә торган медицина ярдәме бушлай дәүләт гарантиясе программасына кертелде. Биредә сүз бушлай диагноз кую турында гына бармый, катлаулы операцияләр дә шуңа керә. Авылда ихтыяҗ бик зур аңа. Үзәкләрнең мөмкинлекләре кебек үк. Әмма дәүләт-шәхси партнерлык кысаларындагы дәүләт заказы клиникага йөз генә күзгә бирелә. Чагыштыру өчен: бер үзәкнең бер айлык эшеннән дә азрак бу. Квоталарның санын арттыру бик күп проблемаларны хәл итәргә булышыр иде – авыл кешеләренең сәламәтлеген кайгыртудан алып перспективалы белгечләрне эш белән тәэмин итүгә кадәр. Шулай ук әлеге мөмкинлек башкаладагы югары технологияле клиникларның да эшен киметә ала, бу очракта авыл кешесенә офтальмология буенча соңгы казанышлар артыннан шәһәргә бару мәҗбүри түгел!

Шул рәвешле «Расческов күз хирургиясе» клиника үзәкләре республика өчен уңайлы офтальмология ярдәме челтәренә әверелде. Ә сәламәтлек саклауның башка тармаклары һәм төбәкләре өчен – үрнәк. Авылда югары технологияле медицина – гамәлгә ашмаслык эш түгел, димәк. ■

«Әлмәт күз хирургиясе үзәге» ачылу тантанасында.

Расческов

«Расческов күз хирургиясе» клиникасы
Казан, Патрис Лумумба ур., 28а,
(843) 204-03-03

МЕЖРАЙОННЫЙ ЦЕНТР ГЛАЗНОЙ ХИРУРГИИ

Районара күз хирургиясе үзәге – Шәмәрдән
Саба районы, Шәмәрдән авылы,
Фрунзе ур., 6б,
(84362) 3-24-80

Районара күз хирургиясе үзәге – Хузангай
Әлки районы, Сихтермә-Хузангай,
Школьная ур., 28,
(84346) 7-34-65

Күз хирургиясе үзәге – Әлмәт
Әлмәт, Ленин ур., 201,
(8553) 399-911

Күз хирургиясе үзәге – Алабуга
Алабуга, Автомобилистлар ур., 4,
(85557) 58-911

www.rascheskoff.ru

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

«АКЧА ҺАВАДАН ТӨШМИ...»

Дәүләт биргән грантларга ике төрле караш бар: берәүләр аннан уттан курыккан кебек курка, икенчеләр, киресенчә, берсен алгач, чираттагысы артыннан йөри башлый. Югыйсә грант алуның шартлары, таләпләре бөтен кешегә дә бер бит...

Грантлар күптөрле. Без арадан «Агростартап» программасына тукталырга булдык. Ни өчен дигәндә, узган елны фермерлар даирәсендә иң күп кызыксыну уяткан грант ул. Әлеге программа кысаларында дәүләттән акча алган фермерларның берничәсе белән танышып, аларның тәҗрибәләре турында белештек.

Сүз уңаеннан, «Агростартап» программасы «Кече һәм урта эшкуарлык» милли проектын гамәлгә ашыру кысаларында эшли. Узган елны әлеге программада 36 районнан 132 КФХ катнашкан, шулар арасыннан 103 фермер грант откан. Аларга барлыгы 312,7 млн сумлык акча бирелгән. Грантны отучылар арасыннан иң күбе мамадышлылар – сигез фермер, Азнакай һәм Теләче районнарыннан – алтышар фермер.

Әзерләде:
Руфия Фазылова

«АТЛАР – ИҢ АКЫЛЛЫ ҖАН ИЯЛӘРЕ»

Фәридә Яруллина, Чистай:

– Узган ел «Агростартап» программасы кысаларында 3 миллион сум грант оттым. Моңа кадәр андый программаларда катнашканым юк иде. Хәер, әле фермер булып теркәлүемә дә бер генә ел. Грант алудан куркырга кирәкми, хәзер моны үз тәҗрибәмә таянып әйтә алам. Анда баш җитмәслек бер әйбер юк. Бүген үзебезнең районнан өч фермер белән эшлим, ягъни грант алыр өчен документларын тәртипкә китерергә булышам. Алар миңа туган да, дус та түгел. Киңәш, ярдәм сорап мөрәҗәгать иттеләр, каршы килмәдем. Кешенең эшләргә нияте, теләге бар икән, рәхәтләнеп эшләсен. Миңа калса, районнардагы «Фермерлар ассоциациясе» тиешлечә эшләп бетерми. Ә алар һәр районда бар. Әлеге оешма эш башлаучы фермерга беренче ярдәм күрсәтергә, аңлату эшләре алып барырга тиеш дип саныйм.

Эшем турында: грантны атлар үрчетү өчен дип алдым. Узган ел зур ферма бинасы эшләттем, кимендә, йөз башка исәпләнгән ул. Грант акчасына нәселле атлар сатып алдым. Бүген хуҗалыкта йөз башка якын бахбай бар. Максатым – бер-ике ел эчендә аларны 200 башка җиткерү. Әле тагын дәүләт программасында катнашып, ит эшкәртү цехы ачасым килә. Атларны тере килеш сатып җибәрү әллә ни табыш китерми.

Күпләр миңа: «Син бит хатын-кыз. Атлардан курку юкмы?» – дип сорый. Кечкенәдән атлар яратам, гәрчә өйдә беркайчан ат асрамасак та. Ә гаиләбездә ат барлыкка килүгә улыбыз Азат сәбәпче булды. Бик ялынып колын алып кайтуыбызны сорады ул. Үсмер чагы, дип, каршы килмәдек. Тик алты айлык колын бездә бик күңелсезләнде. Иптәш булсын өчен, янә бер колын алып кайттык. Менә шуннан китте инде. Атлар кебек акыллы җан ияләрен бүтән күргәнем юк. Алар барысын да аңлый, шуңа күрә куркуыңны күрсәтергә ярамый. Бер кызык үзенчәлек белән бүлешәсем килә: әгәр ат колакларын артка җибәрә икән, якын барма, ул сиңа карата хәерхаһлы түгел. Әгәр инде колакларын туры тотса, бахбай синең белән кызыксына, янына килергә рөхсәт бирә, дигән сүз.

Менә шулай бер уйламаган җирдән фермер булып киттем. Арендага 60 гектар җир дә алдым. Чистай районы башлыгына зур рәхмәтемне җиткерәсем килә, эш башлаучыларга гел ярдәм кулы суза ул.

КУКМАРАДА – ТАВЫК ФЕРМАСЫ?

Динар Гайнуллин, Кукмара:

– Кукмара районы өчен яңа юнәлеш – чеби үстерергә булдык. Иске ферма биналарын ремонтладык, чебиләр өчен махсуслаштырдык. Мин үзем генә түгел, барлыгы 12 ират «Индейка» кооперативы астында эшлибез. Без – дүрт егет, узган ел гына әлеге командага кушылдык. Дүртебез дә тавык-чеби үстерү юнәлешендә эшләячәкбез.

Мин «Агростартап» программасы кысаларында 4 миллион сум грант оттым. Шуның миллионнан артыгы ферма төзекләндерүгә тотылды, калган суммага чеби, азык алырга планлаштырам. Казанның «Залесный» агрофирмасы белән килешү төзелгән инде. Март урталарында 11 мең тавык чебие кайтырга тиеш. Аларны дүрт ай тирәсе карап үстергәч, янә «Залесный» агрофирмасына тапшырачакмын. Ни өчен дигәндә, аның кадәр чебешне суеп, эшкәртү өчен махсус җайланмалар кирәк. Ә бу тагын акчага бәйле. Шуның өчен әлегә менә шул рәвешле генә эшли алабыз. Ә киләчәккә планнар зур, әлбәттә. Кооператив белән тавык итен җитештерү буенча зур бер үзәк булдырысыбыз килә: чебиләрне үзебез чыгарып, үстереп, эшкәртеп сату. Республиканың башка кошчылык фермалары белән конкуренциядә торырлык зур үзәк булдырасы килә.

Кооперативтагы фермерларның уртача яше – кырык тирәсе. Мәсәлән, миңа әле утыз яшь кенә. Дәүләт ярдәменнән башка мондый масштабтагы эшне ача алмас идем. Арабызда шәһәргә китеп, яңадан авылга кайтучылар да бар. Анда кемгәдер эшләп йөргәнче, авылда, ичмаса, үзеңә эшлисең. Әлбәттә,ниндидер шикләнү, курку да бар: әлегә мондый күләмдә чеби үстергәнем юк бит... Берничә тәҗрибәле кеше белән аралаштым, кош фермаларына сәяхәт иттек. Бу эшнең барлык нечкәлекләрен дә өйрәндем кебек. Шуңа күрә барысы да әйбәт булыр дип өметләнәм. Тагын шунысы да күңелне җылыта: мин үзем генә түгел, кооператив белән. Ә күмәк көч тау күчерә, диләр.

«СЫЙФАТЛЫ БАЛЫК ҖИТЕШТЕРӘБЕЗ»

Рәфис Әхмәтсафин, Бөгелмә:

– Дөресен генә әйткәндә, улым Эдуард башлаган эшне дәвам итүче генә мин. Лаеклы ялга чыккач, менә шулай икенче сулыш ачылды...

Дүрт ел элек Эдуард Бөгелмә районының Иске Исаково авылы янындагы күлне арендага алып, карп маймычларын җибәргән иде. Буш вакытта мин дә аңа булыштым. Ә улым бу өлкәдә профессионал дисәм дә була. Самара өлкәсендәге балык совхозында шактый вакыт эшләде ул. Иске Исаково авылындагы әлеге күл колхозлар чорыннан калган. Совет заманында анда балыклар үрчеткәннәр. Ул ташландык хәлгә килгән иде. Күл дамба белән икегә бүленгән. Улым аның башта кечкенә ягын арендага алды, чистартты. Ике ай буена ничә КАМАЗ чүп түккәнбездер. Боларның барысын да ул үз акчасына эшләде. Эдуардның эшли алганын күргәч, Бөгелмә районы җитәкчелеге күлнең икенче ягын да арендага бирде.

Ә мин исә әзергә килдем дисәм дә була. Яңа «Агростартап» программасы чыкканын белгәч, грантка документлар тапшырдык. Шартлар буенча туры килә идек. Шулай итеп миңа 3 миллион сум акча бирделәр. Май аенда ул акчага улым белән Самара өлкәсендәге балык совхозыннан маймычлар алып кайтачакбыз. Балык үрчеткәндә иң мөһиме – нәсел. Чагыштыру өчен: тавык чебиенең яхшысы ике-өч ай эчендә өлгерә, начар икән, дүрт айда да булмый. Балык белән дә шулай, маймыч нәселле түгел икән, үсми. Ите дә тәмле булмый.

Баштагы вакытларда: «Күлдә балык тотыйк әле», – дип киләләр иде. Андый кешеләргә беркайчан да рөхсәт бирмәдек. Болай эшләсәң, харап буласың. Ни өчен икәнен аңлатам. Маймычлары суга җибәргәннән соң, ятьмә белән атна саен тотып, үлчәп карыйсың. Күпме ризык ашаганнарын исәплисең. Бер айлык вакытта,10 мең маймычка фәлән кило ризык кирәк икәнен беләсең. Ә балыкчылар, килеп,

балыкларыңны тотса, баш санын югалтасың. Ә димәк, күпме ризык кирәк икәнен чамалый алмыйсың. Ризык аз булса, балык үсми, күп икән, артыгы суда бозылып кына ята. Бу балыклар өчен зыянлы. Без сыйфатлы балык ите җитештерәбез, монда һәр нәрсә мөһим.

Балыкларны урнаштыру буенча проблема юк, күпләп сатып алалар. Әлеге дә баягы, моның да үз нечкәлекләре бар. Балык күп булгач, без аның бәясен вак фермерларныкына караганда арзанрак итә алабыз. Мисал өчен, көзге ярминкәләрдә карпның килосы 170 сумнан булса, без 130 сумнан саттык. Бер машина товарны санаулы сәгатьләр эчендә сатып бетереп кайттык. Безнең балыкны бер ашап караган кеше тагын килә. Әйткәнемчә, эш итнең сыйфатында.

Язга Эдуард мәрсин (осетр) маймычлары алып кайтырга җыена. Аның килосы 800 сумнан да ким түгел, кара уылдык өчен дә тотарга була. Кыскасы, алга таба планнары зур. Балыкчылык Татарстанда гына түгел, Россиядә дә киң җәелмәгән. Минемчә, конкуренция булмаган өлкәдә эшләргә җайлырак.

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы «Агростартап» программасы кысаларында авыл хуҗалыгы өлкәсенә кече һәм урта эшкуарлык субъектларын җәлеп итү, авылда эш белән тәэмин итүне арттыру максатыннан, крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм шәхси ярдәмче хуҗалыклар арасында сайлап алу конкурсын дәвам итә. Грант алучылар ит һәм сөт җитештерү, ат, сарык үрчетү, кошчылык, умартачылык, балыкчылык, җиләк-җимеш культуралары, бөртекле, кузаклы һәм азык культуралары юнәлешләре буенча эш башлый алалар.

«САРЫМСАК КЫНА, ДИМӘГЕЗ...»

Азат Сөләйманов, Сарман:

– Моннан өч ел элек үзебезнең пай җирләребезне алып, рәсмиләштергән идем. Барлыгы 21 гектар җир ул. Сарымсак үстерү теләге дә шул чакта бөреләнде. Тик әлегә кадәр һаман хыялны тормышка ашырырга мөмкинлек чыкмады. Узган ел «Агростартап» программасы барлыкка килгәнен ишеткәч, тәвәккәлләргә булдым. Районга да әйтеп тормадым, туры Казанга – ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына киттем. Анда миңа барысын да аңлаттылар. Грант алыр өчен бизнес-проект эшләдем. Исәп-хисап счеты ачып, шунда 400 мең сум акча салдым. (Эш башлаганда 10 проценты үзеңнеке булырга тиеш.) Шулай итеп 2019 елның 20 декабрендә 2 миллион 600 мең сум грант акчасы күчте. Ул акчага җир эшкәртү өчен трактор алдым, хәзер чәчкечләр артыннан йөрим.

Җирләр өлгергәч, эш башларга исәп. Алда әйткәнемчә, сарымсак үстерү белән шөгыльләнәсем килә. Ләкин быелга инде соңга калдым, сарымсакны көзен чәчәргә кирәк. Алла боерса, бу эшне сентябрь-октябрьдә эшләргә исәп. Ә быел пай җиребезнең берничә гектарына кишер чәчәчәкмен. Сарымсак белән кишергә бертөрле чәчкечләр кирәк, шуңа күрә артык чыгымнар булмаячак.

Бөтен планнарны алдан кычкырып куясым килми, әлбәттә. Шулай да әйтим инде: кишерне кореялеләр тәмләткече белән салат ясап сатасым килә. Көзен татлы тамырның бәясе 10 сум була, ә салат итеп сатсаң, килосы 100 сумга баса. Калган нечкәлекләрен эш башлагач сөйләрмен.

Сарымсак үстерү тагын да отышлырак дип уйлыйм. Мисал өчен, бүген кибеттә аның килосы 250 сумнан да ким тормый. Әйе, сатуга үстергәндә, яхшы сарымсак кирәк. Инде Краснодар краендагы фермерлар белән сөйләштем, орлыкны алардан сатып алырга уйлыйм.

Илле өч яшемдә фермер булдым. Бу кадәр күләмдә яшелчә, иген үстерү тәҗрибәм юк иде моңарчы. Әлбәттә, авылда яшәгәч, бакча тотабыз, анда яратып эшлим. Эш башлар өчен шул тәҗрибә җитәр дип уйлыйм. Миннән күреп башка авылдашлар да үз эшләрен ачмаслармы... Гаҗәп хәл бит – безгә сарымсакның күп өлеше Кытайдан керә. Югыйсә аны рәхәтләндереп үзебездә дә үстереп була. Авыл кешесенә эш булыр, кулланучы да чиста һавада үскән, натураль ризык ашар иде. Кыскасы, авыл хуҗалыгы тармагында әллә ниләр майтарырга була. Дәүләт ярдәм кулы сузам дип торганда, тәвәккәлләргә генә кирәк. Мин моны шулай дип танышларга, дусларга да әйтәм. Акча һавадан төшми, эшләп алырга кирәк...

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Әбиләр **НИЧЕК** үзгәрә

Җәүдәт Фәйзинең пианиносы **КАЙДА** тора

Тылда Җиңүне **НИЧЕК** якынайтканнар





Гади генә шатлыклар

Әбиләр 3 ничек үзгәрә

Әбекәйләрне гүзәлләндерү буенча «Татарстан» журналының һәр март саен үз эшенә керешә торган «матурлык десанты» быел Буа картлар һәм инвалидлар йортына килеп төште.

Биредә безне сөенеп каршыладылар: «Без, ел саен «Татарстан» журналының март санын ачып, андагы матур әбиләрне карап хозурланганда, кайчан да булса безгә дә килеп җитәрләр әле, дип өметләнә идек, – ди картлар йорты директоры Рәзинә Хисаметдинова. – Һәм менә, ниһаять, килеп җиттегез! Рәхим итегез!»

Буа картлар һәм инвалидлар интернаты коллективы да «Татарстан» журналы алып килгән стилистлар, косметологлар һәм мода белгечләренә иш булып чыкты. Крахмалланган чиста халат кигән кызлар безнең тату командага тиз кушылып китте: менә инде күз алдыбызда героиняларыбыз үзгәрә, яшәрә башлады – һәм, башларына эшләпәләрен кыңгыр салып, «Ялтага, диңгезгә» юл алды...

«Татарстан» традициясе буенча, рамкага куелган һәм журналдагы фото – язгы хатын-кызлар бәйрәме өчен иң шәп бүләк. Чөнки һәр хатын-кызның матур һәм зәвыклы фотосы һичшиксез булырга тиеш.

КАТНАШУЧЫЛАР

Валентина Михайловна Кузьмина

Дилбәр Хәлим кызы Низамова

Нурия Барый кызы Арысланова

Әминә Садыйк кызы Гафурова

Люба Степановна Митрофанова

Фото: Александр Ефремов

Гади генә шатлыклар

ҺӘРВАКЫТ ХӘРӘКӘТТӘ БУЛУ ЗАРУР

Валентина Михайловна Кузьмина
65 яшь:

– Мин авылда гади гаиләдә туганмын. Балачактан күп эшләдем: кер юдым, су ташыдым, кар көрәдем… Әбиемне бик ярата идем. Хәзер инде үзем дә – әби. Әмма әле һаман да эшсез тора алмыйм. Биредәге хезмәт белән дәвалау дәресләренә йөрим, Скандинавия йөреше белән шөгыльләнәм – эш һәм спорт картаймаска булыша. Һәрвакыт хәрәкәттә булу зарур – бу сәламәтлек өчен дә, матурлык өчен дә файдалы.

АКТИВ ТОРМЫШ МИҢА БИК ОШЫЙ

Дилбәр Хәлим кызы Низамова
78 яшь:

– Мин 1941 елның июлендә – сугыш башлангач туганмын. Бик бәләкәй булганга, ярый әле ул кыен чакларны хәтерләмим... Әмма әти-әниемә ач-ялангач булырга туры килгән. Монда бөтенесе дә мине актриса яки модельгә охшата, ә мин гомерем буе гап-гади сыер савучы булып эшләдем! Әмма башкалар мактагач, сынатмаска тырышам инде – биредә оештырылган бөтен матурлык конкурсларында («Красота в любом возрасте», «Молодильное яблоко», «Йога – мудрость золотого возраста») катнашам. Миңа аларда катнашу да, җыену да ошый. Актив тормыш миңа бик тә туры килә.

ЯХШЫЛЫКНЫ ОНЫТМАСКА, НАЧАРНЫ ХӘТЕРДӘН СЫЗЫП ТАШЛАРГА

Нурия Барый кызы Арысланова

81 яшь:

– Минем әнием бик матур булган. Әтием аны урлап өйләнгән. Аларның җиде баласы туган, мин – икенчесе. Әтием сугышка киткәч, ачлык һәм ялангачлык башланды – ул чакны мин нәкъ менә шулай хәтерләп калдым. Өстән утлар күренмәсен өчен, төннәрен ут кабызырга рөхсәт итмиләр иде, кич кергәч, авыл үлгән кебек була... Тормышым җиңел булмады: башта ике балам белән калдырып, ирем ташлап китте, аннары бер-бер артлы балаларым һәлак булды... Бу кайгы мине бик бетерде, көне-төне еладым. Шулай монда килеп эләктем – бу йорт минем үземнекенә әйләнде. Биредә мин кабат җырлар тыңлый һәм җырлый башладым, һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер дуслар таптым. Бернигә дә карамыйча, яшәргә кирәк, без ни өчендер бу җиргә килгәнбез бит. Яхшылыкны онытмаска, начарны исә хәтердән сызып ташларга кирәк.





ГОМЕР КӨЗЕН РӘХМӘТ БЕЛӘН КАБУЛ ИТИК

Әминә Садыйк кызы Гафурова
90 яшь:

– Мин бу йортта инде күптәннән – 2008 елдан бирле яшим. Миңа биредә җылы һәм тыныч. Карыйлар, тәрбиялиләр. Март – һәрвакыт бәйрәмнәр ае: хатын-кызлар көне дә, туган көнем дә мартта – быел унынчы дистәне ваклый башлыйм. Мин үзем – Буаныкы, 40 ел буе эшләдем. Кияүгә чыккан идем, балабыз булмады, аннары ирем үлде... Менә шулай да була. Гомер бик тиз, бер көндәй узып китә икән. Шунлыктан Аллаһы Тәгалә бүләк иткән һәр көнгә сөенеп яшәргә кирәк. Яз белән хозурланырга, җәйне көтәргә, көзен сагышланмаска. Гомер көзен рәхмәт белән кабул итү зарур, бу да – бик матур чак.



КИНО ҺӘМ АРАЛАШУ КӘЕФНЕ КҮТӘРӘ

Люба Степановна Митрофанова

93 яшь:

– Минем исемем – Люба, Любовь түгел, ә нәкъ менә Люба. Метрикада шулай язылган. Минем Аксинья һәм Пелагея исемле сеңелләрем бар иде, аларның да исемнәре матур. Әнием – Христина, әтием Степан исемле иде. Без Чүпрәле районының Кече Аксу авылында бик хәерче яшәдек. Әти-әни колхозда эшләде, балачактан аларга булышып үстек. Яхшы эшләгән өчен бервакыт миңа кәстрүл бүләк иттеләр – мин шундый горурландым! Ул чакта тормыш бик авыр иде: ирләр – сугышта, хатын-кызлар көне-төне эштә. Шулай итеп кияүгә дә чыкмый калдым, миндәй фәкыйрьне кем алсын?! Балам булмаган өчен 150 сум акча тотып калалар иде. Әниемнән: «Элек кешеләр ничек яшәгән? Ул чакта тагын да кыенрак булгандыр бит?» – дип сораганым истә. Ә ул миңа: «Исән калырга түземлек булыша,» – диде. Хәзер бөтенләй башка тормыш – авыр эш тә, сугыш та, ачлык та юк. Куанып яшәргә генә кирәк. Менә мин укырга һәм чигәргә яратам. Яшьлегемдә бу турыда хыяллана гына идем. Бөтен кешегә дә иминлек һәм тыныч тормыш телим. Беркайчан да сугыш булмасын. Ачуланышмагыз, игелекле булыгыз.

100 ТАТАРСТАННЫҢ МУЗЕЕ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА

ИҢ НӘФИС. «СӨЕМБИКӘ» ЖУРНАЛЫ МУЗЕЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ бинасында, бездән бик якында, «Татарстан» журналы редакциясенең янәшәсендә генә, «Сөембикә» редакциясе архивында уникаль музей экспонатлары – 1913 елдан бирле тупланган журналлар саклана. Татар хатын-кызлары өчен беренче журнал нәкъ менә шул елда чыга башлый һәм үткән дәвер эчендә үзенең исемен нибары бер тапкыр гына алыштыра: башта «Сөембикәдән» – «Азат хатынга», аннары – киресенчә.

Хатын-кызлар бәйрәме алдыннан «Сөембикә» журналистлары үз «музейларындагы» раритетларны дөньяга чыгарды һәм коллегалары, укучылары, дуслары, «ТАТМЕДИА» кунаклары өчен узган елларда чыккан журнал тышлыкларыннан уникаль күргәзмә оештырды. 30 нчы, 40 нчы, 50 нче, 60 нчы, 70 нче еллар тышлыкларында Татарстанның азат хатыннары – чаңгычылар, артистлар, хезмәт каһарманнары, хәрбиләр, студентлар һәм гади аналар сурәтләнгән. «Алёнка» шоколады кәгазендәге булачак «азат хатын» да биредә.

«Азат хатын», 1933 ел, № 4.
Арча районы «Тукай Кырлай» колхозында беренче бригададан Мифтахова Кәримә, икенче бригада члены Вәлиева иптәшләр бригадаларда машина белән чәчүче итеп билгеләнделәр.

«Азат хатын», 1938 ел, № 19.
Казан аэроклубының очучылар мәктәбендә укучы – педагогика институты студенткасы Мәсгудә Зарипова.

«Азат хатын», 1959 ел, № 7.
Яңа юл районының инкубатор станциясе зоотехнигы Кадия Нуриева бер көнлек чебешләрне карый.

«Азат хатын»,1963 ел, № 2.
Советлар Союзы Герое Мәгубә Сыртланова.



«Азат хатын», 1977 ел, № 9.
Минзәлә районы «Ярыш» колхозының алдынгы сыер савучысы, авыл Советы депутаты, коммунист Гөлфия Муллахмәтова.

– Һәр тышлык – дистәләрчә ел яши торган тарих ул, – ди «Сөембикә» журналы баш мөхәррире Лариса Маликова. – Безнең героиняларыбыз – республика үсешенә үз өлешен керткән авыл хезмәтчәннәре дә, Оргсинтез, Чистай сәгать заводы, КАМАЗ кебек зур предприятиеләр эшчеләре дә. Алар – куәтләре нәфисләктә булган көчле хатын-кызлар.

НӘРСӘ:
«Сөембикә» журналы күргәзмәсе

КАЙДА:
Казан, Декабристлар ур., 2; 1 нче кат, «ТАТМЕДИА» АҖ галереясы

КАЙЧАН:
Эш көннәрендә 9.00 дән 18.00 сәгатькә кадәр.

Фотолар «Сөембикә» журналы редакциясеннән алынды

Фото астындагы язмаларда шул чактагы орфография һәм пунктуация саклангн.

УҢЫШКА
РУХЛАНДЫРУЧЫ ГҮЗӘЛЛӘР

«Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика конкурсында җиңүчеләрне бүләкләү тантанасында чыгыш ясаганда, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов хатын-кызларның хәзерге дөньядагы ролен билгеләп үтте: «...Катлаулы чорда яшибез, республикабызның үсеше, илебезнең үсеше өчен җаваплы без хәзер. Хатын-кыз – гаилә дигән сүз ул, һәм Көнбатыш җәмгыяте нинди генә схемалар уйлап тапмасын, классик гаилә схемабызны саклап калырга һәм демография өчен көрәшергә кирәк».

«ЯХШЫ ЭШ ҖАЙЛАНГАН ТОРМЫШТАН БАШЛАНА»

Бүгенге көндә хатын-кыз үзен мөстәкыйль һәм бәйсез хис итсен, социаль һәм хокукый яклау өлкәсендә ышаныч тойсын, шул ук вакытта элеккедән килгән кыйммәтләр саклансын өчен, дәүләтебезнең күп һәм нәтиҗәле эшләве бәхәс уятмый. Безнең республикада аналар һәм балаларны саклауга зур игътибар бирелә. Моның дәлиле – Татарстанның эре предприятиеләрендә хатын-кызларга һәм аналарга ярдәм күрсәтү юнәлешендәге колачлы социаль программалар. Мондый предприятиеләр арасында «Түбән Кама Нефтехим» гаммәви акционерлык җәмгыяте дә бар.

«Яхшы эш җайланган тормыштан башлана» – бу сүзләр «Түбән Кама Нефтехим»ның легендар генераль директоры, СССР химия һәм нефть эшкәртү сәнәгате министры Николай Лемаевның тууына 90 ел тулуга багышланган китапта әйтелгән. Ул нәкъ менә шул принципны тормышка ашыра да инде: заводлар белән бергә йортлар, кибетләр, китапханәләр, балалар бакчалары, мәктәпләр, хастаханәләр, спорт объектлары, җылылык һәм су белән тәэмин итү объектлары, чистарту корылмалары, юллар төзелә. «Түбән Кама Нефтехим» өчен социаль яклау һәм социаль ярдәм – бүген дә компания үсешендәге өстенлекле юнәлешләренең берсе. Хатын-кыз һәм җитештерү тармагы – үзе бер аерым тема. Бигрәк тә сүз катлаулы җиһазлар белән эш йөртүне һәм катлаулы технологик процесслар белән идарә итә белүне күздә тоткан нефть химиясе производствосы кебек җитди юнәлеш турында барганда. Заводта күпчелек ир-атлар эшләсә дә, нефть химиясе тармагында хатын-кызлар елдан-ел арта бара. Бүген компаниядә төрле һөнәр иясе вәкилләре булган 6 меңгә якын хатын-кыз эшли: аппаратчылар, технологлар, лаборантлар... Җитештерү эшен уңышлы башкарып, алар гаять актив тормыш белән яши һәм авырлыклар алдында бер дә югалып калмый.

ЯЗ КИЛӘ!

Көннәр җылына, якты кояш елмая, кар эри һәм шулар белән проблемалар да юкка чыга –яхшы кәеф һәм рухи күтәренкелек алып килеп, яз әнә шулай үзенең законлы хокукларына керә.

7 март көнне, яз бәйрәме алдыннан, ТР Дәүләт зур концертлар залына төрле тармакларда уңышлы эшләүче үрнәк гүзәл затларыбыз, шулай ук күп балалы әниләр һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары агылды. Монда гадәттегечә «Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика конкурсына йомгак ясалды. Залда мәдәният, мәгариф, фән, бизнес һәм сәнәгать өлкәсе вәкилләре арасында – «Түбән Кама Нефтехим» хезмәткәрләре дә бар иде.

Ничек кенә булмасын, хатын-кыз – хәзерге ыгы-зыгылы дөньябызда да гүзәллекнең алыштыргысыз символы ул. Нәкъ менә алар өчен дип минут саен искиткеч гамәлләр һәм сокландыргыч батырлыклар кылына. Хәер, хатын-кызлар үзләре дә кайчак гаҗәеп үрнәк булып тора.

ҺӨНӘРЕ – АНЫҢ ЯЗМЫШЫ

«Искиткеч хатын-кыз ул, барысына да кайчан гына өлгереп бетә? Аның өчен тәүлектә 28 сәгать бугай!» – диләр «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ Дивинил һәм уг-

Хатын-кызның җәмгыятьтәге, бала тәрбияләүдәге үзенчәлекле ролен исәпкә алып, бәби тугач, ана кешегә «Түбән Кама Нефтехим» җәмгыятендә матди ярдәм күрсәтелә. 16 яшькә кадәрге балалары булган аналарга, 50% хезмәт хакын саклап, ай саен бер көн ял бирелә. Мәктәп каникуллары вакытында «Корабельная роща» санаторий-профилакторие һәм ял базалары «ана һәм бала» режимында эшли. Яңа ел бәйрәмнәренә ел саен театральләштерелгән тамашалар оештырыла. «Нефтехим» хезмәткәрләре балаларының «Юность» һәм «Олимпиец» сәламәтләндерү лагерьларында ял итү мөмкинлеге бар.

Фотоларны «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ матбугат хезмәте тәкъдим итте

Реклама

леводород чималы җитештерү заводының компрессор һәм насос җайланмалары машинисты Гөлнара Гыйльманова турында. Ул чыннан да бик күп нәрсәгә өлгерә – үз заводында яшьләрне өйрәтү белән дә шөгыльләнә, цехның профсоюз комитетын да җитәкли, өч ул һәм бер кызның әнисе булырга да җитешә. Һәм шул ук вакытта искиткеч мөлаем хатын-кыз да булып кала бит! Күп кенә хезмәттәшләре аның белән шатлыкларын һәм шик-борчуларын уртаклаша, Гөлнара ханымның акыллы киңәшләре аларга һөнәрләрендә дә, тормышта да булыша.

Компаниядә ул инде 12 ел хезмәт куя. 20 ел башлангыч сыйныфлар укытучысы булып эшләгән мәктәбеннән заводка килеп, насос җайланмалары машинисты белгечлеген нульдән үзләштерә. Гөлнара Ринат кызының үз тормышын шулай үзгәртергә җөрьәт итүе дә аның тәвәккәллеге, хезмәт сөючәнлеге һәм яңалыкка омтылышы, моңарчы сынап карамаганны үзләштерергә теләве турында сөйли. Чөнки белем-тәҗрибә белән уртаклашу өчен, аларны гел яңартып торырга кирәк, шуңа күрә ул, төп эшеннән аерылмыйча, производство-техник курсларда үз квалификациясен даими күтәреп-камилләштереп тора.

«Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика конкурсы 1996 елдан бирле Татарстанның социаль-икътисадый үсешенә, мәдәниятккә, рухиятккә, яшь буынны тәрбияләүгә, гаилә институтын ныгытуга зур өлеш керткән хатын-кызларны ачыклау һәм җәмгыятькә тәкъдим итү максатыннан үткәрелә.

– Шаблоннарга, стандартларга һәм планкаларга карап тормаска, үзең өчен таныш булмаган яңа эштән курыкмаска һәм, ерып чыга алмасам, нәрсә булыр, дип уйламаска. Үз-үзеңә ышаныч булганда һәм үз көчеңә генә исәп тотканда, һәр эшне башкарып чыгарга мөмкин, – Гөлнара Гыйльманованың уңыш сере әнә шундый. – Бүген мин, әйтик, үземне башка урында күз алдына да китермим, минем өчен завод – яртьı гомерем.

Тик хатын-кызның язмышы, ни генә дисәк тә, гаилә булганда гына тулы мәгънәгә ия. Ә Гөлнара Ринат кызының гаиләсе бар гына түгел, бу гаилә әле зур да. Һәркемне сыйлау, һәм, һичшиксез, тәмле ризыклар белән сыйлау – әни кеше буларак, Гөлнара өчен аеруча куаныч. Ә ял көннәрендә Гыйльмановлар, тату компания булып, тимераякта, чаңгыда һәм кабартма чаналарда шуарга шәһәр читенә чыгып китә. Җәйгә дә күп калмады, ул чакта инде Күмәк тау шууларны дача алыштыра. Гөлнара Ринат кызы анда бакча эшләреннән соң яраткан шөгыле – бәйләмәнә утырачак. Бу эш турында ул үзе: «Уй-фикерне дә тәртипкә сала, тынычландыра да, гомумән, хатын-кыз үз куллары белән нәрсә дә булса эшли белергә тиеш бит инде», – ди.

«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ «Энергостанция» идарәсе склады мөдире Ольга Ланцова (уңнан икенче).

ПАТРИОТ, ЭЗТАБАР ҺӘМ ГАП-ГАДИ ХАНЫМ

«Үзебез өчен эшләгән эшләребез безнең белән бергә үлә, башкалар өчен кылганнарыбыз мәңгелеккә кала». Альберт Пайкның бу сүзләрен «Хатын-кыз – ел үрнәге» номинациясендә җиңгән Ольга Ланцованың социаль челтәрдәге бер сәхифәсендә күрергә мөмкин. «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ «Энергостанция» идарәсенең склад мөдире ул, инде 15 ел артык «Нефтехимик» эзтабарлар отряды командиры да. Ольга үз юлын мәктәптә – тиктормас кызый булган чакта ук сайлаган. Әнә шул тынгысызлыгы бүген дә аңа эштән соң буш вакытларын ваемсыз гына ял итеп үткәрергә ирек бирми. Балачак тәэсирләре – иң истә кала торганнары, дип тикмәгә генә әйтмиләр. 16 яшендә үзенең беренче эзтабарлык экспедициясенә баргач, Ватан өчен гомерләрен биргән бихисап солдатларның шәхесләре ачыкланмаганын һәм әлеге билгесез геройларның кулларына винтовкалар тоткан килеш кадерсез ятуларын күреп шакката... Эзләү-казу эшләре белән ул инде 30 елга якын шөгыльләнә һәм, үзе әйтүенчә, сәфәрләре уңышлы тәмамланганда, әйтеп бетергесез дулкынландыргыч тойгылар кичерә:

– Тагын бер солдатның булса да казып чыгарылуы, димәк, аның туган ягына кайтарылуы һәм кешечә җирләнү мөмкинлеге дигән сүз-аның өчен, туганнары өчен иң әүвәл шатлык биләп ала күңелне. Әгәр янында шәхси әйберләр – документлар, хат яки медальон тапсак, тагын да көчлерәк хисләр кичерәбез. Ул чакта хәтта аның исемен торгызырга һәм сугышчының җәсәден туганнарына кайтарырга мөмкин бит. Соңгы солдат җирләнмичә торып, сугыш бетми ул...

«Нефтехимик» отряды эзтабарлары яу кырларында һәлак булган сигез йөздән артык сугышчыны табып чыгара. Ике батальон солдат, дистә еллардан соң булса да, сугыштан кайта алды. Егерме бер сугышчының исеме ачыкланып, уналтысының туганнары табылган. Һәлак булган һәм хәбәрсез югалган солдатларның мәетләрен табу, казып чыгару һәм җирләү өчен, отряд элеккечә елга ике тапкыр экспедициягә юл тота.

Бүген Ольга Николаевна тагын бер патриотик проектны тормышка ашыра – «Нефтехимик» эзтабарлар отрядының музеен булдыру белән шөгыльләнә. Бу аның өчен гади бер проект кына түгел! Анда эзтабарларның зур, фундаменталь хезмәте чагылачак, отряд алып кайткан һәм кешеләр бүләк иткән экспонатлар урын алачак.

– Кайбер әйберләрне без хәтта сатып та алдык, – ди проект авторы. – Әйтик, 1940 ел ахырында чыгарылган 1941 елгы календарьны күптән түгел сатып алдым. Ул вакытта совет гражданнары сугыш буласын белмәгән дә әле. Бу – чын, сирәк һәм бик кызыклы экспонат!

«Йорт – эш – йорт» режимында туктаусыз йөгереп йөрү шулкадәр үзенә суырып ала ки, кайчагында туктап, без ни өчен яшибез соң, дип уйларга да мөмкинлек калдырмый. Үз-үзен тыңлый һәм башкаларны ишетә белүче бу ике хатын-кызның тормышы хезмәт яки мавыгуның яшәү мәгънәсенә һәм бөтен гомерен биләгән эшкә әверелүен аңларга мөмкинлек бирә. Ә бу, үз чиратында, уңышларга рухландыра, тормышка дәрт өсти...

НИЖНЕКАМСКНЕФТЕХИМ

«КАЗАН ГИПРОНИИ-АВИАПРОМЫ»НЫҢ ТӨП КЕШЕСЕ

Борис Тихомиров,
«Казан Гипронииавиапромы»
компанияләр төркеме генераль директоры

ТАССРның атказанган машина төзүчесе, Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе, Россиянең Мактаулы төзүчесе Борис Тихомиров бу көннәрдә «Казан Гипронииавиапромы»нда һөнәри эшчәнлегенә 50 ел тулуны билгеләп үтә. Борис Иванович – бөтен гомерен Россия авиация сәнәгатенә багышлаган шәхес, безнең төбәктә иң хөрмәтле җитәкчеләрнең берсе, искиткеч зирәклек һәм сизгер күңел иясе. Аның идарә итү сәләте, тырышлыгы белән «Казан Гипронииавиапромы» АҖ компанияләре төркеме бүген Россиянең оборона сәнәгате комплексындагы әйдәп баручы проект-төзелеш оешмаларының берсе булып тора.

Борис Тихомиров – сугыштан соңгы еллар баласы, легендар предприятиенең яшьтәше дияргә мөмкин. Ул 1946 елның 8 маенда илнең төньяк тарафында – Коми АССРның Абезь бистәсендә туа. Балачактан ук үз алдына зур-зур бурычлар куя һәм мәктәптән соң Мәскәүгә укырга керә. Мәскәү энергетика институтының «Электропривод һәм сәнәгать җайланмаларын автоматлаштыру» факультетын тәмамлаган өметле яшь белгеч предприятиегә узган гасырның 70 нче елларында килә. 18 ел эчендә ул инженердан алып Гипронииавиапромның генераль директоры дәрәҗәсенә кадәр юл уза – башта инженер, өлкән инженер, төркем җитәкчесе, бүлекнең баш белгече була, ә аннары инде – баш белгеч, оешма башлыгы һәм директоры.

Борис Иванович предприятиене 1988 елның февраленнән бирле җитәкли. СССР таркалу һәм икътисади кризис нәтиҗәсендә Гипронииавиапром тарихының иң катлаулы чоры шул вакытка туры килгәндер, мөгаен. Зирәк җитәкче үз алдына предприятиене һәм аның оешкан коллективын саклап калу, белгечләрне эш һәм хезмәт хакы белән тәэмин итеп, тиңдәшсез кеше һәм фәнни потенциалны югалтмау бурычын куя. Шуңа күрә коллектив, предприятиене «давыллы туксанынчы еллар»-да саклап кала алган кеше буларак, Борис Тихомировка чын күңелдән рәхмәт белдерә. «Казан Гипронииавиапромы» хезмәткәрләре үз җитәкчеләренә карата эш вазыйфаларыннан, оешмадагы иерархиядән бик ерак торган аерым бер хөрмәт, чын ихтирам хисе кичерә. Нәкъ менә шушы кеше республикадагы төп предприятиеләрнең берсен саклап кала алды. Асылда бу оешма аның табып-карап үстергән баласына тиң, һәм Борис Иванович һәрвакыт предприятиесенә тугры булды һәм хәзер дә тугрылык саклый. Ул Татарстандагы оборона сәнәгатенә булышлык күрсәтү мәсьәләсендә зур эш башкарган, республика һәм ил җитәкчелеге белән берничә тапкыр шәхсән сөйләшкән шәхес булып тора һәм авиасәнәгать тармагында бик гадел рәвештә югары дәрәҗәдәге белгеч санала.

Бүген искиткеч ышанычлылыгы һәм киң колачлылыгы белән билгеле компанияне ул күп еллар дәвамында җитәкли. Борис Иванович бөтен вакытын үзенең туган-үскән предприятиесенә багышлап, аның символына, флагманына, иң төп кешесенә әйләнә. Аның предприятие үсешенә биниһая зур өлеш кертүе нәтиҗәсендә, бүген «Казан Гипронииавиапромы» АҖ абруйлы компанияләр төркемен тәшкил итә.

Авиация һәм техник базаларны яңарту, камилләштерү, чит дәүләтләр өчен Россия авиатехникасын ремонтлау буенча сервис техник үзәкләр булдыру һәм илебез авиасәнәгатендәге башка бик күп мөһим вакыйгалар аның исеме белән бәйле.

Предприятие башлыгы тырышлыгы белән 2012–2014 нче елларда «Иннополис» МИЗ объектларын төзү өчен проект һәм эш документациясе хәзерләнә. Борис Тихомировка һәм аның коллективына Казандагы Универсиаданың мөһим объектларын проектлау да ышанып тапшырыла: 400 дөнья аэропорты арасында World Airport Awards[1] премиясе яулаган «Казан» аэропорты; FINA Халыкара йөзү федерациясенең XVI чемпионаты уздырылган Россиянең иң эре спорт комплексларыннан берсе – Су спорт төрләре сарае; шулай ук Су спорт төрләре буенча дөнья чемпионаты уздырылган, спортчыларның тренировкалары өчен тәгаенләнгән «Буревестник», «Акчарлак», «Бостан» һәм «Олимп» бассейннары.

Борис Тихомиров җитәкчелегендәге «Казан Гипронииавиапромы» компанияләр төркеме 2010 елдан граждannar һәм сәнәгый төзелеш өлкәсендәге мәгълүмати модельләштерү (BIM[2]) технологияләрен үзләренең көндәлек гамәли эшчәнлегенә актив

Фото «Казан Гипронииавиапромы» компанияләр төркеме тарафыннан тәкъдим ителде

Реклама

[1] World Airport Awards – авиация тармагындагы иң объектив бүләкләрнең берсе.
[2] BIM – мәгълүмати модельләштерү технологияләре

кертә. BIM кулланып, төрле юнәлештәге 100 дән артык объектның проекты хәзерләнә. Компания тарафыннан «Алабуга» административ-эшлекле бинасын реконструкцияләү проекты, таможня терминалын, махсус икътисадый зона территориясе буйлап уза торган автомобиль юлларын һәм тимер юлларны, «Ford» заводларын, табаклы пыяла, капламалы пыяла һәм көзгеләр заводын, санитар-гигиеник кулланыштагы кәгазь, кысып ясала торган SMC/BMC[3] пыялалы полиэфир материаллар заводларын, МДФ, ДСП һәм ОСБ-плитәләр җитештерә торган заводның беренче өлешен төзү проекты эшләнә. Республика башкаласында компания эшләгән проектлар буенча «Көнбатыш Елга аръягы», «Магеллан», «Светлая долина» һәм башка торак комплексларының комплекслы төзелеш эшләре башкарыла. ТР Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, ТР Экология министрлыгы бинаалары h.б. иҗтимагый әһәмияткә ия административ бинаалар төзелә һәм реконструкцияләнә. Шулай ук Борис Тихомировның хезмәт уңышлары исемлегендә тиңсез реставрация һәм реконструкция проектлары бар, алар арасында – КФУның 26 объекты, шәһәр яны тимер юл һәм елга вокзаллары, сәүдәгәр Кекин йорты, Алафузов халык йорты, «Казанское подворье» торак комплексы, Рус православие иске обряд чиркәвенең кафедраль соборы комплексы.

Борис Иванович авиация сәнәгатенең танылган белгече, һөнәри берләшмәләр һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләре арасында иң тәҗрибәле, белемле кешеләрнең берсе булып тора. Борис Тихомировның игътибар үзәгендә – Бөек Ватан сугышы ветераннары, тыл хезмәтчәннәре, инвалидлар. Шефлыкка алынган мәктәпкә, инвалидлар җәмгыятенә, спорт командаларына һәм төрле чараларга ярдәм итү өчен, ел саен шактый зур акчалар бүлеп бирелә. Борис Иванович – тәҗрибәле җитәкче генә түгел, йөрәгә кушканга игелек кылучы чын хәйрияче дә. Әйтик, предприятие «Яңарыш» республика фондына бушлай ярдәм күрсәтте – Зөя утраушәһәрендә туганнар корпусын реконструкцияләү проекты, бернчә чиркәүне торгызу һәм мәчетләр төзү проектлары эшләнде. Борис Иванович җитәкчелегендә «Крылья Советов» паркын реконструкцияләү өчен эскиз һәм эш проектлары хәзерләнде.

Хөрмәтле Борис Иванович!

Сез һәрвакыт үзенчәлекле сыйфатыгыз белән аерылып тордыгыз: киләчәктә җитди нәтиҗә бирәчәк стратегик планлаштыру, үз алдыгызга һәм коллектив алдына еракка караган, киң колачлы бурычлар куя беләсез. Абруегыз тырыш хезмәт еллары белән яуланган, ә бүләкләр һәм титулларыгызның хисабы-саны юк. Туган илебезнең һәм республикабызның патриоты, тәҗрибәле олуг җитәкче, үз эшенең зур остасы, чын хезмәт сөючән һәм сизгер кеше – сезне күпләр нәкъ менә шундый дип белә. «Казан Гипронииавиапромы» компанияләр төркеме коллективы Сезне һөнәри эшчәнлек өлкәсендәге юбилеегыз белән котлый һәм алга таба да зур уңышлар, яңа ачышлар, очрашулар, бетмәс-төкәнмәс энергия, ныклы сәламәтлек һәм озын гомер тели!

КАЗАНСКИЙ ГИПРОНИИАВИАПРОМ ГРУППА КОМПАНИЙ

420127, Казан шәһәре,
Дементьев ур., 1
Тел. (843) 571-95-48,
факс (843) 571-96-56

[3] SMC/ BMC – составы сумала, төрле тутыргычлар, технологик өстәмәләр һәм ныклык бирә торган компонентлардан гыйбарәт кысып ясалган материаллар.

ФӘЙЗИЛӘР ДИНАСТИЯСЕНЕҢ АЛТЫН ТАҖЫ

Автор: Мөршидә Кыямова

Адәм баласы җир йөзенә игелекле гамәлләр кылып яшәр өчен, башкаларны сөендерер өчен яратыла. Әмма үзең фани дөньядан киткәннән соң да нәсел дәвамчыларың синең гамәлләреңөчен горурланырлык итеп яшәү, иҗат итү сәләте һәркемгә дә бирелмәскә мөмкин. Без бүген чын мәгънәсендә иҗат рухы яшәгән затлы нәсел турында сүз алып барырбыз...



Фәйзуллиннар (сулдан уңга): Җәүдәт Фәйзи, Фатыйма, Сәйдә (Сәгыйтьнең хатыны), кечкенә Гәүһәр, Сәгыйть, Мидхәт, ?, Шәүкәт, Кәримә (Мортазаның хатыны), ?, ? яисә Мөхәммәтгәрәйнең кызы.

Байтак популяр җырлар авторы, татар профессиональ җыр сәнгатен үстерүгә үзеннән саллы өлеш керткән, милли музыкаль комедия жанрына нигез салган композитор Җәүдәт Фәйзи хакында фикер йөрткәндә, аның киңкырлы шәхес, һәр нәрсәдән хәбәрдар, тирән белемле иҗатчы икәнен таныйбыз. Аның беренче татар дәреслекләрен язган мәгърифәтче Харис Фәйзуллинның улы булуын, унбиш яшендә тәүге драма әсәрен, шигырь, хикәяләрен язганын, журналист, югары белемле юрист, хокук өлкәсендә бай тәҗрибә туплаган белгеч икәнен яшь буын вәкилләре белми дә. Быел Җәүдәт Фәйзигә 110 ел тула.

Фәйзиләр нәселендә талантлы, төрле өлкәләрдә абруй казанган ир-атлар шактый. Казанның 167 нче мәктәбендә «Фәйзиләр династиясе» музее эшли. 2005 елда ачылган музейда атаклы нәселгә нисбәтле хатирәләр, аларның кул җылысын саклаган шәхси әйберләр шактый күп саклана. Биредә Фәйзиләр нәселенең вәкилләре – татарның классик драматургы Мирхәйдәр Фәйзи; Казанда нейрорентгенологлар мәктәбенә нигез салучы, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, профессор Мидхәт Фәйзи; Башкортостанның халык артисты, режиссер Рәфкать Фәйзи; ТРның атказанган энергетигы Шәүкәт Фәйзи, язмабызның герое – композитор Җәүдәт Фәйзи тормышы турында этрафлы мәгълүмат алырга мөмкин.

ЮРИСТЛЫКТАН – МУЗЫКАГА

Мирхәйдәр Фәйзи Җәүдәттә язучылык сәләтен иртә тоемлый. Заманында Гадел Кутуйга да энекәшенә ярдәм итәргә кирәклеген әйтә. Җәүдәт Фәйзи истәлекләрендә бу хакта мәгълүмат сакланып калган.

Язучылыкка Мирхәйдәр Фәйзи рухландырып җибәргән булса, музыка язарга аны композитор Василий Виноградов илһамландыра. Булачак яшь композитор аңардан сабаклар да ала. «Юриспруденцияне калдырыгыз. Ул сездән башка да яши алачак. Сезне музыка дөньясы көтә!» – ди Виноградов, егетнең үз-үзенә ышанычын арттырып һәм иҗат кыйбласына юнәлеш биреп.

Бала чагында Җәүдәт Фәйзи композитор булырмын, дип башына да китермәгәндер, чөнки галим әтисе музыка белән шөгыльләнүне җитди һөнәргә санамый. Музыка белән мавыгырга була, әмма тормышыңны музыка язып кына алып бару мөмкин түгел, дип фикер йөртә Харис Фәйзуллин. Шулай да Җәүдәт улының шигырь, хикәяләр язуын, гомумән балаларының эрудицияле, белемле булуын, музыка белән шөгыльләнүләрен хуплый, аларга һәрьяктан ярдәм итеп тора. Шигырьләр, хикәяләр, төрле мәкаләләрне Җәүдәт Фәйзи газета-журналларда «Букай» псевдонимы белән бастыра.

Әнисе Әсма абыстай бик матур җырлаган, диләр. Моңлылык композиторга әнисеннән күчкән. Ул балаларының музыкаль яктан зәвыклы булуларын теләгән. Югыйсә, иң авыр заманнарда, ачлык вакытында – 1923 елда – алтын бизәнү әйберләрен тапшырып, пианино сатып алмаслар иде. Әле кемнең пианиносын диген, алтын приискалар хуҗасы Дәрдмәнднекен!

«Музыка мәктәбе ябылса да, мин дәресләремне ташламадым. Ноталарны таный башлаган идем инде. Киң һәм зур кәгазь тасмага пианино клавиатурасы ясадым да, кирәк чакта аны өстәлгә җәеп: «До, ми, соль, фа, ля, до», – дип, әйттерәм генә. Бармаклар уйнаган була, авыз көйли. Соңгы вакытларда әти, кабинетыннан чыгып, мыек астыннан гына елмаеп, мине тыңлап тора.

Кышкы салкын көннәрнең берсендә әнием сөенечле хәбәр әйтте. Кыйммәтле әйберләрне сатып акча җыйганнар да, пианино алырга булганнар.

Менә ул бәхетле көн дә килеп җитте. Әтием: «Әйдә, улым!» – дип, йөк ташый торган чанага утырып, үзе белән каядыр алып китте. Ара якын гына икән. Ишегалдына кереп туктадык. Ифрат бай җиһазлы өйгә кергәч, Мәрьям ханым дигән мөлаем гына апа каршы алды.

...Пианиноны өйдән чыгарып, чанага утырттылар. Өстен киезләр, чыпталар белән капладылар. Әллә каян килеп чыккан дүрт дәү абзый безне озата килделәр. Пианиноны өйгә кертеп урнаштыргач, әти, парланган такталарын сөртеп, өске-аскы капкачларын ачып куйды. Эче алтынмыни! Ялт итеп тора. Болай да, тегеләй дә тартылган берсеннән-берсе нечкә кыллар, матур, ак башлы, йомшак чүкечләр. Суыктан кергәч уйнарга ярамый, берәр көн җылынырга, кибәргә тиеш икән. Күпкә түзгәнне, анысына гына түзәрмен инде аны...

Безне сөендерүенә шатланган әтием:

– Бу пианиноның кадерен белегез, балалар, яхшы итеп уйнарга өйрәнегез. Ул – шагыйрь Дәрдмәнд пианиносы, – диде».

Җәүдәт Фәйзинең бүгенге кардәшләре әлеге данлыклы уен коралының язмышы белән һәрвакыт кызыксынып, аны эзләүләре хакында әйтә. 1925 елда Харис Фәйзуллин гаиләсе Оренбургтан Казанга күченгәндә, пианино да килгән. Гадилә Шәүкәт (Җәүдәтнең энесе) кызы мәктәп музеена бүләк ителгән коралын дәү әнисенеке (Әсма абыстайныкы) икәнен әйтә. Башка туганнары да әлеге пианиноны заманында Дәрдмәнд гаиләсеннән сатып алынганга охшаган, диләр. Хак җавап-

Фотолар Җ.Фәйзинең шәхси архивыннан һәм ТР Милли музей фондыннан алынды

ны белгечләр тикшергәннән соң гына алырга мөмкин булачак... Гәрчә композитор үзе Оренбургтан Казанга күченгән вакытын тасвирлап, «Күңелем кыллары» китабында бу хакта болай ди: *«Бөтен өй җиһазларын агач ящикларга тутырып вокзалга илтеп тапшырдык, пианино белән велосипедны илткәндә мин дә атка утырып бардым. Иң кадерле әйберләр – шулар ич».*

«ДЖОНКА»НЫҢ БАЛА ЧАГЫ

Җәүдәт Фәйзи урта мәктәпне Казанда тәмамлый, әсәрләр язуын дәвам итә, тәрҗемәләр ясап, акча эшли. Беренче драма әсәре – «Күз яшьләре» – унбиш яшендә язылып, 1928 елда Оренбург театрында куела. Дуслары Җәүдәтне «Джонка» дип йөрткән. Мидхәт Фәйзуллин күренекле энекәше турында китап яза. Әмма 1990 елда бакыйлыкка күчкән табибның истәлекләр китабы әле бүген дә нәшер ителмәгән. Әлеге истәлекләрдә ул композиторның тулы тормышын яктырта. Җәүдәт бала чактан тапкыр, эзләнүчән була, радиотехника, фотография белән шөгыльләнә. Нәсел дәвамчылары Җәүдәт Фәйзинең гипнозлау сәләтенә дә ия булганлыгын әйтәләр. Теш сызлавыннан интегүчеләр аңа чиратка баса торган булган. Йортларында электр кыңгыравы ясаган, мондый шәп җайланмага хәтта Шамил Усмановлар гаиләсе дә кызыккач, егет аларга да ясап биргән. Харис Фәйзуллин алдынгы карашлы татар буларак, 1923 елда гаиләсенә кинопроектор сатып ала. Кино сәнгате белән мавыгулар башлана, Җәүдәт тә кинематография институтына керергә омтылыш ясый...

«Я Раббым! Бармы икән син? Әгәр дә дөньяда хакимлек итәсең икән, миңа миһербанлык күрсәтеп, бәхетле язмыш насыйп итсәң иде. Хезмәтләрем белән танылган кеше буласым килә. Үз байлыгын кайгыртып, башкаларны алдаучы сәүдәгәр ясама миннән, чәркәханәләрдән ерак кыл. Халкыма хезмәт итәргә мөмкинлекләр ач, каһарман гамәлләр кылырга насыйп ит!»

Җәүдәт бу юлларны үсмерлек чорында көндәлегенә язып куйган. Аллаһыдан ялварып сораган теләкләре чынга аша егетнең. Ул Мәскәүдә оештырылган татар опера студиясендә Салих Сәйдәшев, Фәрит Яруллин, Нәҗип Җиһанов һәм Муса Җәлил белән бергә укый. Җәмәгатьчелек Җәүдәт Фәйзине композитор буларак таныганда, аңа нибары 22 яшь була.

Җәүдәт Фәйзи. 1940 ел.

«Менә хәзер борчылып утырам, ничек чыгар инде? Кичәнең официаль бүлеге Фатих Мөсәгыйтьнең ялкынлы докладе һәм замандашларының бер-ике истәлек сөйләве белән бетте. Концерт бүлегендә Һади Такташның «Күмелгән кораллар» һәм «Камил» драмаларыннан өзекләр күрсәтелде, шигырьләре укылды. Шагыйрьләр Х. Туфан, Б.Сирин һәм Ф.Кәрим аңа багышланган әсәрләре белән чыктылар, артист Хәким Сәлимҗанов искиткеч осталык белән Һади Такташның «Киләчәккә хатлар»ын укыды. Шушы әдәби номерлар арасына музыкаль әсәрләр дә кертелде. Фәйзулла Туишев үзенең гармуннарында, Заһид Хәбибуллин скрипкада Такташ яраткан көйләрне уйнадылар. Җырчылар Салих Сәйдәшевнең әсәрләрен башкарды. Шул исәптән Ситдыйк Айдаров «Син – дошманым...»ны, Абдулла Сәгыйтов «Байрак тегәбез»не, Галия Кайбицкая «Урман кызы»н җырладылар. Мин ул әсәрләремнән күбрәкне көткән идем. «Урман кызы»ннан башкаларын тыңлаучылар бик сүлпән кабул иттеләр. Үземне: «Яңа форма әсәрләр шул, аңлап бетермиләр...» – дип тынычландырырга тырыштым. Аның каравы, кичәдән соң вешалкада «Урман кызы»н көйләгән тавышларны һәм «Бик матур», «Бик шәп!» дигән сүзләрне ишетеп куандым.

Өйгә кайткач, дүртебез бергәләп чәй эчтек. Мөсфирә белән әнием җырларымны, бигрәк тә «Урман кызы» дигәнен, яратканнар. Әтиемнең күңеле күтәренке. Ул: – Шундый зур кешеләр рәтеннән өч мәртәбә исемең әйтелү – үзе генә дә бик мактаулы эш, улым! – диде».

«Язучылар арасында – музыкант, музыкантлар арасында – язучы», – дип әйтәләр Җәүдәт Фәйзи хакында. Ул йомшак күңелле, зыялы кеше булуына карамастан, үтә дә таләпчән, үз фикерен анык, төгәл җиткерә белү сәләтенә ия була.

Җәүдәт Фәйзи радиокомитетта музыка редакторы, Татар дәүләт академия театрында музыка бүлеге мөдире, Татар дәүләт филармониясенең директоры һәм сәнгать җитәкчесе булып эшли, фольклор кабинетын җитәкли. Композитор концерт эшчәнлеге белән дә шөгыльләнә, республика буйлап гастрольдә йөри. Ул татар драматургиясенә яңалык алып килә: 1942 елда татар музыкаль комедия җанрындагы әсәр иҗат ителә. «Башмагым» спектакле заманында озак еллар опера сәхнәсендә уйнала, хәзер инде ул театр репертуарында юк. Ләкин драма театрларында бу әсәр уңышлы бара. Милли музейда Җәүдәт Фәйзинең архивы белән танышканда, авторга бүләк ителгән акча (совет чоры акчалары) килеп чыкты. Аны «Башмагым» премьерасыннан соң, Җиһан әби (опера җырчысы – Мәрьям Рахманкулова) тапшырган. Әлеге истәлекле бүләк тә конвертка салынган килеш саклана. Конверт тышына «1942 ел» дип язылган.

КОМПОЗИТОРЛАР АРАСЫНДА – ЯЗУЧЫ

«Язучылар арасында – музыкант, музыкантлар арасында – язучы», – дип әйтәләр Җәүдәт Фәйзи хакында. Ул йомшак күңелле, зыялы кеше булуына карамастан, үтә дә таләпчән, үз фикерен анык, төгәл җиткерә белү сәләтенә ия була. Бу сыйфаты 1929–1933 нче елларда Казан дәүләт университетының юридик факультетында укыган чакта формалашкан булса кирәк. Аның оста оратор булганын замандашлары әле бүген дә хәтерли.

Җәүдәт Фәйзи милләт өчен әһәмиятле «Халык җәүһәрләре», «Күңелем кыллары», «Музыкаль кичәләр» китапларын яза. Бу китаплар чын язучылар рухында иҗат ителгән. Юкка гына классик язучы Әмирхан Еники: «Безнең татар композиторлары арасында ул татарча яза белгән бердәнбер кеше дисәм, һич тә хата булмас, минемчә», – димәгән.

«Халык җәүһәрләре» китабында 235 музыкаль әсәр урын алган. Әсәрләренең тексты һәм нотасы урнашты-

рылган. Биредә ул фольклорчы буларак ачыла.

«Күңел кыллары» китабында кечкенә хикәяләр урын ала. Анда ул бала чактан күзәтүләрен оста итеп гәүдәләндергән. Китапта татарның күренекле вәкилләре Мирхәйдәр Фәйзи, Шамил Усманов, Гадел Кутуй, Шәриф Камал һәм рус язучылары Максим Горький, Владимир Маяковский кебек даһилар белән очрашу мизгелләре тасвирлана, шулай ук әдип-композитор үз истәлекләрендә Казандагы тарихи вакыйгаларны да тасвирлый.

«Музыкаль кичәләр»ен автор сәнгать әһелләренә багышлый. Радиода музыкаль редактор булып эшләгән вакытта очрашкан шәхесләр турында бәян итә.

«Кызыклы кунаклар» – балалар өчен иҗат ителгән шигъри әсәре бүген дә яратып укыла. Оркестрдагы уен кораллары белән автор балаларны мавыктыргыч итеп таныштыра. Аның әлеге әсәре рус теленә тәрҗемә ителеп, Мәскәүдә дә дөнья күрә.

ХАЛЫК ЯРАТЫРЛЫК МУЗЫКА ЯЗУ – НАМУС ЭШЕ

Публицистика, драматургия, прозада уңышлы эшләп килгән Җәүдәт Фәйзине музыкаль таланты тулаем бөтереп ала. Җәүдәт Фәйзи гади җырдан җитди әсәрләргә күчеп иҗат итә башлый.

Музыка белән шөгыльләнүе шаяру кебек кенә башланган булса да, тормышының мөһим өлешенә әверелә. Композиторның 300ләп җыры исәпләнә, 1 опера, 3 оперетта, 30лап театраль куелышларга, балетка музыка иҗат иткән ул.

«...Минем һөнәрем дә бит шул табигатьтә булган тавышларның иң матурларын җыю. Шагыйрьләребезнең оста әйтелгән сүзләрен көйләргә тезү, музыка язу. Дөресен әйтергә кирәк, иптәшләр, җыр язу, кешенең җанлы тавышы белән башкарыла торган музыка әсәрләре язу – бик авыр эш. Ике-өч кенә минут эчендә башкарыла торган бу кечкенә музыка әсәрләрендә көйнең йөрәккә ятышлы булуы да, әсәрнең эчтәлеген ачарга ярдәм итә торган ритмика һәм гармониянең ачык булуы да, формасының камилләшкән булуы да төп шарт булып тора. Моның өчен композитор эзләнергә тиеш. Талантының бөтен нечкә осталыкларын казып чыгара белергә тиеш, шул вакытта гына без язган җырлар халык көйләре кебек матур яңгыраячак. Һәрбер композитор өчен халык таләпләренә җавап бирә торган әсәрләр иҗат итү – аның намус бурычы».

Бер төркем иҗат әһелләре: композитор Александр Ключарев, шагыйрь Муса Җәлил, музыкант Х.Гобәйдуллин һәм композитор Җәүдәт Фәйзи.

Композитор Җәүдәт Фәйзи һәм Нәҗип Җиһанов (рояль артында).

ТАССР композиторлары.

ЯКТЫ МОҢГА ИЯ КОМПОЗИТОР

Җәүдәт Фәйзинең музыкаль әсәрләре лиризм белән сугарылган. Күңелгә ятышлы җырларын без милли, үзенчәлекле интонацияләр аша ишетәбез.

«Җәүдәт абый гаҗәеп кеше иде. Аның белән гомеренең соңгы елларында очраштык. Шулай килеп чыкты инде, без бик соң гына таныштык, әмма абый миңа бик нык тәэсир итте. Ул бик ипле, йомшак күңелле, ягымлы кеше иде. Очрашканда кысып кочаклап ала, әйтерсең лә соңгы тапкыр кочаклый, аның кочагында эреп китәсең. Бармаклары юан, музыкантныкына охшамаган. Ул үзе дә тәбәнәк, юантык гәүдәле иде. Ә хатыны Мөсфирә апа чын фикердәше, сердәше иде. Абыйның шатлыгын да, кайгысын да уртаклаша белде. Композиторга иҗат итү өчен бөтен шартларны тудырып торды, көчен кызганмады. Озын буйлы, гаҗәеп чибәр, акыллы хатын-кыз буларак күңелемдә саклана. Бер-берсен тулыландырып, бер-берсен яратып, хөрмәт итеп яшәделәр. Җәүдәт абый рояльдә уйный башласа, музыка дөньясына кереп чума торган иде. Үз тирәсендә берни күрми, берни ишетми... Аның музыкасы да ма-

Флера Сөләйманова, Татарстанның халык артисты:

– Җәүдәт абый искиткеч шәхес иде. Без аның белән радиода эшләгәндә таныштык. Хатыны Мөсфирә апа да гел мөләем, тыйнак, чибәр, уңган хатын-кыз буларак күңелемә кереп калган. Мөсфирә апа шул заманнарда радиодан яңгыраган һәр җырчыны таный иде. Ире «Һаман истә» җырын иҗат иткәч: «Бу җырны яңа тавышка җырлатасы иде», – дип әйткән. Нәкъ шул вакытта радиодан мине җырлаталар икән. Җәүдәт абый хатыныннан: «Бу кем җырлый?» – дип сорый. Мөсфирә апа: «Флера Сөләйманова җырлый», – дигән. Менә шуннан соң мине Җәүдәт ага үзләренә чакырды, ул вакытта мин Усман Әлмиев бригадасында җырлый идем. Усман абый белән композитор яшәгән йортка киттек. «Һаман истә» җырын радиода яздырдык, әлеге әсәр зур популярлык казанды. Ул заманнарда Җәүдәт Фәйзине белмәгән кеше сирәк булгандыр, бик танылган шәхес иде ул! Иҗатын да гел халыкка чыгарып тордылар. Ул киң колач белән иҗат итте, ә хатыны нык булыша иде. Мин аларда еш кунак булдым. Шәхсән үземнең югары музыкаль белемем булмагач, үзем аралашкан композиторларымны укытучы дип атыйм. Җәүдәт Фәйзи – ул минем укытучым. Җырларны тиз отып ала торган идем. «Халык җәүһәрләре» китабын әзерләгәндә мин аңа бик күп халык җырларын әйтеп тордым. Ул чакларны бик күп эшләдек без аның белән. Кешелекле, тырыш, сабыр, мәхәббәтле шәхес буларак күңелемдә саклана ул минем.

Виктор Фәйзуллин, опера җырчысы, Мидхәт абыйсының оныгы:

– Җәүдәт Фәйзи җитәкчеләр өчен «уңайсызрак» кеше булган. Мәңгелек бәхәсләр, ныклы позиция, үз фикереңне яклау, гаделлек хисе, – берсе дә аңа тынычлык бирмәгән... Барысын да йөрәгеннән уздырган. Шуңа да ул якты дөньядан иртә китеп барган... Аның дошманнары, көндәшләре күп булганы да мәгълүм. Шомлы елларда өстеннән донослар да язганнар. Җәүдәт абыйга, «төрек шпионы» тәгъллеген раслап, берничә тапкыр аңлатма язарга да туры килгән. Җәүдәт Фәйзинең әтисе Төркиядә белем алган укымышлы, алдынгы карашлы, зыялы кеше, югыйсә. Улы үзенең шәҗәрәсендә моның өчен акланырга мәҗбүр була. Ә бит композитор әтисе белән, киресенчә, горурланып яшәргә тиеш иде... Җәүдәт Фәйзи гомеренең һәр минутын кадерләгән, тыңгысыз иҗатчы булганын көндәлекләреннән укып белергә мөмкин. Аның көндәлекләрендә мондый юллар бар: «Рәссам минем портретны ясый. Утырам, позировать итәм. Вакытым бик кызганыч...» Димәк ул һәрвакыт иҗатта булган, милләтенә хезмәт итүне өстен күргән.

Бату Мулюков, композитор:

– Республикабызда җыр сәнгатенең «Җәүдәт Фәйзи чоры» булып алды, дияргә мөмкин. Үз заманында аның җырларын башкармаган бер генә җырчы да, аның әсәрләре кермәгән бер генә концерт программасы да юк иде. Төрле спектакльләргә язылган музыкалар композиторның иҗатында шулай ук зур урын алып тора. Ул үз гомерендә 20дән артык спектакльгә музыка язды. Алар мөстәкыйль музыка әсәрләре булып та таралды. Тамашачыны, тыңлаучыны нык тетрәткән әсәрләренең берсе – Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры» спектакленә язылган музыкасы. Андагы «Фатыйма арышларын» яки Басыйрның «Җырга салып җибәргән хаты»н дулкынланмый тыңлап буламы?! Таҗи Гыйзәттнең «Ташкыннар»ыннан Гайнавал җыры кайсыбызның колагында яңгырап тормый? Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ына язылган «Сәрви җыры»да зур сәнгать әсәренә хас эзләнү белән эшләнгән. Бу иҗади уңыш композиторны тагын да яңа әсәрләр язарга рухландырды һәм татар музыкасында булачак «җиңел музыка» өлкәсенә нигез салган классик әсәр «Башмагым»ның иҗат ителүенә китерде. Әлеге музыкаль комедиясе белән композитор татар музыкаль сәхнә әсәрен генә тудырып калмады, күпмилләтле совет тамашасының алтын хәзинәсенә дә яңа рухи байлык өстәде!

Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары. 1966 ел.

жорлы. Ул үзе дә мажор (якты) кеше иде. Кешеләрне яратып яшәде. Тормышында зур кайгы-хәсрәтләр кичерергә дә туры килде аңарга. Гомеренең кыска булуы да шуңа бәйледер күрәсең... », – дип искә ала композиторның туганы **Фирүзә Фәйзуллина.**

Халыкчан, шул ук вакытта яңа яңгырашлы аһәңнәргә бай, заманча булуы белән тамашачыны җәлеп иткән әсәрләр авторының гомере, чыннан да кыска була. Шулай ук ике улы – Лирам белән Фидальнең дә гомерләре иртә өзелә. Ә инде берданбер кызы Лилиананы бала чагында ук җир куенына тапшыралар. Турыдан-туры варислары калмаса да, Җәүдәт Фәйзинең туганнары хәзерге вакытта бердәм. Аның исеме Фәйзиләрне бер йодрыкка туплап тора.

«Җәүдәт Фәйзи – үз нәселендә мәгърифәтчелек традицияләрен дәвам итүче. Ул татар музыкасын танытучы. Төрле аудиторияләрдә лекцияләр укыган, мәкаләләр язган, радиода тапшырулар эшләгән, фольклор экспедицияләрен җитәкләгән. Кызганыч, быел аның 110 еллык юбилее уңаеннан зур күргәзмәсен оештырып булмады. Музей архивларында саклаучы әсәрләрен дөньяга танытасы иде. Музыкаль мирасын, әсәрләрен заманча дискларда кабат яздырасы иде. «Халык җәүһәрләре», «Күңелем кыллары», «Татар халык көйләре» китапларын кабат нәшер итәсе иде. Иң кыйммәтлесе: композиторның Милли музейда рояле саклана. Без, туганнары, әлбәттә, шушы данлыклы рояльнең бүгенге көндә дә халыкка хезмәт итүен телибез. Аны фондтан чыгарып, яшь музыкантлар хозурына куеп, җыр, моң кичәләрендә әлеге рояльдән Җәүдәт абый әсәрләре яңгырасын иде», – ди туганы, Фәйзиләр мирасын актив барлаучы, популярлаштыручы Диләрә Мөхәммәдиярова.

КОМПОЗИТОРНЫҢ БАЙ ФОНДЫ – МИЛЛИ МУЗЕЙДА

Татарстан Милли музее фондында, әйткәнемчә, Җәүдәт Фәйзинең бай архивы тупланган. Әлеге материалларны 1973 елда, композиторның вафатыннан соң, хатыны Мөсфирә Фәйзуллина тапшыра. 1998 елда да әле ул тагын 30 берәмлек ядкарьне шулай ук мирасханәгә бүләк итә. Дәүләт карамагында җәмгысе 4000 берәмлек саклана. Болар – төрле документлар, ноталы материал һәм китапханә. Бу – бик бай һәм үзенчәлекле мирас, аны композитор гомер буена туплаган. Арада әдип-композиторның үз кулы белән язылган берничә автобиографиясе, култамгалары куелган шәҗәрәләре, хатлары, көндәлекләре һәм истәлек дәфтәрләре бар. Нәшер ителгән китаплары, магнитофон тасмалары, фольклор экспедицияләрендә тупланган материаллары зур кыйммәткә ия. Биредә аның кул җылысын саклаган шәхси әйберләре дә тора: кәнәфи, диван, урындыклар һәм рояле.

Архивта шулай ук композиторның Гадел Кутуй повесте буенча эшләнгән «Тапшырылмаган хатлар» ораториясенең партитурасы, «Авыл укытучысы көндәлекләре» дигән дөньяга чыкмаган кулъязмасы бар. Биредә шулай ук Фәтхи Борнашның әсәренә язылган «Кызыл чәчәк» операсының клавирын да күрергә мөмкин.

Татарның музыкаль дөньясына битараф булмаган белгечләргә, сәнгатькәрләргә мирасханәдәге Габдулла Тукайның «Кара Әхмәт» әсәренә язылган тәгәлләнмәгән балетын өйрәнү дә кызыклы булыр иде.

Бу – үзе бер аерым, мөстәкыйль музей булырлык бик зур фонд. Кызганычки, архивтагы материаллар цифрланып бетмәгән, якындагы ике елда башкарылмаячак та әле. Ләкин Милли музейда «100 еллыкка – йөз исем» проекты эшли. Аның нигезендә республиканың күренекле вәкилләре турында күргәзмәләр циклы ел дәвамында тәкъдим ителәчәк. Шул уңайдан, күренекле композитор Җәүдәт Фәйзинең бай, әтрафлы иҗаты, экспонатларының бер өлеше дә халык хозурына чыгачак, дип ышандыра музей әһелләре.

БИОГРАФИК БЕЛЕШМӘ

Җәүдәт Фәйзи 1910 елның 4 гыйнварында Оренбург шәһәрендә мәгърифәтче гаиләсендә туа. Ул башлангыч музыкаль белемне С.Сәйдәшев директор булып эшләгән музыка мәктәбендә ала.

1934 елда Мәскәү консерваториясе каршында Татар опера студиясе ачылгач, Җәүдәт Фәйзи студиянең уку бүлеге мөдире итеп җибәрелә. Административ оештыру эшләре белән бергә, ул биредә Б. Шехтердан композиция классында дәресләр ала, шулай ук Г. Литинскийның консультацияләреннән файдалана. 1938 елда Җәүдәт Фәйзи Казанга кайта. Биредә ул музыка һәм җәмгать эшләрендә актив катнашып, радиокомитетта музыка редакторы, Татар дәүләт академия театрында музыка бүлеге мөдире, Татарстан филармониясенең директоры һәм сәнгать җитәкчесе булып эшли.

Җәүдәт Фәйзи – РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

Композитор 1973 елның 2 маенда бакыйлыкка күчә.

75 ПОБЕДА! 1945–2020

Сугыш чоры балалары... Алар күргән нужа, газаплы кәгазь битенә генә язып бетереп булмыйдыр. Шулай да...

Бөек Җиңүнең 75 еллыгын каршыларга җыенганда, без аларны барларга, бер мәлгә булса да, ул елларны күз алдына китерергә тырыштык. Юк, бу өлкәннәр өчен генә түгел, бу, иң беренче чиратта, безнең үзебез өчен мөһим.

Алар кичергән фаҗига шәүләсендә бүгенге тормышыбызның кадерен белү, шөкер итү өчен кирәк...



ОКОПЧЫ КЫЗ

1941 елның 22 июнь таңы тыныч кына яшәп яткан һәр гаиләнең тормышын астын өскә китерә. Ирләре фронтка китү сәбәпле, хатын-кызлар тормыш дилбегәсен үз кулына ала. Бала-чага да тик кенә утырмый, әби-бабай, әниләре тирәсендә кайнаша. Ә үсмерләргә исә аерым таләп куела – дәүләт заказын үтәү. Шундый заказның берсе – окоп казу. Бөек Ватан сугышы тарихына күз салсак, 1941–1942 еллар аеруча зур югалтулар белән истә кала. Советлар Союзы сугышка әзер булмый. Фронтта корал җитешмәсә, тылда хәтта көрәк, лом кебек эш коралларына кытлык була. Шулай да төркем-төркем яшьләрне окоп казырга җибәрәләр... Шул көннәрнең шаһиты булган Мәрзия Габдрахманова белән очрашып, аның хатирәләрен тыңладык.

Автор:
Руфия Фазылова

Фото: Александр Ефремов

кинлек туачак...», – диде. Шулай итеп, әтәчләнеп барган ир-атлар, хатын-кызлар, барысына да риза булып, җыелыштан таралышты...

Район вәкиле рәхәт тормыш вәгъдә итсә дә, алай сөйләгәнчә рәхәт булып чыкмый. Үз көнен үзенчә күргән халыкка зур-зур планнар куялар. Яңа власть хәтта балалар турында да онытмый.

– Сигез тулганда укырга кердем, шул елны басуга да чыгардылар, – диде Мәрзия апа. – Мәктәптән соң көн саен биш бала, берәр капчык башак җыеп, кохозга тапшырырга тиеш идек. Тагын әле безнең бурыч – житен, ясмык йолку да. Бер көн эшләгән өчен ярты кило ипи бирделәр. Әниләрнең исә эше тагын да тыгыз иде – ай яктысы белән басуга чыктылар. Бригадир төнлә белән: «Фәлән звено китте инде, әйдәгез, – дип, урам тәрәзәләрен кагып йөрде. Без, бала-чагалар, өйдә калабыз, сыер савып, көтү куабыз. Кояш чыкканда әниләр эшләп арган була инде.

Алар гаиләдә ике кыз үскәннәр. Мәрзия апа – 1923 елгы, аңа кадәр дөньяга килгән ике ир туганы үлгән. «Шундый авыр заманда – ачлыктан соң тугансыз икән», – дидем, шул елларга басым ясап әңгәмәдәшемә.

– 1921 елгы ачлыкта урамда ике генә гаилә – без һәм сатучылар гаиләсе калган. Калганнар җыелышып Себергә киткән. Каршыда сукыр бер карчык яшәгән, күршеләр аны да ашаткан. Әти белән әни, киткән кешеләрнең бакчаларыннан алабутаны җыеп, сугып, шуны тирмәндә тарттырганнар. Әти аннан соң алабута онын Чувашиягә алып барып, ак онга алыштырып кайткан. Әни: «Атагыз егет булды, нинди авыр елда да ачлык күрмәдек», – дия иде. Әти безнең бик тырыш кеше иде, күмер яндырып та саткан.

«УЛЫМНЫ ЮГАЛТТЫМ...»

Мәрзия апа Апас районының Түбән Барыш авылында туган. Бүген район үзәгендә, ветераннар өчен төзелгән йортта ялгызы яши. 96 яшен тутырса да, сәламәтлеге, акылы сокланырлык. Мәрхүм тормыш иптәше Габделхәй ага белән 8 бала тәрбияләп үстергәннәр. Ни кызганыч, Апаста яшәүче улы күптән түгел вафат булган икән.

– Бала хәсрәте бик яман икән. Илнат улым үлгәннән соң, бик нык бетерештем, – диде ана кеше.

Мәрзия апаның бер бүлмәле фатиры якты. Тәрәзә төбендә гөлләр шаулап чәчәк атып утыра.

– Гомер буе үз өе белән яшәп өйрәнгән кешене, картлык көндә туган авылын ташлап, күпкатлы фатирда яшәргә нәрсә этәрде? – дим.

– Фатир бирделәр дә, күчендем инде. Миңа Апас чит як түгел бит, Түбән Барышта торганда эш буенча ике көннең берендә монда идем. Сырхауханә, кибетләр – барысы да якын гына. Авылдан күченү авыр булмады...

Хәер, Мәрзия апа Түбән Барышын ташламаган, еш кайтып йөри икән. Төп йортта улы белән килене калган.

– Үземне үзем йөрткәндә, була әле, кызым, – дип дәвам итте әңгәмәдәшем сүзен. – Монда рәхәт, якты, икенче кат, әйбәт этаж туры килде. Күптән түгел шифаханәдә ял иткән идем, кызлар кайтып, яңа обойлар ябыштырганнар. Миңа сюрприз ясаганнар. Әле дә ярый күп бала алып кайтканбыз, дим... Илнат улым көн саен диярлек килеп хәлемне белә иде. Кисәк кенә үлеп китте шул. Рәхмәт, балалар ташламый, кызлар да кайтып йөри, Апастагы килен дә еш килә.

Мәрзия апаны Апас кешеләре дә үз иткән инде, күпләр белә аны. Коръән ашларына чакыралар. (Намазда ул). Без барында: «Ак әбиебез ул», – дип, күршеләре Зөһрә кереп чыкты. Ризык пешерсәләр дә иң беренче күрше әбиләренә алып керәләр икән.

ПЛАН БУЕНЧА ЯШӘҮ

Мәрзия апа күмәкләшү чорыннан башланган вакыйгаларны, фаҗигаләрне хәтерли. Колхозлар оешканда аңа җиде яшь була. Әти-әнисе белән җыелышка ияреп барганын аеруча кызык итеп искә алды:

– Районнан кешеләр килгән иде. Әти белән әни, башкаларга ияреп, җыелышка барды. Юлда хатын-кызлар ирләренә акыл өйрәтә: «Җирләрне алсалар да, атларны бирмибез диегез!» Тик районнан килгән вәкил бик оста сөйләүче булып чыкты: «Хатын-кызларның эше бермәбер җиңеләячәк, тегү машиналары кайтачак. Күмәк хезмәт булганда, дәүләт ярдәме белән иген уңышын да арттырырга мөм-

ДҮРТ СӘГАТЬ ВАКЫТ

Мәрзия Габдрахманова Бөек Ватан сугышы башланган көнне бик яхшы хәтерли. 1941 елның 22 июнен буй җиткән кыз Апаста каршы ала.

– Ул заманда, бәби табуга, хатынкызларны эшкә чыгаралар иде, – диде Мәрзия апа. – Апа бәби тапкач, аның урынына эшкә мин киттем. Без, алты хатын-кызны, бер атнага дип Апаска – юл ясарга җибәрделәр. Хәтерлим, бик матур кояшлы көн. Без яшәгән йорт хуҗасының ун яшьлек малае яныбызга йөгереп килде: «Авылда Сабантуй таралган, сугыш башланган!» – диде. Ул да түгел, халык ыгы-зыгы килә башлады. Шул көнне кичке унбергә хәтле атка, машиналарга төялгән ир-атларны сугышка озаттык. Халык елаша, уфтана... Чури-Бураштан Миңсылу исемле бер хатынның өзгәләнүе әле дә күз алдымда тора: иренең кулына ябышкан, җибәрми. Үкерә-үкерә елый, көчкә каерып алдылар үзен. Янында бер кечкенә кызы бар, ул да ачыргаланып елый...

Мәрзия Габдрахмановага 95 яшь тулган көн. Балалары янәшәсендә.

Апаска юл эшләренә җибәрелгән кызлар анда көзгә хәтле эшли – көрәк белән дамба өяләр. Туган авылларына аларны сентябрь башында – иген җыюда булышу өчен алып кайталар. Һәм буй җиткән кызлар октябрь башына кадәр ындырдан кайтып керми.

– Һич онытмыйм, бер яңгырлы көндә, уч төбе хәтле кәгазь тотып, өйгә авыл советы председателе килде, – дип, истәлекләре белән бүлешүен дәвам итте Мәрзия апа. – «Җыеныгыз, сезгә дүрт сәгать вакыт. Апаска окоп казырга барасыз», – диде. Һәм кулга теге язуын бирде. Укып карасам, исемлек икән: үзең белән запас киемнәр, кружка, кипкән ипи, башка кирәк-яраклар алырга дип язылган. Окоп казырга баручылар арасында илле сигез яшьлек эти дә бар. Авыру әнине ялгызын калдырып, авылның дүрт кызы, эти, тагын бер үсмер күрше малае белән Апаска чыгып киттек. Анда безне бер сәләмә генә йортка керттеләр. Иртән чыгып китәбез, кич кайтабыз. Кызлар, җыйнаулашып, идәндә йоклыйбыз. Юрган, мендәр ише әйбер юк инде, өскә кигән кәчтүмнәрне аска салабыз. Әти белән күрше малае сәкедә ята. Йорт хуҗасы, тәтә – мич башында, килене кечкенә баласы белән почмакта йоклый. Көзге яңгырлар, пычрак, аяклар юешләнә. Кигән киемне киптерергә, юарга мөмкинлек юк. Җир казып кайткач, үзебез белән алып килгән бәрәңгене пешереп ашыйбыз да, бөрешеп, йокларга ятабыз.

Тарихтан, аерым истәлекләрдән беләбез: Апаска окоп казырга күрше районнардан да килгәннәр. Аларны бригадаларга җыйганнар. Гадәттә бер төркемдә 24 хатын-кыз булган.

– Окопны өч метр тирәнлектә казырга кирәк иде, – диде Мәрзия апа. – Бер бригадага ике лом бирәләр, аның белән алмаш-тилмәш эшлисең, калганнар көрәк белән балчыкны алып тора. Ул елны көз җылы килгәндер, дип уйлыйм, чөнки кәчтүмнәрне салып эшләгәнебез истә калган.

Сугыш чоры балаларының кайсы белән сөйләшсәң дә, бет кыйссасын искә алмый калмыйлар. Окопчы кызлар да ул «җан иясләре» талаудан нык интегә. Окоп казырга килгәч, ике ай юынмый алар.

– Сез бит чит җирдә түгел, үз районыгызда эшләгәнсез. Мунча ягу өчен күп кирәкми, утын белән су юк идеме? Бер дә булмаса, туган авылыгызга кайтып булгандыр, – дидем, аптырап.

– И, нинди мунча ягу, ди... Беренчедән, без яшәгән йортта мунча юк иде. Икенчедән, су ташырлык түгел, өйгә кайтып егылырлык та көч калмый иде. Ә авылга ничек кайтасың. Анда бит армиядәге кебек: тиешле вакытында торасың, эшкә барасың, кайтасың...

«ФРОНТКА ҖИБӘРЕГЕЗ!»

Чүп өстенә чүмәлә, дигәндәй, бет өстенә корчаңгы афәте килә. Төне буе кашынып ятып, кызларның тәннәре бозыла. Окоп казучыларны Тәтешкә җибәрәләр икән, дигән хәбәрне ишеткәч, Түбән Барышның дүрт кызы район военкоматына китә: «Без үз теләгебез белән фронтка китәбез», – диләр. Тик бетле, корчаңгылы кызларны военкоматта кире боралар. Дүртесен бергә Апас район сырхауханәсенә җибәрәләр. «Бер атналап хәл алгач, яңадан килерсез», – диләр.

– Сырхауханәдә безнең тәнне зәһәр исле дарулар белән майладылар, – диде Мәрзия апа. – Ул елашабыз, өстәвенә үтереп ашыйсы килә. Атналар буе көнгә өч кешегә бер ипи ашап йөреп, хәлсезләнгән идек. Шәфкать туташы безгә әчкелт эремчек ашатты, кайнар чәй эчертте. Шулай итеп төнне үткәрдек. Иртән, врачлар килгәнче, сырхауханәдән чыгып качтык. «Авылга, әниләр янына кайтасы килә», – дигәч, санитарка ишекне ачып чыгарды. Менә шулай, өч ай михнәт күргәннән соң, туган нигезгә кайтып егылдык.

Тик кайтып озак та үтми, кызларны урман кисәргә җибәрәләр. Ә фронтка китү теләге тормышка ашмый кала. «Фронтка кеше җитә, ә монда эшләргә кеше юк», – диләр аларга.

Урман кисүче кызларга да план куялар – һәрберсенә биш кубометр агач егарга. Әлбәттә, арада ир-атлар да эшли, гадәттә алар фронтка бармаган, яки сугышта яраланып кайткан кешеләр була. Шулай берничә ай урманда эшләгәннән соң, кызлар янә туган авылларына кайталар.

– Чүри-Бураш авылында тракторчылар курсы ачылган икән, дигәч, мин шунда киттем, – ди Мәрзия апа. – Колхоз җитәкчесеннән рөхсәт алдым. Ул башта җибәрергә теләмәгән иде, аннары риза булды тагын. Колхозда эшләргә кеше юк иде бит. Тракторга бүтәннәр кебек өч ай укымадым, мин килгәндә курслар башланган иде. Ай ярымнан укуны тәмамладык. Теорияне алдыра алмадым, ә менә практиканы бишлегә тапшырдым. Алга, артка таба йөртүем дә дөрес иде, тракторны сүтеп җыя да белдем. Ирләрчә нык холкым, үткенлегем бар иде. Техникадан бер дә куркып тормадым. Трактор йөртү таныклыгын алуга, мине Апас районының Шонгаты авылына эшкә җибәрделәр. Зур «колесный» трактор бирделәр. Гадәттә төнге сменада эшләдем, чөнки әнине карарга кирәк иде. Әти көндез эштә булды, шулай чиратлаштырдык. Менә хәзер уйлап утырам: бер ялгызым – кырда, ничек курыкмадым икән? Бер якта – Үләмә елгасы, икенче якта – кап-кара урман. Батыр булганмын инде, ай-һай...

P.S. Чынлап та, батыр булган Мәрзия апа. Хәер, әле хәзер дә теле-телгә йокмый аның. Менә шул үткенлеге, батырлыгы аңа бүген дә көч бирә. Озын гомер телим ак әбигә. Балалар хәсрәте күрергә язмасын бүтән...

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Татар телен өйрәнү турындагы сорауга укучы **НИНДИ** җавап алган

Анатолий Марченко СССРдагы барлык сәяси тоткыннарны **НИЧЕК** азат итәргә теләгән

Камал театрының яңа бинасы **КАЙЧАН** төзелеп беткән

Емельян Пугачев һәм Бәхтияр Канкаев.

ХАЛЫКНЫ КҮТӘРГӘН ЯУ

Россиядә 1773–1775 нче еллардагы халык күтәрелеше җитәкчесе Емельян Пугачевның: «Патша Иван Васильевич Казан янында 7 ел торды, ә мин өч сәгать эчендә шәһәрне көлгә күмдем», – дип, 1552 елгы вакыйгалар белән чагыштырып әйткән сүзләре әлеге даталарның төбәк тарихы өчен никадәр әһәмиятле булуын ача кебек.

Автор:
Илшат Фәйзрахманов

Бәрелешләр булган урыннар картасы. 1774 елның 12,13 һәм 15 июль көннәре.

БАШ КҮТӘРҮНЕҢ БАШЫ

Түбән катламнарны дәүләт һәм аерым феодаллар тарафыннан крепостной изү көчәя барган шартларда, халыкның ризасызлыгы чиктән ашып, иртәме-соңмы баш күтәрүгә китерәчәге аңлашыла, билгеле. Ут кабынып китәргә очкын гына кирәк була, асылда. Баш күтәрү 1773 елның 17 сентябрендә Җаек казахлары арасында башлана. Емельян Пугачев үзен могҗиза белән генә исән калган патша Петр III дип игълан итә. Аның казахларына җирләр бирү, акчалата һәм икмәкләтә түләүләр кертү турындагы манифесты киң тарала. Тиз арада Пугачевның тарафдарлары арта, Җаек крепостен алалар, көзгә таба Оренбургка җитәләр. Баштагы чорда крестьяннар хәрәкәте хәзерге Оренбург өлкәсе, Башкортостан, Көнчыгыш һәм Көнбатыш Урал территорияләрендә бара. Урта Идел буенда баш күтәрүчеләрнең уңышлары хакындагы хәбәрләр киң тарала, халык арасында «Казанга да килеп җитәчәкләр икән» диган төрле сүзләр йөри.

ПУГАЧЕВ ЯВЫ – КОТЫЛГЫСЫЗ

Хөкүмәт восстаниене башыннан алып аяусыз бастырырга керешә. Хөкүмәт гаскәрләре иң беренче чиратта Пугачев җитәкчелек иткән баш күтәрүчеләрнең төп көчләре белән көрәшә, «ялган патшаны» әсирлеккә төшерергә, аерым отрядларның берләшүен булдырмаска тырыша. Халык кузгалышлары күзәтелмәгән Идел буе төбәкләре дә нык контрольдә тотыла. Казан адмиралтействосы күзәтчелегендәге йомышлы татар авылларында контроль тагын да кырыслана (шуңа күрә йомышлы татарлар арасында Пугачевка кушылучыларның саны аз була). Хөкүмәт гаскәрләре 1774 елның мартына фетнәченең төп көчләренә зур зыян салып, шулай ук берничә аерым отрядны тар-мар итеп, инициативаны үз кулларына алалар. Әмма баш күтәрүчеләргә яңадан-яңа отрядлар кушылып тора. Хөкүмәт гаскәрләре туктаусыз эзәрлекләгән шартларда Емельян Пугачев отрядлары да даими күченеп йөрергә мәҗбүр була. 1774 елның язында Пугачев Көньяк Уралдан төньякка – металл заводлары күп булган территорияләргә юнәлә. Монда аларга заводларда эшләгән күпмеңләгән эшче-крестьяннар кушыла. Әмма анда да озаклап торырга мөмкин булмый – Казанга юнәлергә карар кылына. 1774 елның июнь-июль айларында Пугачев отрядлары Уса, Алабуга, Сарапул, Мамадыш, Минзәлә, Зәй крепостьларын алалар – Казанга юл ачыла.

«ФЕТНӘЧЕЛӘР» КАЗАНДА

Емельян Пугачев гаскәре Казанга Арча юлы буйлап һөҗүм итә. Шәһәргә якынлашканда аның гаскәрендә 20 меңләп кеше исәпләнә. Аларның күпчелеген рус, татар, башкортлар тәшкил итә. Бәхтияр Канкаев җитәкчелегендәге 2 меңнән артык кешедән торган отряд Пугачев армиясенә 1773 елның декабрендә килеп кушыла. Алар Идел-Кама буенда шактый җирләрне контрольдә тоталар, Пугачев армиясен азык-төлек, фураж белән тәэмин итәләр. Казанның үзендә хөкүмәт гаскәрләре чагыштырмача аз: 1500 ләп гарнизон солдаты, шулай ук Адмиралтействодан, полиция, пожарниклардан 500гә якын саклаучы җыела, Казан гимназиясендә гимназистлардан, укытучылардан 74 кешелек корпус төзелә. Казан сукно мануфактурасы хуҗасы Иван Федорович Дряблов суконщиклардан шәһәрне саклаучы отрядлар оештырмакчы булып маташа. Татар бистәләрен анда яшәүчеләр үзләре сакларга тиеш булалар. Пугачевны эзәрлекләүче подполковник Иван Иванович Михельсон гаскәре Казаннан шактый ерак була әле. Шәһәр һәм губерна башлыклары өчен Пугачев явының Казанга якынлашуы көтелмәгәнчә тиз килеп чыга һәм аларның сакланырга әзерлекләре җитеп бетми.

1774 елның 11 июлендә Пугачев гаскәре белән Казаннан 7 чакрым ераклыкта Нокса һәм Царицыно авыллары арасындагы буйга сузылган шактый зур территориядә лагерь булып урнаша. Биредә Пугачев 3 манифест чыгара: 1. Казан губернаторына сугышмыйча гына бирелергә кушылган указ. 2. «Бөтен халык исеменә». 3. «Татарларга аерым мөрәҗәгать».

12 ИЮЛЬ ВАКЫЙГАЛАРЫ

12 июльнең таңында шәһәрне штурмлау башлана. Емельян Пугачев гаскәре 4 юнәлештә һөҗүм итә: Арча кыры ягыннан, Казансу елгасы буеннан, Сукно бистәсе һәм Татар бистәләре ягыннан. Берничә сәгать эчендә бөтен Казан диярлек баш күтәрүчеләр кулына күчә. Баш күтәрүчеләр печән кибәннәре алып килеп ут төртәләр. Җил уңае шәһәргә таба булганга, бөтен шәһәр, хөкүмәт гаскәрләре ут-төтен эчендә кала. Бик күп җирдә янгыннар чыга, шул исәптән пугачевчылар яклы Сукно бистәсендә 186 йорт яна (492 се кала). Татар бистәләрендә генә янгыннар булмый кала. Шәһәрне саклаучылар Кремль эченә кереп кача. Баш күтәрүчеләр Кремльне дә алырга омтыла – һөҗүм итәләр, янгыннар аркасында бу тирәләр дә бик эссе төтен белән тула. Кремль эчендәгеләр, биналарның агач өлешләренә ут капмасын, дип, аларын үзләре үк сүтеп ташлыйлар. Шәһәрдә 25 чиркәү, 3 монастырь, 1772 шәхси йорт янып бетә. Анда яшәүчеләрнең күбесе шәһәрдән кача, бер өлеше әсирлеккә эләгә. Төп сәүдә үзәге – Гостиный дворда йөзләрчә лавкалар талана.

12 июльнең кичендә Җөри юлы аша подполковник Михельсонның гаскәрләре Казанга якынлаша. Хөкүмәт гаскәрләре баш күтәрүчеләрнең тылына килеп чыгалар – алар килә-килешкә Пугачевның Нокса буендагы лагерена һөҗүм итәргә ниятлиләр. Лагерьда 1200ләп кенә кеше исәпләнә – калганнары шәһәрдә. Шул ук 12 июльнең кичендә Михельсонның 800ләп солда-



«Пугачев суды». Василий Перов картинасы.

ты Царицыно урманы аша узганнан соң сазлыклы Нокса елгасын кичеп чыга һәм лагерьның үзәгенә һөҗүм итә. Хөкүмәт гаскәрләре пугачевчыларны икегә аеруга ирешә. Фланглардан майор Дуве һәм майор Харин отрядлары ярдәм итә. 5 сәгать буе дәвам иткән төнге сугыштан соң тынлык урнаша. Бу бәрелештә бер якны да җиңүгә иреште дип әйтә алмыйбыз. Иван Михельсон сүзләренә караганда, дошманның 800ләп кешесе үтерелә, 737 кеше әсирлеккә төшә, ядрәләре белән туплары тартып алына. Үзләреннән бары 23 кеше һәлак була, 38 е яралана. Әмма тарихчылар хәзерге көндә дә Емельян Пугачев явы вакытында Казанда төгәл генә күпме халык кырылганын белмиләр. Күп хәбәрләр Иван Михельсонның һәм башка хөкүмәт гаскәрләре отрядлары башлыкларының рапортларына гына нигезләнә, ә аларга үзләренең хәрби уңышларын арттырып күрсәтү хас нәрсә.

13–15 ИЮЛЬДӘГЕ ХӘРӘКӘТЛӘР

13 июльдә, бераз ял итеп алгач, Михельсон отряды шәһәр гарнизоны белән кушылырга юнәлә. Әмма юлларына баш күтәрүчеләрнең отрядлары каршы чыга. Михельсонның якынаюын белгән генерал-майор Павел Сергеевич Потемкин җитәкчелегендәге шәһәрне саклаучылар да Кремльдән чыгып, пугачевчыларга икенче яктан һөҗүм итәләр. Төп бәрелеш Арча зиратыннан көнчыгыштарак була (Подсека дигән җирдә). Нәтиҗәдә Пугачев җиңелә, калдык отрядлары белән Казансу елгасын кичеп, үзенең ерактагы лагерена – Коры Елга (Сухая Река) авылына барып чыга.

14 июльдә актив сугыш хәрәкәтләре алып барылмый. Иван Михельсон белән Павел Потемкин Пугачевны эзәрлекләп артыннан барырга җөрьәт итмиләр – әйләнештә калуыбыз бар, дип шөбһәләнәләр. Моннан файдаланып, Емельян Пугачев тиз арада яңа гаскәр туплый. Тирә-як авыллардан аның лагерена агылган крестьяннардан тагын 15 меңлек гаскәр оеша (кайбер чыганакларда 25 мең диелгән).

15 июльдә хөкүмәт отрядлары белән Пугачев гаскәре арасында иң зур бәрелеш була. Кайбер авторлар бу сугышта Пугачевның баштагы лагере – Нокса буендагы беренче бәрелеш урынында булган, дип исәпли. Шулай да аның үз күрсәтмәләрендә сугыш Арча кырында булды, дип әйтә. Сугыш 4 сәгать бара. Күпсанлы Пугачев гаскәре яхшы коралланган һәм өйрәтелгән патша армиясенә каршы тора алмый. Михельсон күрсәтмәләренә караганда, 2 меңләп фетнәче яклы кеше үтерелә, 5 меңе әсирлеккә төшә, 10 меңнән артык кеше баш күтәрүчеләрнең әсирлегеннән азат ителә. Александр Сергеевич Пушкин «Пугачев тарихы»нда «Казансу елгасы кеше мәетләре белән тулган иде», дип яза.

ВОССТАНИЕНЕҢ ДӘВАМЫ

Казанда җиңелгәннән соң Пугачев зур булмаган отряды белән Иделнең уң як ярына чыгып кача. Аның уенда Мәскәүгә кадәр бару планнары да була. Зөя, Чебоксар, Козьмодемьянск, Ядрин һәм башка өязләрдә баш күтәрүчеләр пугачевчыларга кушыла. Хөкүмәт яңадан-яңа каратель отрядлары җибәреп (шул исәптән А.В. Суворов җитәкчелегендәге отряд), баш күтәрүләр дулкынын бастыруга, Пугачевның үзен әсирлеккә алуга ирешә.

НӘТИҖӘЛӘР

Шулай итеп, Россия тарихындагы иң зур крестьяннар сугышы төгәлләнә. Дәүләттәге нығып урнашкан феодаль-крепостной тәртипләргә каршы рус, татар, башкорт, чуваш, мари һәм башка милләт вәкилләре бергәләп көрәшә. Пугачев явыннан соң Казанның тышкы кыяфәте бөтенләй үзгәрә. Әйләнеп кайткан качакларның күбесе үз йортларын таба алмый – янып көлгә әйләнгән. Таш биналарны янгыннан соң торгызу мәшәкатьләре дә җитәрлек була. Зыян күрүчеләр, ярдәм сорап, хөкүмәткә бихисап күп үтенечләр яза. Әкренләп булса да, чиркәү-йортларны торгызу эшләре бара. Пугачев җитәкчелегендәге сугышларда катнашучыларны җәзалау да озак көттерми. Меңәрләгән кеше таяк-камчы белән суктырыла, шактыеның борыннарын тиштереп, колакларын кисәләр һәм кандалада каторгага озаталар. Хөкүмәт ягында сугышучыларга төрле дәрәҗә орден-медальләр бирелә, күпсанлы өстенлекләр, карьера үсеше тәэмин ителә. Йомышлы татарлар, морзалар «Емельян Пугачев явы вакытында хөкүмәткә тугрылыклы булып калдык», дип үзләренә өстенлекләр дәгъвалыйлар. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1784 елда Екатерина II татар морзаларына да Россия дворяннары хокукларыннан файдаланырга мөмкинлек бирүче указ чыгара.

МАХСУС ПРОЕКТ

— 52нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

КИҢ КОЛАЧЛЫ КЕШЕ

Республиканың иң эре предприятиеләренең берсе – «Казанкомпрессормаш» ААҖне 1996 елдан 2013 елга кадәр җитәкләгән легендар директор, Татарстан Республикасының атказанган фән һәм техника эшлеклесе, техник фәннәр докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, Халыкара салкынлык академиясе һәм Россия табигать фәннәре академиясенең хакыйкый әгъзасы, Россия Машина төзүчеләр берлегенең Хезмәт даны залы лауреаты Ибраһим Хисамиевка март аенда 75 яшь тула. Әлеге юбилей уңае белән «Казанкомпрессормаш» ААҖ коллективы предприятие үсешенә зур өлеш керткән Ибраһим Габделхак улын котлый.

2020 елның мартында Татарстан Республикасы Президенты Указы белән Ибраһим Габделхак улы Хисамиев республика иминлеге хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм илебез машина төзелеше үсешенә зур өлеш кертүе өчен «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләнде.

– Хөрмәтле Ибраһим Габделхакович!

Юбилеегыз көнендә предприятиебез һәм тулаем Татарстан сәнәгате өчен күрсәткән хезмәтегез һәм игелекләрегез өчен Сезгә хөрмәт-ихтирамымны белдерәм. Сез ярты гасырдан артык химия һәм нефть тармагы машина төзелеше предприятиеләрендә һәм оешмаларында эшләдегез. Республикабыз территориясендә бу тармактагы җитештерүне торгызуга күп көч куйдыгыз. Заводның гади бер вәкиле буларак, эшче һөнәрләрнең барлык серләрен белеп, Татарстанда компрессорлар төзелешенә нигез салучыларның берсенә әверелдегез. Талантлы инженер һәм оста оештыручы, хезмәт сөючән зат һәм уйлап табучы – республикада Сезне әнә шундый шәхес итеп беләләр. Һәр вазыйфада Сез алга куелган бурычларны уңышлы башкардыгыз, кыйммәтле тәҗрибәгә ия булып, дуслар һәм фикердәшләр тупладыгыз. Катлаулы 90нчы елларда республика сәнәгате «кризиска каршы торырлык» ныклы, ышанычлы җитәкчеләргә мохтаҗ иде. Шуңа күрә 1996 елда Сезне, шәхси эшлекле сыйфатларыгызны, җитәкчелек һәм оештыру тәҗрибәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасының беренче Президенты Минтимер Шәймиев тәкъдиме белән, «В.Б.Шнепп исемендәге турбокомпрессор фәнни-тикшеренү институты» ААҖ директоры вазыйфасын саклаган хәлдә, «Казанкомпрессормаш» ААҖ генераль директоры итеп билгеләделәр. Сезнең җитәкчелектә предприятиенең яңа данлы чоры башланды – хәзер завод компрессорлар төзү тармагында Татарстанда һәм Россиядә алдынгы урыннарны били. Сезнең тырышлык белән «Казанкомпрессормаш» ААҖнең икътисадый һәм социаль үсеше стратегик программасы эшләнде, яңа инновацияле технологияләр кертелде, моның өчен Сез фән һәм техника өлкәсендә ТР Дәүләт премиясенә лаек булдыгыз. Сезнең стратегик адымнарыгыз күзгә күренеп торган нәтиҗәләрне бирде – 2000 нче еллар дәвамында предприятиенең җитештерү темплары һәм күләмнәре даими үсештә торды. Бүгенге көндә Казан компрессорлар төзү заводы Россиядә һәм БДБ илләрендә сәнәгатьнең төрле тармаклары өчен компрессорлар һәм шул агрегатлар нигезендә тулы комплектлы җайланмалар җитештерә торган алдынгы заводларның берсе санала. Без җитештерүне модернизацияләү, яңарту белән актив шөгыльләнеп, техник яктан яңадан җиһазлар көйләү эшен һәм рационализаторлык традицияләрен дәвам итәбез. Сезнең кебек үк, хезмәт коллективына сакчыл карыйбыз, хезмәткәрләрнең керемнәре арту мәсьәләсен армый-талмый кайгыртабыз.

Сез – компрессор техникасын ясау нигезләре өлкәсендә күп кенә уйлап табулар, 50дән артык китап һәм 300 фәнни мәкалә авторы, күп еллар Казан милли тикшеренү технология университетының (КХТИ) шул профильдәге кафедрасын җитәклисез. Сез – өч тапкыр «Ел җитәкчесе» республика конкурсы лауреаты, компрессорлар төзү өлкәсендә абруйлы шәхес, актив тормыш позициясе белән дә аерылып торасыз. Безнең өчен Сез – фикердәшләр командасын туплау һәм берләштерү, билгеләнгән бурычларны үтәү өчен аларны туплау сәләтенә ия легендар җитәкче. Хәйрия өлкәсендәге бай мирасыгызга аерым тукталасым килә. Игелекле, кайгыртучан зат буларак, сез «Намус һәм батырлык өчен», «Намус һәм файда» орденнары белән лаеклы бүләкләндегез, «Алтын йөрәкле кеше» район конкурсында җиңү яуладыгыз, үз акчагызга Казандагы балалар йортларына ярдәмне туктатмыйсыз.

Хөрмәтле Ибраһим Габделхакович!

«Казанкомпрессормаш» ААҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезгә уй-ниятләрегездә, гамәлләрегездә чын күңелдән уңышлар телим һәм һәрберебезнең язмышына керткән зур өлеш һәм предприятиенең югары нәтиҗәләре өчен рәхмәт белдерәм! Юбилеегыз уңаеннан Сезгә һәм якыннарыгызга бетмәс-төкәнмәс энергия һәм ныклы сәламәтлек телим!

Илнур Сәгъдиев,
«Казанкомпрессормаш» ААҖ идарәче директоры

Реклама

Фотоларны «Казанкомпрессормаш» ААҖ тәкъдим итте

Камил Сәмигуллин, ТР Үзәкләшкән дини оешма – ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти, март аенда үзенең туган көнен билгеләп үтә.

Реклама

Фото «ТР ДЭБИ» ДАУ матбугат хезмәтеннән алынды

Мәҗит Салихов,
«ТР ДЭБИ» ДАУ җитәкчесе

Аллаһка һәм халыкка хезмәт юлында

– Хөрмәтле Камил хәзрәт! Безнең учреждение хезмәткәрләре һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән ихлас котлыйм! Туган көнегездә яңгыраган барлык котлауларга кушылып, Сезнең ил һәм республика территориясендә ислам үсешенә керткән өлешегезне билгеләп үтәм. Сез хак мөселман рухание буларак, озын һәм кызыклы юл үттегез, Коръән буенча күренекле галим һәм олы белгеч булып җитештегез.

ТР мөфтие, Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе итеп билгеләнүегез Сезнең хезмәтегезгә югары бәһа, күпсанлы өммәтегез каршында гаделлек, тәрбиялелек, игелеклелек һәм еракка карап эш итә белү кебек шәхси сыйфатларыгызны тану буларак кабул ителде. Сезнең милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрдә гармониягә ирешүгә, халкыбызның традицион кыйммәтләрен ныгытуга, иминлек һәм үзара килешеп яшәүгә юнәлтелгән тырышлыкларыгызның җимешләрен күрү аеруча сөенечле.

Мөфти-хәзрәт җәнаплары, Сезгә, язмышын ислам динен өйрәнү һәм тарату белән бәйләгән, гомерен Аллаһка багышлаган кеше буларак, олы ихтирамымны җиткерәм. Сез бөтен вакытыгызны һәм тырышлыкларыгызны Аллаһка һәм Татарстаныбыз халкына хезмәткә багышлыйсыз.

Хөрмәтле Камил хәзрәт! Сезгә Татарстан территориясендә мөселман өммәтенең традицион кыйммәтләрен ныгыту буенча миссиягезне тормышка ашыруда уңышлар телим! Аллаһ Сезгә һәм якыннарыгызга үзенең рәхмәтен җиткерсен, Сезгә озын гомер, сәламәтлек иминлек һәм муллык бирсен!

Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре яусын сезгә!

Фото «Ярдәм» МИХФ Советыннан алынды

– Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим! Әссәләмү галәйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәрәкәтүһ!

Хөрмәтле Камил хәзрәт, Сезне күркәм бәйрәмегез – туган көнегез белән «Ярдәм» милли ислам хәйрия фонды һәм шәхсән үз исемемнән ихластан котлыйм. Ислам динен үстерүдә һәм Татарстан өммәтенә хак юл күрсәтүдә тырыш хезмәтегезне тагын әле озак еллар дәвам итүегезне теләп, Аллаһы Тәгаләдән хәерле гомер сорап калам.

Камил хәзрәт, сезнең исемегез һәм башкарган хезмәтләрегез, Татарстанда гына түгел, Россия киңлекләрендә, чит илләрдә дә билгеле. Үзегезнең тирән гыйлемегез, ару-талуны белмәс эшчәнлегегез белән Русия ислам җәмәгатьчелегендә абруйлы шәхесләрнең берсенә әверелдегез.

Үзегезнең үтемле вәгазьләрегез белән һәркем күңеленә үтеп кереп, аларның һидаять юлына басуына сәбәпче булдыгыз. Сезнең күпсанлы хезмәтләрегез мөселманнарның өстәл китабына әйләнде. Дин юлына баскан кешеләргә юл күрсәтте. Сезнең үгет-нәсыйхәтләрегез олысының да, кечесенең дә күңеленә барып җитә. Сез аларның, күңеленә юл табып, Ислам динен куәтләүчеләр булуына ирештегез. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре яусын сезгә!

Аллаһ Раббыбыз һәркайсыбызга ныклы иман, хәерле гомер, саулык-сәламәтлек, хәерле гыйлем, илебезгә, динебезгә, милләтебезгә файдалы, якыннарыбызга миһербанлы-шәфкатьле булып яшәргә насыйп кылсын. Аллаһның кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып, динебезне куәтләүче, Пәйгамбәребезнең өммәте булып яшәргә, ике дөнья бәхетенә ирешергә насыйп булсын.

Ихтирам һәм изге догалар белән,
Илдар хәзрәт Баязитов,
Татарстан мөфтиенең социаль мәсьәләләр буенча киңәшчесе,
«Ярдәм» МИХФ Советы рәисе

Елена Кузьмичева,
алтынчы чакырылыш ТР Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы Профсоюзлары федерациясе рәисе, апрель аенда юбилеен билгеләп үтә.

Фото: «Татар-информ» МА

Виллен Балоев,
«Гамәли оптика дәүләт институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» АҖ генераль директоры

ГИПО

– Хөрмәтле Елена Ивановна!

«Гамәли оптика дәүләт институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» АҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән чын йөрәктән котлыйм!

Сез – Татарстанның иң танылган хатын-кызларының берсе. Сезне искиткеч оештыручы, югары профессиональлеккә ия, тәҗрибәле һәм принципларга тугры профсоюз хезмәткәре буларак беләләр.

Хезмәт биографиягез төрле предприятие, оешма, учреждение хезмәткәрләренең, уку йортлары укучыларының һәм студентларының хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау максатыннан, аларның һөнәри берлекләргә берләштерү эшенә бирелгәнлек үрнәге булып тора. Ә нәкъ менә хәзерге замандагы үзгәреп торган сәяси һәм социаль-икътисадый шартларда профсоюзларның тотрыклы эшләве аеруча мөһим.

Россия сәнәгать хезмәткәрләре һөнәр бәйрәменә кергән «Гамәли оптика дәүләт институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» АҖ күп кенә мәсьәләләрне хәл итүдә, шул исәптән җитештерү, хезмәткәрләрнең ялын оештыру эшен, хезмәт шартларын яхшыртуда, аларның социаль-хезмәт хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауда, белем һәм һөнәри дәрәҗәсен күтәрүдә Татарстан Республикасы Профсоюзлары федерациясенең һәм, федерация рәисе буларак, шәхсән Сезнең ярдәмегезне даими тоя.

Әлеге истәлекле көндә Сезгә, Елена Ивановна, һәм гаиләгезгә ныклы сәламәтлек, бәхет, иминлек, уңышлар телим. Муллык һәм имин тормыш телибез Сезгә! Лаеклы хезмәт итү мөмкинлеге бирә торган энергия, яктылык, мәхәббәт чишмәсе һич саекмасын!

Фото «Гамәли оптика дәүләт институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» АҖ тарафыннан бирелде

Реклама

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

facebook.com/protatarstan

twitter.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

instagram.com/protatarstan

Реклама 16+

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕНЕҢ МӘНФӘГАТЬЛӘРЕН ҺӘМ СӘЛАМӘТЛЕГЕН КАЙГЫРТЫП

– Хөрмәтле Елена Ивановна!

Үз исемемнән һәм безнең дәвалау-профилактика учреждениесе хезмәткәрләре коллективы исеменнән Сезне юбилеегыз белән ихлас күңелдән котлыйм!

Юбилей уңаеннан хезмәттәшләрегездән һәм партнерларыгыздан котлау телеграммалары яуган бу истәлекле көндә Сезгә әйтелгән бөтен җылы сүзләргә кушылабыз һәм ныклы сәламәтлек телибез. Чыннан да, сәламәтлек – кеше өчен иң зур кыйммәт. Шуны да билгеләп үтик: безнең профсоюз шифаханәсе 1938 елдан бирле билгеле һәм ул эшче коллективларының сәламәтлеген торгызуда һәрчак ярдәмче булды. Шуңа күрә шифаханә коллективы нәтиҗәле эшегез һәм хезмәт ияләренең тормыш сыйфатын күтәрүгә керткән өлешегез өчен олы рәхмәт белдерә. Бүген Татарстан Республикасы Профсоюзлары федерациясе – безнең төбәктә генә түгел, ә гомумән Россия Федерациясендә дә хөрмәт казанган абруйлы оешма. Сез, ТР Дәүләт Советы депутаты буларак, Татарстан халкы мәнфәгатьләрен кайгыртып, закон чыгару эшен һәм иҗтимагый эшчәнлекне актив алып барасыз.

Сезне тәҗрибәле җитәкче генә түгел, ә зирәк, мөлаем хатын-кыз буларак та беләләр, кешелеклелек сыйфатларыгыз, югары әхлакый принципларыгыз, кешеләрнең кайгы-борчуларына игътибарлылык һәм күңел җылысы федерация алдында торган бурычларны хәл итәргә булыша. Хезмәт биографиягез – эшкә сәләтлелек һәм талант өлгесе, югары әхлакый принципларга һәм максатчанлыкка ия булу үрнәге. Сез язмышыгызны республиканың хезмәт коллективлары файдасына көч түгүгә, эшче кешеләрнең хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга, аларны лаеклы һәм куркынычсыз хезмәт шартлары белән тәэмин итүгә багышладыгыз. Сез оборона сәнәгате хезмәткәрләре профсоюзының мәнфәгатьләрен уңышлы якладыгыз. Татарстан Республикасы Профсоюзлары федерациясе рәисе вазыйфасында хезмәт коллективларының тормыш дәрәҗәсен яхшырту, әгъза оешмалар арасында социаль-хезмәт хокукларын яклау һәм оешманың абруен үстерү буенча ният-гамәлләрне берләштерү һәм координацияләү юнәлешендә нәтиҗәле эш алып барасыз. Сездәге зур оештыру тәҗрибәсе һәм югары белем дәрәҗәсе Татарстан халкы файдасына акыллы карарлар кабул итәргә мөмкинлек бирә. Төбәктәге һөнәр берлекләренең көчле потенциалы алга таба да профсоюзлар тармагындагы мөһим эшчәнлекне үстерүгә һәм куелган максатларга ирешүгә юнәлтелер дип ышанабыз.

Ливадия Livadia
санаторий health resort

Хөрмәтле Елена Ивановна!

Юбилеегыз көнендә иң ихлас котлауларны кабул итегез! Сезгә чын күңелдән корычтай ныклы сәламәтлек, республика профсоюзлары оешмаларының бердәмлеген ныгытуда, социаль-хезмәт хокукларын һәм хезмәт ияләренең мәнфәгатьләрен яклауда профсоюзларның ролен арттыруда уңышлар телибез! Бәхет, иминлек, муллык, гармония Сезгә!

Фәрит Галимуллин,

«Ливадия» шифаханәсе баш табибы һәм шифаханә коллективы

Реклама Фотолар профсоюзларның дәвалау-профилактика шәхси оешмасы – «Ливадия» шифаханәсеннән алынды

ЯШЬНӘП ТОРГАН КОШМАН

Тукай районының Биклән авылына баргач, чын шәһәрчә яшәүче авылны күреп: «Чаллыга якын, шуңа да кешеләрнең көнкүрешләре алга киткән», – дип үзара сөйләшкән идек. Кайбыч районының Кошман авылы исә шәһәр янәшәсендә дә түгел, ә халыкның тормыш рәвеше гаҗәпләнерлек. Чагыштыру өчен гади генә бер сан: балалар бакчасына 42 сабый йөри, әле тагын ике яшькәчә утыз биш бала өйдә тәрбияләнә. Килешерсез, бүгенге көн өчен кечкенә саннар түгел бу. Кошманның «картаймау» сәбәбе нидә? Җирле халык белән аралашып, шул сорауга җавап эзләдек.

Автор:
Руфия Фазылова

«МОНДЫЙ БАКЧА БҮТӘН ЮК»

Кошман чагыштырмача зур авыл, 220 йортта 751 кеше яши. «Яшь гаилә» программасы белән төзелгән 9 йорт бар, ә нигездә, бередә ел саен ике-өч яңа йорт салына икән.

– Әлбәттә, башка авыллар белән чагыштырганда, бездә хәлләр күпкә әйбәт, – диде Кошман авыл җирлеге башлыгы **Лилия Сафина.** – Моны миңа коллегаларым да әйтә. Алга таба да шул югарылыктан төшмисе иде.

– Кошманда мәктәпкәчә яшьтәге җитмештән артык бала бар икән. Димәк, авылда яшьләр кала. Моның сере нидә? – дим.

– Беренчедән, безгә Кайбыч якын, дүрт кенә чакрым ераклыкта. Сиксәнләп кеше район үзәгенә йөреп эшли. Икенчедән, авылда яшәр өчен бөтен мөмкинлекләр бар: газы, суы, уты, юлы… Бездә бер генә юлсыз урам да юк. Өченчедән, халык тырыш: күктән төшкәнне көтеп утырмыйлар: 3 КФХ, 8 ШЭ генә бар. Әле тагын үз эшләрен башларга теләк белдерүчеләр дә күренә. Ә бала санына килгәндә, яшь гаиләләр шактый. Өченче балаларын алып кайтучылар да бар.

Бала дигәннән, 2019 елда «Демография» милли проекты кысаларында, Кошманда 50 балага исәпләнгән балалар бакчасы төзелгән. Иң беренче эш итеп, без шунда юнәлдек. «Тиенкәй» дип язылган аллы-гөлле бина еракт ан үк күзгә ташланды. Мәктәп белән янәшә салганнар аны. (Сүз уңаеннан, белем бирү йортында да капиталь ремонт бара. Ике ел ел элек мәдәният йортын да өр-яңа төзелгән кебек ясап куйганнар).

– Балалар авыру сәбәпле, әле карантинга ябылып торган идек, – дип каршы алды бакча мөдире Айсылу Калашникова. – Бүген беренче көн эшлибез. Балаларның кайберләре әле килмәде дә.

Яңа бакчаның иркен бүлмәләренә атлыйбыз. Шәп дип әйтү генә аз, искиткеч! Ике төркемгә исәпләнгән бакчада барысы да заман таләпләренә туры килә: уен, йокы бүлмәләре аерым, ашханәне санамыйча, ике якта да ризык бүлү һәм савыт-саба юу өчен аерым кабинетлар. Миңа исә аеручa шәфкать туташы бүлмәсе ошады.

Фото: Александр Ефремов

– Бакча ачылышына бөтен нәрсә кайтты, – дип сөйләде Айсылу Калашникова. – Тузан суырткыч, кер юу машинасыннан башлап, уенчыкларга кадәр. Безгә килеп ирешкән мәгълүматларга караганда, республиканың бүтән авылларында мондый бакчалар юк.

Кыскасы, «Тиенкәй»дән, шаккатып, Кошман балалары, ата-аналары өчен сөенеп чыктык.

– Авылда балалар саны тагын да артыр инде, бакчага кызыгып булса да хатын-кызлар бәби алып кайтыр, – диештек.

«БАБАЧЫ БАБАЙ КИЛГӘН!»

Электән Кошман авылы сөннәткә утыртучы «бабайлары» белән дан казанган. Алар авылда берничә кеше булган. Хәтта Урта Азия якларына кадәр йөргәннәре билгеле. Хәзер авылда бу шөгыльне онытканнар инде. (Закон балаларны өйдә сөннәткә утыртырга рөхсәт итми бит). Ә менә авылның соңгы сөннәтчеләре яшәгән йорт бар, иң сөенечлесе – ул ябылмаган.

Гөлсинә Сафиуллина әлеге нигезгә 1958 елда килен булып төшкән. Каенатасын бу якларда «бабачы Хәлилулла» дип йөрткәннәр. Соңрак тормыш иптәше Галимулла да шушы һөнәрне үзләштергән.

– Ирем Галимулла бабачы булып әллә ни күп йөрмәде, – дип сөйләде Гөлсинә апа. – Озак яшәмәде шул, 1982 елда дөнья куйды. Каенатам картайгач, сөннәтче итеп Галимулланы чакыра башлаганнар иде. «Кулың җиңел», – дияләр иде аңа. Ул, гел әткәй тирәсендә йөреп, сөннәткә утыртуның серләрен өйрәнгән иде.

Бу йорттан дистә еллар бала-чага тавышы тынмаган. Сөннәткә утыртканнан соң, өчәр көн яшәүчеләр дә булган.

– Ата-аналар балаларын әллә кайлардан алып киләләр иде, – дип хәтер сандыгын чиште Гөлсинә апа. – Җәрәхәт азрак төзәлсен дип, каенатам аларны шулай үзебездә яшәтте. Ашатып-эчертеп, тәрбиядә тота идек үзләрен.

– Сөннәткә утыртуның аерым бәясе бар идеме? – дим.

– Дөресен генә әйткәндә, белмим. Бер түбә астында яшәсәк тә, каенатамның күзенә бик чалынмаска тырыштым. Оялу, курку булганмы, ничек атарга да белмим... Әткәй шактый кырыс кеше иде, аның сүзе буенча яшәдек. Акча да аның кулында булды. Мине кибеткә җибәргәндә, башта агач счетын чыгарып исәпләр, аннан акча бирер иде...

Шулай да берсендә Гөлсинә апа, каенатасының бер әти кеше белән сөйләшкәнен ишетеп кала: «Миңа артыгы кирәк түгел, биш сум күп була, өч сум җитәр...»

– Сөннәткә утырту яшерен эшләнә иде, – дип пышылдап кына дәвам итте әңгәмәдәшем. (Әйтерсең, безне тыңлап торалар). – Совет власте дин кушканча яшәүне тыйды бит. Ерактан килгән кешеләр атларын капка төбенә куймыйча, аны берәр җирдә туарып калдырып керәләр иде. Әйе, бик кырыс заманда яшәдек. Баласын сөннәткә утыртканны белсәләр, әти-әнине партиядән чыгарырга күп сорамыйлар иде.

Гөлсинә апа күңелендә тагын бер истәлек яши. Баксаң, каенатасы аздан гына төрмәгә эләкмәгән. Сәбәбе – сөннәткә утыртканнан соң, бер бала үлгән.

– Әткәй пәкесен алып, атналар буе йөреп кайта иде, – диде әңгәмәдәшем. – Һич онытмыйм, берсендә Яшел Үзәннән кумердәй каралып кайтты: шунда бер сабыйны сөннәтләгән. Ул чирле туган булган, тик моны әткәй белмәгән. Берничә көннән теге бала үлгән. Шуннан соң әткәйне милиция юлында йөртә башладылар. Төнлә килеп, сорау алырга дип алып киттеләр. Бөтен дөньяны айкадылар, пәкеләрен эзләделәр. Бәхеткә, әткәйне төрмәгә утыртмадылар. Ана кеше, баласының туганда ук сау булмаганлыгын аңлаткан, табиблардан белешмәгә хәтле яздырып алып кайткан...

Ни кызганыч, сөннәтче бабайларның эш коралы – пәкеләр сакланмаган. Кырык-илле ел эчендә югалып беткән икән.

– Әткәй, әнкәй, ирем – бер-бер артлы бакыйлыкка күчте, – диде хуҗабикә. –1981 елның көзендә – әнкәйне, 1982 елның язында – иремне, көзен әткәйне җирләдем. Әле ярый балаларым бар, шатлыгым да, таянычым да – алар. Ялгызым яшәсәм дә, гел хәлемне белеп, килеп, кайтып торалар.

«ҺӨНӘРЛӘРЕ БУЛГАН»

Умартачылар, кирпеч сугучылар төбәге буларак та, Кошманның даны еракларга таралган. Халык соңгысы белән аеруча горурлана, элек-электән һөнәрле булганнар бит. Менә шуның өчен дә биредә халык иң авыр заманнарда да начар яшәмәгән.

– Лаеклы ялга чыккач, авыл тарихы белән кызыксына башладым, – **диде Салих Мотыйгуллин.** – Әлегә авыл тарихына кагылышлы документларны өйрәнеп, архивларда утырганым юк. Миндә авыл картларыннан сорашкан мәгълүматлар гына бар. Мисал өчен, безнең әби Кошманга 1906 елда килен булып килгән. «Иген игүгә караганда, кирпеч сугу ныграк җәелгән иде», – дип сөйли иде ул. Безгә билгеле документлардан күренгәнчә, XX гасыр башында авылда 150 йорт булган, шуның йөзендә кирпеч сукканнар. Мәрхүм әткәй: «Бер елга кырык мең кирпеч суктык», – дип әйтә иде. Һәр гаилә кырык мең сукмаса да, егерме, егерме биш меңне сукканнар инде. Исәпләсәң, бер Кошман авылы 2 миллион ярым чамасы кирпеч суккан. Безгә якын булган Ябалак авылында кирпеч заводы бар иде. Шунда эшләгән кешеләрдән сораштым: яхшы эшләгән чорларда алар елына 2 миллион кирпеч суккан. Димәк, безнең авыл кешеләре тулы бер завод кадәр эш эшләгән. Кошман кирпеченә, дип, бик ераклардан ук килгәнннәр.

– Кирпеч сугу өчен авылда бөтен мөмкинлекләр булган, – дип сүзгә кушылды Кошман мәктәбендә күп еллар тарих укыткан мөгаллим **Нәзир Сафин.** – Кызыл балчыкны бәрәңге бакчасыннан ук алганнар. Бакча артындагы чокырларны әле берничә ел элек кенә тигезләттердем. Шул заманнардан калган ул. Бакчалар казылып беткәннән соң, кырга чыкканнар. Миндә әле кирпеч сугу станы да бар иде. Әнкәйләрдән калган ул. Аны узган ел, музей ачылгач, Кайбычка илтеп бирдем.

– 1950–1960 нчы елларда кирпеч сугу кимегән, – дип дәвам итте Салих абый. – Мин әле 1969 елда да өч мең кирпеч суктым. Әткәй урыннарын ясап биргән иде. Шулай булгач, авылның иң соңгы кирпеч сугучысы булып чыкмыйммы икән дип тә уйлыйм...

Кошманлыларның тагын бер һөнәре – умартачылык. Элек-электән авылның һәр өченче, дүртенче хуҗалыгы корт асраган. Бүген дә шушы традиция дәвам итә.

Авылның иң өлкән умартачысы – Харис Гарифуллин бүген килене Нәҗия белән яши.

Авылның иң өлкән умартачысы – **Харис абый Гарифуллин.** Узган ел ул тугыз дистәне тутырган. Бүген килене Нәҗия белән яши. Улы Исмәгыйль берничә ел элек фаҗигале рәвештә вафат булган.

– Әти картайды инде, – ди Нәҗия апа. – Кортларны карамый башлаганына ике ел бардыр. Аллага шөкер, үзен үзе йөртә әле.

Нәҗия апа бал кортларын бүген үзе карый икән. Егермеләп баш умартасы бар.

– Умартачылык эшенә әтидән өйрәндем, – дип сүзен дәвам итте Нәҗия апа. – Баштагы вакытларда кортларны бергә карый идек. Хәер, хәзер дә бал аертканда чыга әле, күзәтеп булса да тора.

Харис абыйдан җай белән генә яраткан эше турында сорашам. Шактый еллар Урсак урман хуҗалыгында, Кошман умарталыгында эшләгән ул.

– Мин үз эшемне яратып башкардым, – диде туксан яшьлек умартачы. – Бал җитештерү планын һәр елны арттырып үтәдем. Тырыш хезмәтемне җитәкчеләр дә бәяләде. Төрле елларда мактау кәгазьләре, кыйммәтле бүләкләргә ия булдым. Хәтта мотоцикл да бүләк иттеләр. Умартачы булып эшләгән чорда өч тапкыр Мәскәүгә бардым. Республикадан Мәскәүдә уза торган Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенә делегат итеп сайладылар. «Социалистик ярыш җиңүчесе», «Коммунистик хезмәт ударнигы» күкрәк билгеләренә дә лаек булдым. Сагынам шул чакларны, кызым...

Рушан Сәйранов өйләнеп, төп йортта әнисе, тормыш иптәше, ике баласы белән яши.

ЯШЬ ФЕРМЕРЛАР

Кошманның яшь гаиләләре, авылның карап торган әйдәп баручы кешеләре белән дә танышмасак, дөрес булмас, дидек. **Рушан Сәйрановны** Кайбыч районында шактый кеше белә икән. Яшьтән үз бизнесын булдырган бик тырыш, белемле егет ул. Өйләнеп, төп йортта әнисе, тормыш иптәше, ике баласы белән яши.

– Фермерлык тәҗрибәм әлегә кадәр иген, печән үстерү буенча гына иде, – дип сүзен башлады Рушан. – Узган ел менә кошчылык тармагы да кушылды. Максат куйсаң, чарасын табарга була. 2019 елда «Эш башлаучы фермер» программасы кысаларында, грант алдым. Чувашиянең Урмар кошчылык фабрикасы белән килешү төзедем, 6 мең 500 баш чебешкә акча түләп куйдым инде. Алга планнар – тәүлеклек чебиләр алып кайтып, үстереп сату. Бер айлык чагында аның 5 меңен тере килеш сатарга дип уйлыйм, калган мең ярымы калып торачак. Аларын ит өчен үстерәчәкбез.

Рушанның тавык үстерү тәҗрибәсе зур булмаса да, бар, узган ел 1 мең 500 бройлер чебі үстереп сатканнар.

Кайбыч белән Казан арасында йөреп, товарны урнаштырып бетергәннәр.

– Өйдән дә күп кеше килеп алды, – диде Рушан. – Итнең сыйфатлы икәнен аңлагач, кеше тагын килә. Бәясе чагыштырмача кыйммәт түгел, килосы 230 сумнан. Быел бәяне азрак арттырасы булыр кебек. Ни өчен дигәндә, ризык бәясе артты. Мисал өчен, элек бер капчык комбиазык 1 мең сум тора иде, ә хәзер аны 1 мең 300 сумнан саталар. Әле мин бәяне шуңа да тота алам: чебиләргә дигән азыкның 60 проценты үзебезнең җирләрдә үсә, 40 процентын гына алам. Ә сатып алып кына ашатсаң, итнең килосын 230 сумнан җибәрә алмыйсың. Ул үзүзен акламаячак.

Рушан грант акчасына тавык фермасы салып куйган. Хәзер аның бердәнбер проблемасы – фермага кадәр юл юк икән.

– Дәүләт программасы ярдәмендә, шул юлны хәл итәсе иде, – диде яшь фермер. – Күп тә түгел инде ул, ике йөз метр чамасы гына…

Тагын бер фермер гаиләсе – **Шәфиевлар** белән дә таныштык. Рушан Сәйрановтан аермалы буларак, алар дәүләт ярдәменнән файдаланмаганнар. Шәфиевлар мөгезле эре терлек үрчетү белән шөгыльләнә. Савым сыерлары, дистәдән артык үгез асрыйлар. Гаилә башлыгы Ринатка әле утыз яшь тә тулмаган, ә инде йорт салып кергән, ике баласы, зур хуҗалыгы бар.

– Тормышны хатыным Гүзәлия белән тартабыз, – диде Ринат. – Мин малларны ашатам, ә Гүзәлия, сөт савып, аннан каймак, катык, эремчек, корт ясый. Авылда да, Кайбычта да сатып алучыларыбыз бар. Сөтне дәүләткә тапшырсаң файдасы юк, ә менә эшкәртеп сатсаң, ярый әле.

Гүзәлия Биектау районының Ямаширмә авылы кызы икән. Сөт ризыкларын эшкәртеп сату балачагы белән бәйле:

– Безнең якта хатын-кызлар корт, эремчек ясап, Казанга алып барып саталар иде, – диде ул.

Шәфиевларның җирләре юк. Малларга дигән печәнне, ашлыкны сатып алалар.

– Алга таба шушы юнәлештә планнар байтак, – диде гаилә башлыгы.

…Кошман әниемнең туган авылы икәнен әйтмәсәм, авыл кешеләре аңламас. Бу авыл балачагымның якты, җылы хатирәсе булып күңелгә кереп калган. Бер үзенчәлек турында да әйтим – бередә халык динле. Авылда гомергә ике мәчет булган, бүген дә шулай. Кошманга бара башласак әни: «Башыңа яулык алдыңмы?» – дия иде. Монда аш өстәле артына яланбаш утырмыйлар. Менә шул кыйммәтләр авылны бүген дә яшәтә сыман: тәртип, әхлак бар бередә. Ә тәҗрибә күрсәткәнчә, ул кай заманда да кыйммәтен югалтмый.

– Тормышны хатыным Гүзәлия белән тартабыз, – диде Ринат Шәфиев.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

Авыл атамасы 1565–1567 нче елларны үз эченә алган Зөя өзенең теркәү кенәгәләрендә очрый. XVIII йөзгә караган тарихи чыганакта Олы Кошман авылында йомышлы татарлар саны – 181, керәшен татарлары 6 кеше дип күрсәтелә. Җирле халык берничә керәшен гаиләсе барын инкарь итми. Ләкин алар ислам диненә яңадан кайта.

Кошман – елга исеме. «Ман» сүзе төрки телдә су дигәне аңлата, ә «куш» – елгалар кушылган урын. Авыл Түбән Кошман, Югары Кошман булып, елганың ике ярына урнашкан. Заманында алар ике колхозга аерылган була. Бүген исә андый бүленеш юк, шулай да халык «Түбән Кошман», «Югары Кошман» дип, авылны икегә бүлеп карый.

(Авыл халкы сөйләгәннәрдән).

1000 СУМГА НӘРСӘ АЛЫРГА БУЛА?

...хәзерге вакытта:

- 5 шешә Россия шампан шәрабе
- яисә базарда 3 кг сыер ите
- яисә Казаннан Зөя шәһәренә бер көнлек тур (автобуста йөрү, экскурсия, гид хезмәте)
- яисә балалар өчен бигүк сыйфатлы булмаган самокат (Кытайныкы)
- яисә иске модель телевизорга цифрлы приставка

РФ буенча уртача хезмәт хакы (2019 елның июль ае мәгълүматы)
46 509 сум

ХАТЫН-КЫЗЛАР СОВЕТЛАРЫНЫҢ МАТУР ЭШЛӘРЕ

Хөрмәтле редакция! Сезгә Башкортостанныц Ярмәкәй районы, Тарказы авылыннан язам. Мин сезнец журналны 1961 елдан бирле алам, бу ел өчен дә алдан язылып куйдым. Ул безнец районда бер генә журнал икән.

Мин үзем җәмәгать эшләрендә актив катнашам, күп эшемне башкаруда сезнең материаллардан файдаланам. Бик күп яңалыкларны яктыртуыгыз өчен зур рәхмәт.

Редакциягә үтенечем бар. Хатын-кызлар советларының эшендә яңа формалар турында сөйләсәгез иде. Алар ни белән шөгыльләнәләр, үз алларына нинди бурычлар куялар, ул бурычларны ничегрәк хәл итәләр? Минемчә, бу бер миңа гына кызык булмас.

Ихтирам белән, катлаулы эшегездә
зур уңышлар теләп, **РӘЙСӘ СӘМИГУЛЛИНА**

Безнең районда хатын-кызлар советлары хатын-кызларның 1984 ел ахырында булган республика конференциясеннән соң оешты. Хәзер районда, авыл Советлары каршында 32 хатын-кызлар советы эшли. Аларга 200 ләп иң абруйлы, булдыклы һәм ярдәмчел хатын-кыз сайланды. Алар авыл хатын-кызларының сәламәтлеген саклау, хезмәт һәм тормыш-көнкүреш шартларын яхшырту мәсьәләләре белән шөгыльләнәләр, гаиләләргә балалар тәрбияләүдә, ялны оештыруда ярдәм итәләр.

Хатын-кызлар советлары депутатларның яшьләр белән эшләү буенча, халык мәгарифе һәм культура буенча даими эшләүче комиссияләре, социаль тәэминат хезмәткәрләре, хезмәт коллективлары, җәмәгать оешмалары белән тыгыз элемтәдә эшлиләр. Хатын-кызлар советларының булышлыгы белән башлыча хатын-кызлар эшли торган күп кенә коллективларда эш графиклары уңайрак итеп үзгәртелә, кайнар аш оештырыла, ял бүлмәләре ачыла, килеп сәүдә итү, көнкүреш хезмәте күрсәтүгә заказлар кабул итү, медицина ярдәме күрсәтү җайга салына.

Шул ук вакытта күп хуҗалыкларда бөтен нәрсә искечә кала. 4,5 мең хатын-кыз эшләгән район авыл хуҗалыгында хезмәтне оештыруның прогрессив формалары акрын кертелә, авыр хезмәт процесслары аз механикалаштырыла, авыр, зарарлы хезмәт шартларында эшләүчеләр күп, бу профессиональ авыруларны күбәйтә. Хатын-кызларны пестицидлар белән эшләүгә тарту очраклары бар, бу бигрәк тә чәчүлек орлыкны агулаганда була. Ә алар эшли торган агулы химикат һәм минераль ашлама складларында күптән инде срогы чыккан махсус киемнәр файдаланыла, эш көне режимы һәрвакытта да үтәлми. Кайбер хуҗалыкларда санитария һәм көнкүреш биналары белән тәэмин ителеш түбән.

Әгәр хуҗалык җитәкчеләре хатын-кызлар советларының үтенечләренә һәм тәкъдимнәренә колак салсалар, байтак мәсьәләләр җиңелрәк һәм тизрәк хәл ителер иде. Әлбәттә, хезмәттәшлек итү тәҗрибәсе туплана. Мисалга «Масловка» совхозының дирекциясе һәм хатын-кызлар советы эшен китерергә мөмкин. Анда аларга ике бик уңган хатын — Т.Васильева белән Г.Васильева җитәкчелек итәләр. Алар агымдагы һәм перспектив планнарны бергәләп билгелиләр, хатын-кызларның мәшәкатьләрен җиңеләйтергә омтылалар.

Яшьләр, балалар, үсмерләр белән эшләүдә кискен проблемалар бар. Хулиганлык, эчүчелек очраклары, укырга теләмәү, кеше өстендә яшәргә омты¬лу күренешләре борчый. Ямьсез күренешләрнең башы еш кына ата-аналарның үз бурычларына җавапсыз мөнәсәбәтенә барып тоташа. Алар белән иренмичә, җентекләп эшләргә туры килә. Балалар һәм ата-аналар белән сөйләшәбез, шунда ук коллектив җитәкчеләрен, административ органнар хезмәткәрләрен дә чакырабыз.

Яшьләр белән эшләүнең мөһим ягы — аларны авылда төпләндерү. Яңа Арыш авыл Советы каршындагы хатын-кызлар советы моңа зур игътибар бирә. Менә өч ел рәттән инде урта мәктәпне тәмамлаучылар туган авылларында, әти-әниләренең эшен дәвам итәргә калалар.

Байтак хатын-кызлар советлары «Кайгырту» программасын тормышка ашыруда актив катнаша. Бөек Ватан сугышы инвалидлары, һәлак булганнарның тол калган хатыннары, ялгыз картлар исәпкә алынды. Аларга тормыш шартларын яхшыртуда, ягулык белән тәэмин итүдә, бәрәңге бакчаларын эшкәртүдә ярдәм күрсәтелә. Карт кеше акчага интеккәндә дә ярдәм итәбез.

Хатын-кызлар советларының авторитеты үсә, аларның эшчәнлек даирәсе киңәя. Бирегә кешеләр яхшы киңәш ишетәсе килеп тә, эч бушату өчен дә киләләр. Концертлар, үзешчән сәнгать смотрлары, авыл бәйрәмнәре һәм җыеннары алардан башка үтми. Бина хәзерләргәме, костюмнар тегәргәме, балага исем куштырыргамы — һәркайда уңган хатын-кызларыбызның кайгыртучан куллары, җылы карашы кирәк.

Р. ГАНИЕВА,
Балык Бистәсе районының
хатын-кызлар советы председателе

ТР Милли китапханәсенең вакытлы матбугат бүлеге фондларыннан

ПАРТИЯ РАБОТНИКЛАРЫНЫҢ ХЕЗМӘТ ҺӘМ КӨНКҮРЕШ ШАРТЛАРЫ ТУРЫНДА

Мәгълүм булганча, соңгы вакытта партия аппараты кимеТелде. Бу акция КПССның Татарстан өлкә комитетына ни дәрәҗәдә кагылганын белергә теләр идек. Бер ук вакытта «Татарстан коммунисты» битләрендә шул хакта сөйләвегезне үтенәм: өлкә комитеты работникларының окладлары нинди, аларның нинди дә булса льготалары яки өстенлекләре бармы, өлкә партия комитетының бюджеты нинди чыганаклардан формалаша һәм бюджет акчалары кая тотыла?

З. АНОХИНА,
КПСС члены,
Казан шәһәре

Редакция бу сорауларга КПСС өлкә комитетының эшләр управляющие А. М. ПОДСЕКАЕВНЫҢ җавап бирүен үтенде.

Чыннан да, конференциясе карарларына туры китереп, партия комитеты аппаратын үзгәртеп кору һәм кимету бара, бу аппаратның структурасы дәүләт, хуҗалык органнарын алыштырмасын, политик җитәкчелекне көчәйтү бурычларына, үзгәртеп коруның яңа этабы максатларына тулырак җавап бирсен өчен эшләнә.

КПСС өлкә комитеты аппаратында кыскартудан һәм үзгәртеп корудан соң 17 бүлек урынына 9 бүлек калды. Шул исәптән – оештыру-партия һәм кадрлар эше, идеология, социаль-экономик, аграр, дәүләт-хокук бүлекләре, эшләр идарәсе, партия контроле комиссиясе һәм башкалар. Фән һәм уку йортлары, культура, нефть һәм химия промышленносте, транспорт һәм элемтә, промышленность, төзелеш, җиңел промышленность һәм халык кулланты товарлары, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү бүлекләре бетерелде.

Өлкә комитеты аппаратының җитәкче һәм җаваплы работникларының гомуми саны 30 – 480, бүлек мөдирләренеке – 380, бүлек мөдире урынбасарларыныкы – 310, сектор мөдиренеке – 270, инструкторныкы – 250 сум.

Моннан башка, өлкә комитеты процентка кимеде һәм хәзер ул 108не тәшкил итә. Аларның окладлары түбәндәге күләмнәрдә: беренче секретарьныкы – 600 сум, икенченеке–500, секретарьларныкы – аппаратында 43 техник хезмәткәр, техсекретарьлар, статистик-учетчылар һ. б. бар. Аларның эш хакы 90 сумнан 135 сумга кадәр. Хезмәт күрсәтүче персоналның (электриклар, сантехниклар, слесарьлар, шоферлар, җыештыручылар) эш хакы да шул чама.

Льготаларга һәм өстенлекләргә килгәндә исә, монда информация һәм хәбәрдарлык җитмәү имеш-мимешләргә һәм аңлашылмаучылыкка урын калдыра торгандыр. Шуны әзеп әйтергә була: партия работниклары өчен бернинди «аерым» льготалар билгеләнмәгән, көнгә 10–12 сәгать һәм аннан да күбрәк, шимбәләрне, ә кайвакыт якшәмбеләрне дә ял итмичә эшләү «хокукын» әйтсәң генә. Ә еллык ялны алар кайчан ала? Әйтик, партиянең шәһәр һәм район комитетлары секретарьлары өчен «бәрхет сезон» гадәттә ноябрь-декабрь айларында башлана.

Статистикадан күренгәнчә, партия работниклары арасында йөрәк-кан тамырлары авырулары аеруча киң таралган. Әлбәттә, аларга башка күп предприятиеләр һәм оешмаларда булган кебек дәвалау учреждениеләре дә кирәк, һәр партия работнигы ике елга бер мәртәбә санато-

ТР Милли китапханәсенең вакытлы матбугат бүлеге фондларыннан

рийга яки КПСС Үзәк Комитетының ял йортына путевкадан файдалана ала. Аларга түләү тәртибе профсоюздагы кебек үк – путевка бәясенең 80 проценты партия акчаларыннан түләнә. Партия органнарының җаваплы работниклары 2 нче республика больницасына беркетелгән. Ул больница 26 мең кешегә хезмәт күрсәтә, шулардан 1,5 проценты – партия работниклары.

Өлкә комитеты работникларының бер өлеше ТАССР Министрлар Советының Боровое Матюшинода урнашкан ял базасыннан файдалана. Дачалар өчен алар елга 200–300 сум акча түли.

Халык арасында еш кына партия өлкә комитетында эшләгәндә квартираны тиз алып була дип, ишетергә туры килә. Бу уңайдан шуны әйтәм: өлкә партия оешмасы бюджетында торак төзүдә пайга керү өчен елга миллион сумга якын акча каралган. Бу акчаның 30 процентка якыны Казанда, калганы республиканың башка шәһәрләрендә һәм районнарында торак төзүгә тотыла. Партия эшенең спецификасын да исәпкә алмый ярамый, чөнки өлкә комитеты аппаратына белгечләр еш кына районнардан чакырыла. Казанга килгәндә, алар квартираларын калдыра һәм безнең бурыч – аларны һәм гаилә членнарын нормаль яшәү шартлары белән тәэмин итү.

Һәм соңгысы – бюджет турында. Өлкә партия оешмасы бюджетының доход өлеше нигезен членлык партия взнослары тәшкил итә. Доходлар структурасында аларның өлеше 60 процентка җитә. Партия взносларының абсолют суммасы елдан ел арта (1988 елда 12 процентка үсте һәм 14 миллион сумнан күбрәк тәшкил итте). Бу коммунистларның саны үсүгә һәм аларның эш хакы сизелерлек артуга бәйле. Мәсәлән, быелтыр бер коммунистка уртача взнослар суммасы Татарстанда айга биш сум тәшкил итте, мондый сумма 250 сум хезмәт хакы алганда түләнә.

Керемнәрнең икенче бер өлеше – нәшрият эшчәнлегеннән доходлар. КПСС өлкә комитеты нәшрияты 1988 елда партия кассасына үз табышыннан 9 миллион сум отчисление кертте. Бу өлкә партия оешмасы доходларының 40 процентын тәшкил итә. Хәзер ул гомуми тиражы 2,2 миллион данә булган 14 исемдәге газета һәм журнал чыгаруны тәэмин итә. Яңа техника кертү, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү нәшриятка отчисленияләр суммасын ел саен арттыра барырга мөмкинлек бирә.

Һәм, ниһаять, доходларның бик аз өлешен (1 процентка якынын) «башка керемнәр» – тотылган автомашиналарны, инвентарьны сатудан кергән һ. б. акча тәшкил итә. Күргәнебезчә, доходларның төп өлешен коммунистларның членлык взнослары тәшкил итә. Эш хакы күләменә карап, взнослар ике тиеннән алып эш хакының 3 процентына кадәр түләнергә мөмкин. Партия бюджетын формалаштыруда мондый тәртип бу средстволарны тоту ышанып тапшырылырга тиешле кешегә аерулча җаваплылык йөкли, һәм ышаныгыз – акчаларның кирәккә генә тотылуына, финанс дисциплинасын үтәүгә безнең тарафтан таләп бик каты.

Партия акчалары нәрсәгә тотыла? Иң элек аларның тиешле максатка һәм КПСС Үзәк Комитетының Эшләр идарәсе раслаган суммада гына тотылуын әйтергә кирәк. Болар – партия органнарын тотуга киткән акча, монда партия работникларының эш хакы, канцелярия чыгымнары, телефоннар өчен, командировкалар өчен түләү, пленумнар һәм киңәшмәләр үткәрү чыгымнары керә. Политмәгариф йортлары һәм кабинетлары, марксизм-ленинизм университеты, партия һәм совет кадрларының квалификациясен күтәрү курслары да бюджет акчалары исәбенә эшли, бу сред стволар анда эшләүчеләр һәм укытучыларның хезмәтенә түләүгә, әдәбият һәм күргәзмә әсбаплар сатып алуга тотыла.

Партия органнарының шактый зур хуҗалыгы бар, аны тоту да байтак акча таләп итә. Болар – партиянең өлкә комитеты һәм илле шәһәр, район комитетлары биналарын, өч Ленин музеен, партия архивын тотуга чыгымнар. Инвентарьны әледән әле яңартып торырга, транспорт тотарга кирәк.

Теләсә кайсы дәүләт предприятиесендәге һәм оешмасындагы кебек үк, биналар, торак һәм башка объектлар төзү партия органнары системасында расланган планнар нигезендә эшләнә. Мәсәлән, быелтыр КПСС Үзәк Комитетының Эшләр идарәсе тарафыннан бу максатларга капитал салулар безнең республика буенча 2 миллион 100 мең сум күләмендә билгеләнде, шулардан 1 миллион 881 меңе – төзү-монтаж эшләренә. Бу сумма нигездә үзләштерелде.

Журнал укучының сорауларына җавап биреп, тагын бер кат басым ясап әйтәсе килә: партия органнарының эшчәнлеге, анда эшләүчеләрнең хезмәт-көнкүреш шартлары белән бәйле бөтен нәрсә халыктан яшерен түгел. Биредә нинди дә булса серләр юк һәм була да алмый.

МИЛЛИ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРНЕ ИСКӘ АЛЫП

Безнең журналда юридик фәннәр кандидаты Б. Железновның совет дәүләт автономиясенә багышланган язмасы басылганнан соң (№ 11, 1988 ел), Питрәч районыннан редакциягә сугыш һәм хезмәт ветераны В. Козловскийдан хат килде. Ул милләтара мөнәсәбәтләрне яхшырту, интернациональ тәрбия бирү турындагы фикерләре белән уртаклаша. «Совет власте елларында, – дип яза автор, – барлык совет кешеләренең үзаңы үсте. Шуңа күрә милли психология үзенчәлекләрен һәм хезмәт ияләренең социаль гаделлеккә омтылуын истә тотарга кирәк. Тәрбия эшен дә яңача корырга, интернациональ тәрбияне оста һәм түземле алып барырга кирәк». Шул уңайдан хатта рус милләтеннән булган кешеләрне татар теленә мәҗбүри тәртиптә өйрәтүне, уку йортларында шушы телне өйрәтә торган группалар булдыруны, дәүләт хезмәткәрләрен моңа өйрәтүне яклаучылар белән килешмәү белдерелә. «Казанда татар телендәге мәктәпләр саны кимүне,– дип яза хат авторы,– проблема дип торасы юк һәм вузларда параллель рәвештә татарча укыту оештырырга кирәк түгел. Алар барысы да дәүләтнеке һәм дәүләт телендә, ягъни рус телендә эшләргә тиешләр. Дәүләт теле – рус теле. Без һәммәбез Россия республикасында яшибез». Хатта авторның илнең кайбер регионнарындагы, шул исәптән Алма-Атадагы, Таулы Карабахтагы, Балтик буендагы тискәре күренешләрне тудырган проблемаларга карашы белдерелә. «Анда да, – дип укыйбыз, – җитәкчеләр һәм укымышлы кешеләр халыкны милләтенә карап аера, милли мәктәпләр, балалар бакчалары һәм магазиннар ача башладылар».

Редакция В. Козловский хатын телгә алынган мәкалә авторы Б. Железновка күрсәтте, аның үз фикерен әйтүен үтенде.

Хөрмәтле Виктор Алексеевич! Иң элек Сезгә минем мәкаләмә игътибар иткәнегез өчен рәхмәт. Мин бездә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә тупланган проблемаларны гадел хәл итү белән кызыксынуыгызны уртаклашам. Бу проблемалар хәзер күпләрне борчый. Сез аларга КПСС Үзәк Комитетының махсус Пленумы багышланачагын беләсездер һәм XIX Бөтенсоюз партия конференциясенең тиешле резолюциясе белән танышсыздыр, һәр халыкның милли үзенчәлеге никадәр тулырак һәм ныграк ачылса, тугандаш союзыбыз да шулкадәр баерак һәм ныграк булыр – партия әнә шуннан чыгып эш итә.

Милли үзенчәлекне ачу һәм шул ук вакытта халыкларның союзын ныгыту ни дигән сүз? Минемчә, һәр халык үзен үз җирендә хуҗа итеп тойсын, кыерсытуны, социаль гаделсезлекне сизмәсен өчен, һәр милләтнең һәм халыкның, һәр республиканың һәм бөтен илнең мәнфәгатьләре кушылсын өчен бөтенесен эшләргә кирәк, һәм безнең һәрберебез, башка совет республикасына барып чыккач, үзен өендәге кебек хис итәрлек булсын, димәк, аның теле, гореф-гадәтләре һәм башка аермалыклары башкалар тарафыннан үзләренеке кебек үк ихтирам ителсен.

Ә хәзер башкасын күз алдына китерегез. Сезгә күршегез болай ди: «Минем белән минем телдә генә аралашыгыз, һәммә нәрсәне минемчә эшләгез, синең телеңдә, гореф-гадәтләреңдә минем эшем юк». Алай гына да түгел, ул сезнең балаларыгызны ана телләренә өйрәтүне һәм сезнең милли үзенчәлегегезнең саклануын артык дип саный. Сез үзегезне кыерсытылган

ТР Милли китапханәсенең вакытлы матбугат бүлеге фондларыннан

итеп хис итмәс идегезмени? һәм бу яхшы күршелек мөнәсәбәтләренә булышлык итәрме? Әгәр сезнең культурагызны үстерүгә, тормыш хәлегезне яхшыртуга бары тик Сез башка милләттән булган өчен генә аяк чала башласалар, Сез үзегез үк хатта әйткән ситуация килеп чыгарга мөмкин, ягъни: «Менә сезгә Таулы Карабах!» Бу өлкәдә яшәүче әрмән халкының ихтыяҗларына Азәрбайҗандагы элекке җитәкчеләрнең игътибарсыз каравы, Әрмәнстандагы һәм Таулы Карабахның үзендәге бюрократларның битарафлыгы белән бергә кушылып, милләтчеләр өчен бик бәрәкәтле җирлек булды, автономияле өлкәдә һәм аның тирәсендә күңелсез вакыйгаларга китерде.

Юк, Виктор Алексеевич, массаларны интернациональ тәрбияләү һәм халыкларны якынайту аларның милли үзенчәлеген югалтуга корыла дип уйлавыгыз һич дөрес түгел. Дөресен әйтим, без барыбыз да диярлек бу җәһәттән ялгыш фикердә тордык, кешеләрнең ана телләрен һәм үз культураларын онытуына куана язып йөрдек, бу процесста милләтләрнең «якынаюын» күрдек. Команда-бюрократлык системасы шартларында безгә азчылык халыклар тизрәк ассимиляцияләшсәләр, зур милләтләр, беренче чиратта руслар, аларны күбрәк йота барсалар, без коммунизмга якынрак булырбыз кебек тоелды. Ләкин шул ук вакытта, бездә социалистик интернационализм тантанасы турында сүз куерту белән бергә, халыкларның ерагаю процессы барды, милли үпкәләр ишәйде, чын милли бюрократик элита, адыловчылык тамыр җәйде, бөтен-бөтен республикаларның башында торган һәм хәтта үзәктәге коррупцияләнгән элементлар үз халыкларының мәнфәгатьләрен кысты. Ә без боларны күрмәдек.

Таулы Карабах та, Сумгаит та, башка күп нәрсәләр дә чынлыкта әнә шуннан килеп чыкты, һәм бу бүген генә башланмады, ә Сталинның шәхес культы елларында, бөтен-бөтен халыклар репрессиягә дучар ителгәндә, тыштан караганда бөтенесе имин кебек тоелган шартларда башланды һәм торгынлык елларында үсеш алды. Ә без бу проблемаларны чынлап торып хәзер генә, демократияләштерү һәм ачыклык тышкы ялтырауны бетергәч кенә күрдек, һәм моның өчен, сез раслаганча, «кешеләрне милләтләренә карап бүлгәләргә телиләр», дип галимнәрне гаепләргә ярамый.

«Татарларның 2,2 проценты татар телен белмәүгә, ә республикада яшәүче русларның 0,81 проценты гына татарча белүгә офтанып торасы юк», – ди язасыз Сез. Ә мин исә киресенчә уйлыйм: беренчедән, теләсә кайсы халыкның үзенең уникаль культурасын һәм телен югалтуы совет халкының бөтен күп милләтле культурасын ярлыландыра; икенчедән, бер-береңне ихтирам иткәндә, танып белгәндә, милли культуралар бер-берсен баетканда гына халыкларның чын дуслыгы һәм якынаюы мөмкин. Бүтән юл юк!

Сүземне йомгаклап, дәүләт теле турында да әйтим. Сез – бу төшенчәгә каршы түгел, ләкин безнең Татарстанда дәүләт теле татар теле түгел, бәлки рус теле булырга тиеш дип исәплисез. В. И. Ленинның С. Г. Шаумянга язган хатындагы сүзләрне исегезгә төшерим «Бик күп вак һәм артта калган милләтләр өчен рус теленең прогрессив әһәмияте булды – бу бәхәссез. Ләкин, әгәр ирексезләү булмаса, аның прогрессив әһәмияте тагын да күбрәк булыр иде, Сез шуны күрмисезмени? Соң, «дәүләт теле» рус теленнән күңел кайтаручы таяк түгелмени?» (Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 19 том, 492 бит).

Гомумән исә В. И. Ленин «дәүләт теле» дигән төшенчәнең үзенә үк каршы булды, һәм мин милли республикалар, шул исәптән Татарстаннан кайбер иптәшләрнең һәркайда хокукый нигезләрдә дәүләт телләрен, димәк ки, алар белән бәйле котылгысыз хокук чикләүләрен кертүне дәгъвалавы белән килешмим. Рус теле дә, башка телләр дә һәркайда фактта да, юридик яктан да тигез булсын. Ике, өч теллелек, милли телләрне дә, халыкара аралашуда куәтле корал булып торган рус телен дә тигез белү алга китсен. Ә иң мөһиме– барлык телләрне өйрәнү фәкать ирекле нигездә генә барсын.

БУЫННАР

Бик тиздән Татарстан Республикасы төзелүгә 100 ел тулачак. Түгәрәк һәм мөһим юбилей – гасыр гына түгел, тулы бер тарихи дәвер!

Шул ук 2020 елда 100 еллыгын билгеләп үтәчәк «Татарстан» журналы уртак юбилей хөрмәтенә «Буыннар» проектын эшли. Без анда Татарстаныбыз тарихында эз калдырган шәхесләр, вакыйгалар, күренешләр турында сөйлибез. Без инде 20 нче елларда республиканы оештырган шәхесләр турында яздык. Моңа кадәр күрелмәгән энтузиазм һәм коточкыч кырыс репрессияләр елларында яшәгән 30 нчы еллар, Бөек Ватан сугышын кичеп, аннан җиңүче булып чыккан 40 нчы еллар, сугыш афәте җимергән шәһәрләрне торгызган, нефть сәнәгатен күтәргән 50 нче еллар, галәмне буйсындырган 60 нчы еллар, иҗат итеп, төзелешләрдә эшләп, үзенә торгынлык еллары дигән ярлык тагыласын белмәгән 70 нче еллар буыннары турында да сөйләдек.

Бүген бездә кунакта – 80 нче еллар буыны. Алай ук ерак та түгел, күпләр өчен бик якын ул, чөнки без йә тумышыбыз, йә балачагыбыз һәм яшьлегебез белән 80 нче еллардан…

1980 нче еллар

ДИСКО БУЫНЫ

Без барыбыз да йә тумышыбыз, йә балачагыбыз, йә яшьлегебез белән 80 нче еллардан. Шуңа да сезне иң чая буын яшәгән 80 нче елларга чакырабыз – без анда очрашканбыз, очрашабыз, очрашачакбыз. 80 нче еллар дискотекасы кебек онытылмастай күңелле кичәләр, «су буенда янган учак», «Бони Эм»нар көткән чакка – диско буыны яшәгән вакытларга чакырабыз.



1 НЧЕ ТАРИХ

КАЗАН. ПАРАЛЛЕЛЬ ДӨНЬЯЛАР

80 нче елларда башкала ничек яшәгән

2 НЧЕ ТАРИХ

«АТЫП ҮТЕР!»

Ничек итеп Дәүди яралы иптәшләрен ут астыннан алып чыккан

3 НЧЕ ТАРИХ

«СОВЕТЛАР СОЮЗЫНЫҢ БАРЛЫК СӘЯСИ ТОТКЫННАРЫН АЗАТ ИТӘРГӘ!»

Чистай төрмәсенең сәяси блогында кем ачлык игълан иткән

4 НЧЕ ТАРИХ

«СУ БУЕНДА УЧАК ЯНА...»

Хәтер дулкыннары буйлап фотосәяхәт

5 НЧЕ ТАРИХ

РИВАЯТЬКӘ ӘЙЛӘНГӘН ХЫЯЛ

Камал театры Кабан күленә ничек «йөзеп» килгән

6 НЧЫ ТАРИХ

ВИДАКНЫ ФАТИРГА АЛЫШТЫРАМ

Видеосалон хуҗаларына «баллы клиентлар» нинди табыш китергән

7 НЧЕ ТАРИХ

80 НЧЕ ЕЛЛАР ДИСКОТЕКАСЫ

Ни өчен кешеләрнең романтикага кайтасы килә

8 НЧЕ ТАРИХ

НАРАЯМА ТУРЫНДА РИВАЯТЬ

Ни өчен Казан кинотеатрлары иртәнге биштән эшли башлаган

1980 нче еллар

ТАССР 100 лет / ел

ХРОНОГРАФ



1981

- Татарстанда икенче миллиард тонна нефть чыгарыла
- Казан янында Займищедан Идел аша күпер төзелеше башлана

1982

- Яр Чаллы шәһәренең исеме Брежневка үзгәртелә
- Казанда Шаляпин исемендәге беренче опера фестивале үтә (1985 елда ул бөтенроссия статусын ала)
- Казанның «Оргсинтез» заводында «Этилен-200» җитештерелә башлый

1983

- «Оргсинтез»да елына 200 мең тонна куәт белән түбән басымлы полиэтилен җитештерелә башлый

1984

- Алабугада Кама трактор заводы төзелеше башлана
- ТАССР Югары Советы Президиумының ТАССР дәүләт бүләкләре нигезләмәсен раслау турында Указы чыга

1986

- Казанда таможня барлыкка килә
- Хәрби комиссариаттан мобилизацияләнеп, татарстанлылар Чернобыль АЭС афәтен ликвидацияләү эшендә катнашырга китәләр

1987

- Казан аэропортыннан беренче халыкара рейс башкарыла. ТУ-154 Берлинга оча
- Түбән Кама гидроагрегатларының барысы да кулланылышка тапшырыла

1988

- Кама трактор заводын ЕЛАЗ җиңел машиналары җитештерә торган завод итеп үзгәртү турында карар кабул ителә
- Әлмәт янында кыю фәнни тәҗрибә башланып китә – Яңа Елховойда үтә дә тирән скважина бораулыйлар. Проект тирәнлеге – 7000 метр
- Татариядән Әрмәнстанга җир тетрәү нәтиҗәсендә хәрабә хәленә килгән шәһәрне торгызу эшләренә төзүчеләр отрядлары җибәрелә

1989

- ТАССР Министрлар Советының халык мәгариф системасында туган телне һәм әдәбиятны укытуны яхшырту буенча Карар кабул ителә

1989

- Казан янында Идел аша автомобильләр йөрү өчен күпер кулланылышка тапшырыла

КАЗАН. ПАРАЛЛЕЛЬ ДӨНЬЯЛАР

1980 нче еллар башы Казаны, май. Урам тузаны һәм алмагач чәчәге исе бергә кушылып, биредә җитештерелә торган «Слеза Мичурина» төнәтмәсеннән дә болайрак исертә. Дөрес, сиреньнең хуш исе Кабан күленнән күтәрелә торган тынчу күкертле водород исен бераз баса. Динамиктан яңгыраган «магнолияләр иле» турындагы шлягер исә чынбарлык хакында уйланырга мәҗбүр итә...

Автор:
Әскәр Сабиров

Чынлыкта исә бернинди сюрреализм да юк боларда. Моннан йөз ел элек вакыт туктап калган иске Казан бакчалары май аенда тоташ чәчәккә күмелә. Сукно бистәсе алачыклары, Вишневскийдан Жданов урамына (булачак Эсперанто) төшкәндә кырыйда кала торган кыекмыек йортлар, Калинин, Островский, Тихомирнов урамнарындагы череп каралган агач өйләр бер-ике атнага аклы-шәмәхәле томан эчендә югала... Тәүге ләйсән яңгырында ук лыгыр пычракка әйләнә торган тузан фәкыйрь капка төпләреннән генә күтәрелеп калмый, бу – бирегә үзгәрешләр җиле ташый торган тузан. Ул җил «гасыр төзелеше» – Ирек мәйданыннан ерак түгел урнашачак Ленин мемориалы, Татарстан урамындагы төзелүе бик озакка сузылган Камал театры бинасы ягыннан исә. Башка, өр-яңа, панельле-типовой Казан салынып яткан Кварталлар һәм Горки микрорайоны тарафыннан исә. Җирле йолдыз Ренат Ибраһимовның «тормыш һәм мәхәббәт хакында иркенләп сөйләп була торган» ил турындагы шлягеры исә – иртәгәдән бүгенгә сәлам кебек... Параллель дөньялар.

СЫЙНФЫЙ ИДЕЯЛӘР КРЕМАТОРИЕ

Ленин мемориалын берничә елдан соң, чираттагы бөек революцион бәйрәмгә – Казан студентлары сходкасының 175 еллыгына тәгаенләп төзеп бетерәчәкләр. Казанга килгән шагыйрь Евгений Евтушенко совет архитектурасының әлеге котсыз могҗизасына озак карап торачак, аннары исә үз талантына табынучыларга:

– Казансу буендагы калкулыкта урнашкан һәм крематорийга охшаган

әнә теге бинаның нәрсә икәнен һаман аңламадым мин, – диячәк...

Билгеле, архитектор ул бинаны бөтенләй башкача күзаллаган. Бина җилдә җилфердәгән пролетарийлар байрагын хәтерләтергә тиеш булган, әмма акчаны кискәннәр, проектны гадиләштергәннәр – һәм карета кабакка әйләнгән дә куйган. Әмма эчтә барысы да тиешенчә. Партия документларының «бәһасез» күчермәләрен чырайны сытмыйча карап та булмый, ә бит биредәге экспонатлардан халык массаларының кәефен, рухын күтәрерлек энергетика ташып торуы планлаштырылган.

Гомумән, идеологик акцияләргә акча кызганмыйлар. Бoҗра янындагы калкулыкта – тагын бер колачлы төзелеш. Биредә, шәһәр салу пропорцияләрен һәм перспективаларын санга сукмыйча, ялкынлы революционер Мулланур Вахитовка һәйкәл куеп яталар. Циклоптай фигура әлеге күркәм урынның доминантасын – финанс институтының затлы бинасын каплап торачак. Әмма революционерга барысы да рөхсәт ителә. Партия монументалистикасы җәүһәре өчен урын әзерләгәндә «Вузовец» кинотеатры һәм берничә дистә борынгы күркәм бинаның да җимерттерелүе вактөяк кенә бит...

Хәер, идеология кайвакыт үз корбаннарына файда да китерә икән. Уйламаган җирдән Мәскәү Ленино-Кокушкиноны төзекләндерүгә күп акча бирә. Янәсе, революцион идеяләре белән рухланган Ильич үзенең беренче сөргенен үткәргән урын муллык витринасына әйләнергә тиеш – ахыр чиктә, «Аврора» тикмәгә генә туптан атмаган бит инде...

Төзелешне партия өлкә комитеты махсус контрольдә тота, планеркаларны ТАССР Министрлар Советы рәисе урынбасары Мөхәммәт Сабиров үткәрә. Нәтиҗәдә сходка юбилеена әлеге гади авыл халкы шәһәр халкына әйләнә яза: асфальт, бөтен уңайлыклары булган фатирлар, кафе, универсам, мәдәният йорты. Тагын әле почта, телефон, телеграф – кабат революция ясасаң да була...

Табигый ки, буш урында өр-яңадан Бланк утарын да торгызып куялар. Югыйсә әллә ничек бит: Ильич крестьяннарны азат итү өчен көрәшкән, алар исә революция башлангач, беренче эшләре итеп, аның бабасының утарына ут төрткән...

АЛГА КИТКӘН СОЦИАЛИЗМНЫҢ ТУЗГАН ЙОРТЛАРЫНДА

Казанда тузган торакта яшәүчеләр Ленино-Кокушкино халкыннан үлеп көнләшә. Чәчәк аткан бакчалар артына унтугызынчы гасыр башы көнкүреше посркан, чөнки. Биредә рәсми идеология – үткән телләрне чарлау өчен сәбәп кенә. Казанның статуслы Ленин яки Карл Маркс урамнарын Беренче май бәйрәмендә бизи торган «Партиянең югары максаты – халыкның рәхәт яшәве» шигаре башка – Свердлов, Киров, Луковский яки Волков урамнарында мәсхәрәләү сүзе кебек яңгырый.

Ә бит 80 нче еллар Казаны мәрткә китүдән айнырга тиеш кебек иде. Елга аръягы һәм Горки бушлыкларында төзүчеләр тугыз катлы йортларны коймак пешергән кебек шапылдата гына, һәм зур оборона заводында, нефть химиясе тармагында эшләүче аеруча кирәкле хезмәткәрләргә егерме биш ел



Фото: Е. Канаев

буе торак чиратында торасы, гомерләрен тулай торакта уздырасы юк…

Өмет барын бар да бит, әмма Казан үзәгендәге җимерек йортларда яшәүчеләргә бу гына җиңеллек китерми. Аларның чын «уңайлыклары» чынлыкта бик сасы исле. Ишегалдындагы бәйрәм хөрмәтенә агартылган бәдрәфкә Максим Горький яшьтәше булган агач йортта яшәүче ике дистәләп кеше бертуктаусыз йөргәч, тагын нинди ис килсен инде аннан?! Революция җырчысы сурәтләгән ночлежкалардагы кебек үк, халык бик тыгыз яшәгән фатирларда һаман канализация дә, сууткәргеч тә юк…

Биредә яшәүчеләрнең – үз шигарьләре. Кремль янындагы иске йорт диварына зур итеп «Мы заложники трущоб» дип язып куя алар. «Здесь живут люди. Спасибо правительству за заботу» дигәнен Киров урамындагы коммуналка фасадына эләләр… Алга киткән социализм чорында мондый лозунглар өчен төрмәгә утыртмыйлар инде. Аларны нибары тиз-тиз буяп куялар, тик бераз вакыт үтүгә үк, язулар кабат пәйда була.

Әмма, яхшыга үзгәрешләрне бер дә күрмичә, нигә партиянең ачуын чыгарырга соң? Хәзер Казандагы барлык фатирларда диярлек газ бар, суга исә колонкага, күрше тыкрыкка гына, барып кайтып та була. Дөрес, кышкы салкыннарда колонкалар барысы да диярлек туңа, һәм өйгә чираттагы ике чиләк суны алып кайту челюскинчылар батырлыгын хәтерләтә: суы туңмаган колонкага кадәр егерме минут барасың, утыз минут чиратта торасың, һәм аннары – өйгә кадәр тагын егерме минут кайтасың. Бездә төзелеп беткән социализм турында имтихан бирергә әзерләнүче студентларга бик җайлы. Чиратта туңып торганда, күптән түгел генә бакыйлыкка күчкән Леонид Ильичның хезмәтеннән, мәсәлән: «Конкрет кеше, аның ихтыяҗлары һәм хаҗәтләре турында конкрет кайгырту – партиянең икътисадый сәясәтенең башлангыч һәм азаккы пункты», – цитатасын ятлыйсың.

Аның каравы, хәтта җимерек йортларда да кайберәүләрнең телефоны бар. Телефон номеры алу – лотерея оту кебек, чират әллә ничә елга сузылган. Әмма сиңа да, күршеләреңне сөендереп, үз гомереңдә бер тапкыр бәхет елмаерга мөмкин икән бит. Ә инде бәхеткә ирешкәч, иртәдән кичкә кадәр чит шалтыратуларга җавап бирәчәксең һәм сөйләшү өчен икенче каттагы Надя түтине, беренче каттагы Биби апаны яки каршы йорттагы Абрам дәдәйне чакырырга тиеш булачаксың. Чакырмый ярамый. Биредә партия Уставы буенча түгел, ишегалдының язылмаган кодексы белән яшиләр…

ИКМӘК ҺӘМ ТАМАША

Тик шулай да 80 нче еллар уртасыннан халык иркенрәк сулыш ала. Сәясәт турында инде Колхоз базары янындагы балык тәңкәсенә чумган пивнушкада басып түгел, бәлки Европадагыча уңайлы барда табын янында фикер алышырга мөмкин була башлый. «Раки» яки «Бегемот»та. Яки хәтта Чернышевский урамында ачылган купшы «Грот-барда». Бу биналарга сирәк кенә студентлар кергәли, биредә бай яшьләр кәеф-сафа кора, аларга хәтта чит ил кешеләрен чакырырга да оят түгел.

Берничә ел элек кенә бирегә үзенең поляк коллегасын алып кергән өчен республика газетасы журналисты Владимир Устиновскийның чак кына эшеннән куылмыйча калуын белгәнгә, бу бик гаҗәп тоела. Ничек белгәннәр диген әле бу турыда! КПСС өлкә комитетына бер аноним Польша басмасының тышлыгын җибәргән. Анда исә – гайре табигый хәл! – совет журналисты пивбарга кереп бара…

Хәзер исә Яшьләр үзәгендәге «Кино дуслары клубында» (абонемент буенча гына керергә мөмкин) башкаладан килгән танылган режиссёрлар үзләренең цензура белән көрәше хакында сөйли һәм аздан гына киштәгә куелмый калган фильмнарын күрсәтә. Рязановның «Гараж» фильмы – исемлектә беренче. Биредә, шул ук Яшьләр үзәгендә, алдынгы карашлы студент яшьләр «Үзешчән сәнгать җырлары клубында» бардлар белән очраша. Тиздән биредә Булат Окуджава үзенең тиләләр һәм акыллылар турындагы атаклы җырын башкарачак…

Хакимият күп кенә иркенлекләргә бармак аша карый, хәтта әкренләп тимер пәрдә дә күтәрелә башлый. 1987 елда Казан чик буе шәһәренә әйләнә – аэропортта таможня ачыла. Бер-ике айдан, майда, бирегә Лейпцигтан немец туристлары төялгән самолет киләчәк, беренче совет пассажирын исә – чартер рейсына очрак-

лы гына билет алган яшь лейтенантны – Чкаловны зурлагандай каршы алачаклар.

Әмма Казаннан туры чит илгә китеп булмый әле – билетлар сатылмый. Хәтта социалистик илгә дә – бары тик Мәскәү аша, бары тик төркем белән генә.

1986 елның апрель азагында КАМАЗның яшь эшчеләреннән һәм интеллигенция вәкилләреннән торган шундый төркемнәрнең берсе Чехословакиягә юнәлә.

– Без сезгә бүләк ясарга булдык, – диячәкләр турны оештыручылар төркем җитәкчесе, комсомол хезмәткәре Владимир Фоминга. – Тур программасында Киев юк иде, хәзер исә анда ике көн йөриячәксез, экскурсия үткәреләчәк, отельдә куначаксыз.

Моның нинди бүләк икәнен төркем тиздән аңлаячак. Киев аларны буш урамнар, су сиптерә торган машиналар колоннасы һәм спиртлы эчемлек тулы кибетләр белән каршы алачак. Бу Чернобыль АЭСындагы һәлакәттән соңгы бишенче яки алтынчы көн булачак...

СИН МАЛ ТАБУЧЫМЫ, ЮКМЫ?

1983 елның октябре. Иделнең Звенигово янындагы яры. Бирелдә гасыр газүткәргече Уренгой-Помары-Ужгород торбасын елга төбеннән менә-менә сала башлаячаклар. Казаннан килгән журналистлар суык сөякләренә кадәр үтеп туңган – алар инде берничә сәгать буе торбаның «Покорись, Волга!» дип язылган башы (дюкер) суга кереп киткәнне көтә. Әмма иң җаваплы мизгелдә кемдер:

– Егетләр, анда тушёнка китерделәр! – дип кычкырмасынмы.

Дүртенче хакимият, партия журналистикасының асыл ирләре, ике дә уйламый, шул якка йөгерә. Дюкерның су астына китүен бик аз кеше генә күреп кала...

Тушёнка банкасы гигант планнарга караганда ышанычлырак – конкретрак шул. Дөрес, КАМАЗ төзелешен үз җилкәсендә кичергән казанлыларга (ул дәвердә башкалада кайвакыт хәтта бәрәңге дә талон буенча бирелә) сиксәненче еллар башы хәтта бай кебек тә тоела әле. Хәзер Татарстан башкаласы – миллион кеше яшәүче шәһәр, СССРда бу статус метро турында хыяллану һәм нинди дә булса Саратовтагыга караганда яхшырак ашау хокукы бирә.

Чыннан да, атланмай инде талонсыз сатыла, Баумандагы «Сөт ризыклары» кибетендә исә хәтта сөт өсте һәм заварной пирожный да сатып алып була, соңгысын шәһәр читеннән дә эзләп киләләр. Көнбагыш кебек арзан креветка һәм кальмар сәрхушләрнең яраткан ризыгы булса, үзләрен хөрмәт итүче шәһәр халкы кайнар ысул белән ысланган экзотик исемле простипома балыгына һәм контрабанда юлы белән Әстерханнан литрлы банкаларда кайтартыла торган кара уылдыкка өстенлек бирә.

Ә менә фил төшерелгән чын һинд чәе, эри торган кәһвә, ит, тавык кибетләрдә һаман күренми. Әмма моңа казанлыларның бер өлешенең исе дә китми. Берәүләр – КПСС җитәкчелек иткән илебездә шулар рәтеннән булучылар – Маяковский, Гоголь яки Париж Коммунасы урамнарындагы затлы йортларда яши, эшкә хөкүмәт машинасында йөри, дефицит ашамлык тутырылган пөхтә пакетларны аларга заказ буенча китереп бирәләр.

Икенчеләр, параллель дөньяда яшәүчеләр, якты киләчәк турында вәгъдәләргә ышанмаска кирәклекне яхшы белә һәм үзләрен үзләре кайгырта. Казан елга портыннан һәр сәгать саен китүче «Ракеталарга» утырып, алар Новочебоксарскига юл тота. Анда, күршеләрдә, люизит җитештерү буенча яшерен завод һәм Мәскәү тәэминаты – тавык кына түгел, хәтта чит илдә тегелгән кием-салым да табарга була.

Нинди дә булса модалы һәм чит илдә җитештерелгән әйбер табуның тагын бер юлы – ЗАГСка гариза бирү. Кыюлык өчен бүләк – махсус кибеткә талон, анда ГДРда тегелгән туй күлмәген, Чехословакиянең ЦЕБО фирмасы туфлиләрен, һәм Польшада тегелгән, Карденнан диярлек килеп төшкән костюмны кулга төшерергә мөмкин. Яхшы белә торган кешеләр әйтүенчә, бернидән дә куркырга кирәк түгел – хәзер инде өйләнешмәсәң дә була хәтта, әйберләрне барыбер кире алмыйлар...

Тагын берничә елдан, үзгәртеп кору белән бергә, Казанга кабат талон системасы әйләнеп кайтачак. Үзләренә тиешле май, чәй, иткә чират торганда, халык парадоксаль әйбергә аптыраячак: иркенрәк сулыш алган саен, нигә кибетләрдә товарлар азрак һәм чиратлар озынрак була икән? Хәбәрдарлык чорының шәраб бүлекләре исә сталинизм заманын хәтерләргә мәҗбүр итәчәк: талон буенча аракыны корыч рәшәткәле тәрәзәдән бирәчәкләр. Горбачев яңалыгы – эчкечелеккә каршы көрәшнең кызган мәле...

Ил упкынга тәгәри, ә параллель дөньяда, партия кабинетларында, һаман план коралар. Кама Аланында Татар атом станциясен салырга керешәләр. Алабугада КАМАЗ төзелешенә тиң гигант төзелеш гөрли – бирелдә елына 150 мең (!) данә трактор җитештерәчәк завод салырга ышандыралар. Аннары трактор заводын «Фиат» җитештерә торган автомобиль заводына әйләндерәчәкләр. Ахыр чиктә, «Фиат» урынына «Ока» җыярга карар кылачаклар...

Нәтиҗәдә Татар атом станциясен, төзеп бетермичә, ябалар. Алабугада трактор заводы да, гигант автозавод та чынга ашмый кала.

Мөгаен, унъеллык азагында күпләр аның ничек башлануын исенә төшерер. Олимпия аюының һавага күтәрелүе, елмаюы, күзеннән яшь тәгәрәү... Шундый булып чыга да шул әлеге дистә ел: дулкынландыргыч, моңсу. Илнең соңгы унъеллыгы...

СОҢГЫ КАҺАРМАН

…Тирә-якта – үләнләр, бер куак әсәре дә күренмәгән тау битләре, Герируд елгасының кипкән үзәне. Әфганстанның Иран белән чигендәге әлеге җирендә 1986 елның 23 августында өлкән сержант Ильяс Сафин (Дәүди) үзенең соңгы сугышына күтәрелә. Ул ут астында шуышып барып, өч яраланган сугышчыны яу кырыннан алып чыга, ә үзе, минага эләккәннән соң, иптәшенә: «Атып үтер!» – дип боера.

Россия Герое Ильяс Дәүди бюстын туган ягы Азнакайда 2011 елда куялар. Тантанада Ильяс Дилшатович та катнаша, бронзада түгел. Тере килеш! Разведрота командиры урынбасарының соңгы боерыгын солдатлар үтәми...

КОКАРИ-ШАРШАРИ. «ТОЗАК» ОПЕРАЦИЯСЕ

1986 елның 21 август иртәсе. Әфганстанда «Тозак» («Западня») дигән яшерен исем астында хәрби операция башлана. Мөҗәхитләрнең Кокари-Шаршари янындагы шактый көчле ныгытылган районына десант төшереп, дошманга кинәт кенә һөҗүм итәргә карар кылалар. Максат – корал базасын юкка чыгару, дошманны ныгытылган урыныннан куып чыгару... Ильяс үзенең взводы белән бергә вертолетка төялә, ярты сәгатьтән соң алар инде тиешле «нокта»да була. Ләкин җирдә аларны көтеп торганнар булып чыга – десантчыларга каршы миномётлардан ут ачалар...

Ильяс хезмәт иткән батальонга таулар аша тиз арада дошман позицияләренә барып җитәргә дигән бурыч куела. Сафин, комбат боерыгын үтәп, разведкага барырга тиешле төркем туплый:

– Миңа сапер, элемтәче, ике пулеметчы һәм ике автоматчы кирәк...

Полк командиры Александр Скородумов, яңа максхалат кигән егетне күзәткәндә, үзенең күптәнге танышын төсмерләп ала. Гвардия өлкән сержанты – полкта аны белмәгән кеше юктыр. Әгәр кайдадыр уставта каралмаган «сабантуй» оештырыла яисә азык-төлек складында берәр нәрсә югала икән – туп-туры Сафинга барырга кирәк... Әмма полкта «хулиганны» яраталар, чөнки сугыш кырында батыр – һәркем сокланырлык! Иптәше өчен җанын фида кылырга да әзер – тикшерелгән!

БЕРЕНЧЕ ЙОЛДЫЗ

1985 елның октябре. Баглан провинциясенең көньягы, Андарабад үзәнлеге. Кышлакларның берсе янында солдатлар әле генә «духлар» киткән тау куышлыгына керәләр. Казандагы пылау суынырга да өлгермәгән. Өстәлдә – документлар, бандага кергәннәрнең фотографияләре. Күрәсең, бу кыр командирларының берсенең команда пункты, ашык-пошык ташлап киткәнгә охшаган.

Рота командиры өлкән лейтенант Холтураевка һәм рядовой Сафинга кайнар эзләр буенча разведка ясарга кушыла. Сугышчылар тарлавыкка төшәләр, шунда ук аларга төбәп ата башлыйлар. Көтеп торганнар!

Ильяс, ата-ата, ышык урынга барып җитә ала. Холтураев бераз арттарак йөгерә һәм кинәт кенә сөрлегеп егыла. Ул йөз метрда гына ята, туктаусыз ут яңгыры астында. Батыр яу кырында беленә диләр: Сафин артка – Холтураевка таба шуыша, аннан ачык җир өстеннән иптәшен балчык стена ышыгына таба сөйри. Үзенә бернәрсә дә булмый – тырналган урыны да юк. Холтураевка ярдәм күрсәткәч, дошманга каршы ут ача.

Ул кырык минут берүзе дошманга каршы тора. Ярдәм килеп җитеп, ике ут ноктасын юкка чыгарганчы атыша. Һәм офицерны үлемнән саклап кала. Әлеге кыюлыгы өчен аңа беренче сугышчан орден – «Кызыл Йолдыз» тапшырыла.

Бокс буенча спорт мастерлыгына кандидат Сафинның армиядәге «картлар» белән мөнәсәбәтләре баштарак бик җылы булмый. Тегеләре дә: «Син палаткада гына кыю, сугышта карарбыз әле...», – диләр. Андарабад үзәнендәге хәрби операция 18 яшьлек егет өчен беренче җитди сугышчан сынау була. «Картларга» башка бернәрсә дә исбатлап торырга кирәк булмый...

АКОКАРИ-ШАРШАРИ. «ТОЗАК» ОПЕРАЦИЯСЕ

Өлкән сержант Сафин төркеме ашыгыч рәвештә алга атлый. Сугыш аккомпанементы астында тау сукмаклары буенча өч сәгать – һәм разведка батальонны тиешле биеклеккә китерә. Мотоукчылар үз урыннарын алырга өлгерми, яңадан ут ташкыны күтәрелә. Хәзер инде аларга каршыдан орудие, гранатомет, пулеметлардан аталар.

Подразделение түгәрәкләнеп саклану өчен тарала, ләкин сугышчылар бер-бер артлы минага эләгә башлый. Өчәү, бер-бер артлы... Мина кыры! Ильяс, сугышчыларга үзен ут белән каплап торырга әмер бирә дә, кулына сапер эзләгече алып, яраланганнарга ярдәмгә ашыга. Беренчесенең, икенчесенең, өченчесенең яраларын бәйли, коеп торган ут астында мина кырыннан сөйрәп чыгара...

Ә сугыш тынарга да уйламый. Бер тәүлек, икенчесе... Су, боеприпаслар бетә. Дошман зениткаларыннан кача алган «вертушкалар» резина савытларда аска су ташлыйлар, ләкин алар ташка төшеп ярыла: бик биек, ә түбәнрәк төшеп ташлау мөмкин түгел... Кырык градустан артык эсселек, солдатлар сусызлыктан интегә, әмма алар сугыша һәм бары тик бер нәрсә турында гына уйлый – патроннар гына җитсен...

Патроннарны һәм суны вертолетлар бары тик 22 августтан 23енә күчкән төндә генә китерә алалар – кирәк-яракларны алгы сызыктан еражтарак, арырак булган биеклеккә төшерәләр. Рота командиры өлкән сержант Сафинга йөкне алып кайту өчен биш сугышчы бирә. Ильяс дүрт фамилияне атый:

– Өлкәнегез булып үзем барам. Ул сукмакларны мин беләм.

– Син миңа монда кирәк!

Ләкин Сафин үзенекендә тора: вакыт бар әле, сугыш иртәнге алтыдан да иртәрәк башланмаячак.

Мөҗәхитләрнең бу сукмакларга миналар куярга өлгерүен белмиләр шул...

ВОЕНКОМ КАПИТУЛЯЦИЯСЕ

Әфганстанга ул үзе теләп китә. Азнакайда ихтирамга лаек инженер-нефтьче һәм бала тудыру йорты мөдире гаиләсендә туып-үскән егет абруйлы башкала вузында укый. «Койрыклары» да, тәртибе буенча да проблемалар юк – укы, яшә генә! Ләкин Сафин Черемушки (хәзер - Гагарин) военкоматына бара: «Мине Әфганстанга җибәрегез!» Военком егетне акылга утыртырга тырыша, ләкин тегесе үзенекендә тора. Нәтиҗәдә военком бирелә: «Ярар, таулар буйлап үрмәлисең киләдер...»

Романтик җилбәзәклекме? Чынлыкта барысы да бик җитди. Ул кая җибәрүләрен сораганын белми түгел, белә. «Ничек?» һәм «Ни өчен?» – әлеге сорауларга, мөгаен, Ильяс Сафин чирек гасырдан соң, Азнакайда үзенә Герой бюсты ачкан көндә генә җавап бирә алгандыр:

– 1983 елның язында берьюлы ике өлкәнрәк дустымның үлгәнлеге

турында язулар килде. Аларның берсе классташым Рөстәмнең абыйсы – Фәнис Гыйльфанов иде. Бүгенге көнгә кадәр армиягә озатканда аның белән «тормыш» турында сөйләшүебез исемдә. Сержант Гыйльфанов засадага эләккән сугышчан дустына ярдәмгә ашыкканда үлә. Аны күмешергә мин дә кайттым, гаиләләренә төшкән хәсрәтне үз күзләрем белән күрдем. Үлгәннәрнең икенчесе Фәнүз Гәрәев – бокс белән шөгыльләнгәндәге танышым, без аның белән ярышларда еш очраша идек. Егетләрнең үлеме мизгел эчендә минем тормышка карашларымны үзгәртте. Минем буынга шулай хезмәт итәргә, кан түгәргә туры килгән икән, мин дә әлеге сынау аша үтәргә тиеш дигән карарга килдем.

Сафин, әлбәттә, урамда бәйләнергә генә торган сугыш чукмары, хулиган түгел, әмма аны тыйнак малай дип тә атап булмый. Вак-төяккә дигән беренче акчаларын ул 13 яшендә эшләп таба. Каникулларда КАМАЗ двигательләрен солярка белән юа. Музыка мәктәбенең аккордеон классында да укый – әти-әнисе шулай тели. Ләкин музыка мәктәбеннән чыгуга, ноталарын гараж артына яшереп, бокс секциясенә йөгерә...

Спортчы әзерлеге аңа соңрак тегендә, Әфганстанда да, бик булыша. Гәрчә бокс «елга аръягына» китәргә вакыт җиткәндә, чак кына аяк чалмый калса да. Ильяс Төркестан хәрби округының Термез хәрби разведка әзерлеге үзәгендә уздырылган «учебка» полкы беренчелегендә җиңә. Алда округ ярышлары көтә, командирлар шуңа күрә сәләтле егетне үзәктә кече командир итеп калдырырга уйлый. Ә тегесе өзми-куймый үзенекен сөйли:

– Әфганстанга җибәрегез!

Үзсүзле курсантны уку часте командирына җибәрәләр. Ләкин егет үз сүзендә нык тора.

КОКАРИ-ШАРШАРИ. «ТОЗАК» ОПЕРАЦИЯСЕ

Беленер-беленмәс таң атып килгән вакыт. Дошман әлегә дәшми. Һәм кинәт кенә тынлыкны шык иткән тавыш боза. Мина! Ильяс моны шартлау мизгеле алдыннан гына аңлап өлгерә. Шунда күкнең асты өскә әйләнә, аяклары канга бата. Ул авыртудан үзенә үзе укол ясый, жгут сала...

Госпитальдә табиблар диагноз куя: сул ботны өзгән һәм уң аякның йомшак тукымасын кыйпылчыклар аерган мина шартлау нәтиҗәсендәге яралану, авыр контузия. Ләкин анда, миналар куелган сукмакта, ул яраланган килеш җитәкчелек итүен дәвам итә. Үзе янына иптәшләренең төшүен күреп, аларны кисәтеп кычкыра:

– Туктагыз! Сапёрсыз якын килмәгез!

Беренче көннәрдән бирле бергә хезмәт иткән Абдрахман Магомедов тыңламый, әкрен генә яралы янына килә. Сафин мизгел эчендә вазгыятьне бәяләргә өлгерә: аны вертолет төшә алырлык ерак позициягә миналар куелган сукмак буйлап, ут астында алып бару кешеләрнең тормышын куркыныч астына кую дигән сүз. Шуңа күрә:

– Атып үтер! – дип боера.

Дагестан егете, әйтерсең лә, бөтенләй ишетми. Башка солдатлар белән бергә Ильясны мина кырыннан алып чыга. Берничә сәгатьтән соң аны һәм башка яралыларны вертолет алып китә ала. Сафин әле аңында була.

Ниһаять, госпиталь, каталка, аңа таба иелгән табиблар. Алар бертуктаусыз сорау бирә: «Фамилияң, исемең, әтиеңнең исеме? Подразделениең? Званиең? Вазыйфаң?» Ул җавап бирә һәм хәтта шундый авыр хәлдә дә гел сорау биреп торуларын мәрхәмәтсезлек дип уйларга да өлгерә...

СУГЫШТАН СОҢГЫ КӨРӘШ

Кайвакыт ул үзен Әфганстаннан кайткан итеп күз алдына китерә. Парад киеменнән, аксельбантлар белән, орденнарын таккан (икенче «Кызыл Йолдызын» ул Әхмәд шах Масуд мөҗәхитләре белән сугышканы өчен ала – **ред. иск.**). Үләргә мөмкинлеген дә аңлый, ләкин гарип калуны...

Госпитальдә аңына килеп, аягы юклыгын аңлый. Исккиткеч авыр мизгел, үзе өчен тормыш тукталгандай тоела аңа. Чынлыкта исә, әле бу аяксыз гомер өчен дә көрәшергә туры киләчәк. Кыр госпиталеннән аны Кабулга озаталар. Анда, үзәк армия госпиталендә, ул бер-бер артлы биш операция кичерә. Табиблар булдыра алмастайны эшлиләр – алар яраланган солдатның икенче аягын саклап калалар. Алар белән бергә Сафин да көрәшә: кайвакыт чыдап булмастай тоелган физик авыртуларга каршы. Вакытлыча авыртуны баса торган дарулар да бар, ләкин разведчик егет алардан баш тарта – ияләшү барлыкка килергә мөмкин.

– Герой! – диләр табиблар, аның ихтыяр көчен сокланып.

– Герой! – диләр аның турында күрше палаталарда яткан егетләр дә. Кокари-Шаршари янындагы бәрелештәге кыюлыгы һәм өч яралы иптәшен коткарганы

өчен, гвардия өлкән сержанты Сафинның Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителүе турындагы хәбәрне солдат радиосы инде җиткереп өлгергән була…

Ташкенттагы госпиталь, тернәкләнү үзәге. Аны туган ягына алып кайтырга дип, әти-әнисе килә. Яралар әле тартылып өлгермәгән, әмма Ильяс әтисе белән әнисен, Уфага кереп, протез куйдыртырга ризалаштыра. Әле Кабулда ук ул үзенә сүз бирә: Азнакайга исән-сау кайтырга – аны каршы алучыларның күзләрендә җәлләү күрмәскә!

Ул шулай кайтып керә дә: парад киеменнән, аксельбантлар белән, орденнарын тагып!

Ә Герой «Йолдызы»? Ул Ильясны бары тик 23 ел узгач кына эзләп таба…

ӘФГАНЧЫЛАР ТУГАНЛЫГЫ

Әфганстаннан кайтканнан соң, Ильяс институтта укуын дәвам итә, ләкин укуның беренче елы гаять авыр бирелә. Тәүлекләр буе дәреслекләр белән утыра – контузия йогынтысы фикер тупларга комачаулый. Бу сынауны да лаеклы үтә: уку йортын бишлегә генә тәмамлый.

Ләкин заманалар үзгәреп китә: СССР җимерелә, тормыш алып бару өчен базар шартларына күнегергә туры килә. Ильяс бизнес белән шөгыльләнә һәм бер генә көнгә дә Әфганстанны узган иптәшләре турында онытмый. Күпләрнең, бигрәк тә инвалидларның хәле-көнкүреше кыенлаша, ул иптәшләренә ярдәм итү өчен барысын да эшли. 1997 елда үз акчаларына 82 кеше өчен Германиядәге иң яхшы фирмаларның берсендә эшләнгән протезлар кайтарта.

Бүгенге көндә Ильяс Дилшатович – хәрби хезмәт инвалидларының Мәскәү социаль яклау фондының башкарма директоры. Фонд аның инициативасы буенча оештырыла. Үз бизнесы да бар, ул аны нульдән, үз көче белән аякка бастыра. Дәүди элеккечә үк сыйфатлы протезлар алу өчен акчасы булмаган ветераннарга, солдаттан кайтмаганнарның гаиләләренә акчалата ярдәм күрсәтүен дәвам итә… Әгәр сугышчан иптәшләре шалтырата икән, кичектергесез эшләрен читкә куеп тора: әфганчылар туганлыгы – беренче урында…

1986 елның 23 августында күрсәтелгән батырлыгы өчен Россия Героеның Алтын Йолдызын Ильяс Сафинга (Дәүдигә) 2010 елның 19 февралендә Кремльнең Георгий залында тапшыралар. Тантанада Ченстоховск Кызыл Байраклы, Кызыл Йолдыз орденлы 149 нчы гвардия мотоукчылар полкының элеккеге командиры, бүген запастагы генерал-лейтенант Александр Скородумов та катнаша. Нәкъ менә ул, Ильясның полк командиры, Кокари-Шаршари янындагы бәрелештәге батырлыгы өчен кайчандыр үзе Герой исеменә тәкъдим иткән гвардия өлкән сержантының булачагын ала алмавын ишеткәч, гаделлек тантана итсен өчен, озак еллар буена эзләнә, дәлилләр таба һәм батырлыкның эшләнгәнлеген исбатлый.

МӨҖӘХИТЛӘР БЕЛӘН – КҮЗГӘ-КҮЗ

Ильяс Дәүдинең холкын аңлау өчен, Әфганстанда булган бер эпизодны искә төшерү мөһим. Бервакыт разведвзводны стратегик яктан әһәмиятле юлны сакларга куялар. Аларның БМП машинасы янында гына – бодай кыры. Кырның хуҗасы – фәкыйрь генә әфган крестьяны бервакыт Ильяс янына килә һәм төнлә белән атмауларын сорый: янәсе, башакларга ут кабарга мөмкин. Төнлә «трассерлар» белән ату мөҗәхитләрнең кинәт кенә һөҗүм итү мөмкинлеген киметә, әмма Ильяс үтенечне кире какмый, гәрчә төнге сакны көчәйтергә туры килсә дә. Карт рәхмәт йөзеннән солдатларга көлчә белән әйран китерә башлый, ә инде Ильясның мөселман икәнлеген белгәннән соң, аңа карата мөнәсәбәте тагын да яхшыра төшә. Көннәрнең берендә ул сөйләшүләр өчен берничә… мөҗәхитне алып килә. Тегеләре, бәхетле тормыш (чит җирләрдә ятып калганчы) вәгъдә итеп, егетне үз якларына күчәргә үгетләп карыйлар.

Ильяс кырт кисә: «Мин монда үземнекеләр белән килдем һәм үземнекеләр белән китәм яисә үләм». Ә «илчеләргә» хәзер, киткәндә аркаларына атмаска сүз бирә, әмма сугышта мәрхәмәт көтмәсеннәр…

Дуслык шуның белән тәмамлана. Ләкин взвод киткәндә Ильяс трофейга килгән «Беретта»ны складта азык-төлеккә алыштыра һәм барысын да әфган картына илтә.

СОҢГЫ СҮЗ УРЫНЫНА

Үзенең улына Ильяс Дәүддин дигән исем куша. Улы хөрмәтенә хәтта фамилиясен дә Дәүдигә үзгәртә. Шулай да ата мәхәббәте улын чын ир-егет итеп үстерергә комачауламый. Ике ел элек егет солдат хезмәтен үтәп кайта – ВДВның махсус билгеләнештәге 45 нче аерым гвардия бригадасында разведчик-снайпер булып хезмәт итә.

Башкача була да алмый. Балаларны сүзләр түгел, әлкәннәрнең үрнәге, аларның гамәлләре тәрбияли. Дәүддингә һәм аның биш кыз туганына бу яктан бик уңай туры килә. Гәрчә Ильяс Дилшатович йортында герой әти турындагы сөйләшүләргә табу куелган булса да. Гаилә башлыгы шулай хәл иткән.

– Мин улымны да кисәттем: «Әтиеңнең гамәлләре турында кешеләргә сөйләп йөрү килешми, – дип аңлата Ильяс. – Үзең нинди дә булса лаеклы эш башкар һәм шул вакытта рәхәтләнеп горурлана аласың!»

Ә Әфгансанда күргәннәре турында ул хәзер яза. Аның «Записки войскового разведчика» язмалары «Армейский сборник»та дөнья күрде. Ярлы крестьян белән булган хәлләр «Плов для Шераги» хикәясенең нигезенә салынган. «Эссе раненого солдата» хәтта әдәби конкурста да җиңә.

Әфганстаннан совет гаскәрләре чыгарылганга утыз елдан артык вакыт үтте. Ләкин әле бәхәсләр һаман да тынмый: бу сугыш безгә кирәк идеме соң. Ильяс Дәүдинең моңа карата үз фикере бар:

– Әлеге сугышта катнашучы буларак, шуны әйтә алам: без анда, туганнарыбыздан һәм якыннарыбыздан читтә, үзебезнең ирләр генә булдыра ала торган авыр эш башкаруыбызга, ил өчен мөһим хәрби бурычларны чишүдә катнашуыбызга һәм моның өчен гомеребезне дә кызганмаска тиешлегебезгә чын күңелдән ышана идек.

ИРЕКЛЕ ТОТКЫН

«Советлар Союзының барлык сәяси тоткыннарын азат итәргә!» – танылган совет диссиденты Анатолий Марченко 1986 елда әнә шундый таләп куеп, чикләнмәгән вакытка ачлык игълан итә. Ачлык 112 көнгә сузыла, ә аны туктатып, ун көн узуга, Анатолий җан тәслим кыла. Бу хәл декабрь аенда, Чистай төрмәсенең сәяси блогында була. Шуннан соң бер ай чамасы вакыт үтәр-үтмәс, ил буенча тоткыннарны азат итү турында беренче хәбәрләр яңгырый.

Автор:
Ольга Туманская

ЧЫН ИР – ИНТЕЛЛИГЕНТ – ДИССИДЕНТ

1985 елның 25 октябре. СССР җитәкчелеге үзгәртеп коруга, хәбәрдарлыкка, демократиягә йөз тоту турында игълан итә. Ә борынгы Чистай төрмәсе гадәти булмаган тоткынны каршы ала.

Бик ябык, йончыган кыяфәтле, зур күзлекле һәм колагына ишетү аппараты кигән ир конвой сагында төрмә ишегалды аша уза. Ул ни күрә? Казематларның калын диварлары, рәшәткәле кечкенә тәрәзәләр… Тоткын эчке якка керә, еллар кырып таушалдырган баскычтан икенче катка күтәрелә. Тар коридор… Уң яктагы ерак тәрәзәдән күзгә яктылык бәрә. Карар өчен махсус тишем-күзләр ясалган, саллы тимер йозаклар эленгән агач ишекләр тезелеп киткән. Конвоир шуларның берсен ача. Ике ярусны төрмә сәкесе, өстәл, эчәргә яраклы су багы, вак-төяк кирәк-ярак өчен тумбалар, элгеч… Мондый «аппартамент»та Анатолий Марченко Аллаһ тарафыннан болай да саран бирелгән гомеренең кыска гына вакытын уздырачак.

Аз сүзле, тышкы яктан җитди, ә вакыт–вакыт хәтта бик караңгы чырайлы бу кеше – Советлар Союзының бөтен дөньяга танылган диссидентларыннан берсе. Мөгаен, чит илләрдә популярлыкта аның белән Солженицын да ярыша алмыйдыр. Марченконың Хрущев һәм Брежнев лагерьлары турындагы «Мои показания» китабы Көнбатышта кайнар сумсалар кебек таралып бетә. Өстәвенә, аны Америкада һәм Европада популяр «Ридерз Дайджест» бастырып чыгара.

Гап-гади Себер ир-атын язмыш җилләре диссидентлык чоңгылына кертеп җибәрә. Шул ук мизгелдә диярлек ул «ризасыз» зыялылар арасында үз кешегә, ә хакимият өчен персона нон грата, ягъни сөелмәгән, хәерсез, читкә тибәрелгән затка әверелә.

– Гаделлек хисе бик көчле кеше иде ул. Ничек шундый булгандыр – анысын белмим, – ди Анатолий Тихоновичның улы Павел Марченко.

«Мои показания» китабы, аннан соң дөнья күргән бүтән китаплары кебек үк, тәхәллүс белән түгел, ә авторның үз исеме белән басыла. Ә бит хәтта совет диссидентлык хәрәкәтен башлап җибәргән шәхесләр – Юлий Даниэль һәм Андрей Синявский дә фамилияләрен бик «ялтыратырга» яратмаган. «Ә мин псевдоним куям икән, бу нинди күрсәтмәләр, нинди тоткын сүзләре була инде ул?» – дип фикер йөртә Анатолий Марченко. Дөреслекне җиткерү – менә аның төп максаты!

– Гонорар көтәсеңме? – дип сорый аннан иректә чакта ниндидер кичәдә дусты Людмила Алексеева, шаяртып.

– Көтәм, – ди ул күңелсез генә шунда. – Тик сумнарда түгел, ә елларда.

Үз «гонорарын» ул тулысы белән ала – төрмәләрдә, лагерьларда һәм сөргеннәрдә гомеренең 18 елын үткәрә. Соңгы срогы 1981 елның мартында башлана: советка каршы агитация һәм пропаганда өчен аны ун елга иректән мәхрүм итәргә һәм аннары биш елга сөргенгә җибәрергә дигән хөкем чыгарыла. «Әгәр бу дәүләт минем кебек кешеләр белән бергә яшәүнең бердәнбер ысулы – аларны рәшәткә артында тоту, дип саный икән, мин мәңгегә, гомерем ахырына кадәр рәшәткә артында булачакмын дигән сүз. Мин сезнең мәңгелек тоткыныгыз булырмын», – ди ул судтагы соңгы чыгышында.

АЧ ТОТЫП ҺӘМ… КҮРШЕЛӘР БЕЛӘН ҖӘЗАЛАУ

Алла Пугачеваның яңгыравык тавышын һәм аның язмышлар, аерылу-сагышлар турындагы популяр «Паромчы» җырын Чистай төрмәсе ишегалдында ишетергә мөмкин. «Алка»ның җырлавын җинаятьчеләр дә бик сораган – моның өчен төрмәдә махсус радиоузел эшләгән. Тик шундый кешечә мөнәсәбәт янында адәм ышанмаслык явызлыклар да күзәтелә.

…Ике тоткын үз кашыкларының сабын сындырып алып, шуны йотып җибәргән.


1. Фам. МАРЧЕНКО,
2. Имя АНАТОЛИЙ
3. Отчество ТИХОНОВИЧ
4. Родился 23. 01 1938. 5. Место рожд. г. БАРАБИНСК, НОВОСИБИРСКОЙ ОБЛАСТИ.
6. Адрес м/ж Владимирская обл. г. КАРАБАНОВО, ул. Ленина 43, ЖКО № 6
(место работы, должность, специальность) КОЧЕГАР-ОПЕРАТОР КОТЕЛЬНОЙ.
8. Нац. РУССКИЙ 9. Гражд. СССР
10. Арестован 17. 03 1981 г. 11. Характер преступления антисоветская агитация и пропаганда.
12. Ст. ст. УК РСФСР 70 ч 2
13. Карточка составлена Тюрьма № 4 г. Чистополь
(указать название органа)
25. 10 1985 г. Зазнобин
Орган Следственной группой УКГБ по Владимирской обл.
(кем арестован, без сокращений)
№№ дел 372
Сл.
Арх.
Дакто
Форм.
Отпечаток указательного пальца правой руки
По данному факту прокуратурой г. Нижнекамска (спецпрокуратура) 22.12.86 г. возбуждалось уг. дело № 113224 по ст. 103 УК РСФСР. Прекращено 17.02.87 г. по ст. 5 п. 2 УПК РСФСР.

Автор фотосы. Чистай төрмәсе (бүген СИЗО-5) музей почмагыннан

Рәхимсез шартларга түзә алмаудан бу гамәл, чөнки шул рәвешле төрмә сәкесеннән бераз котылып, хастаханәгә эләгү мөмкинлеге бар. Бу хәл Марченко күз алдында, ул җәза срогын уздырган бер төрмәдә була, һәм «Мои показания» китабына да кертелә. Хәер, анда тагын да шаккаткычрак хәлләр дә сурәтләнә. Әйтик, тоткыннарның үз гәүдәләреннән ит кисеп алып, иске газеталардан камерада учак ягулары һәм үз каннарында «аш» пешерүләре турында – надзирательнең аяк тавышларын ишеткәч, алар бу ашны, яна-пешә, тизрәк йотып-ашап бетерергә тырышкан...

Ач тотып җәфалау. «Юк, аның нәрсә икәнен аңлатып булмый. Моны үзе кичермәгән кеше аңламый», – дип яза Марченко. Ул ачлык белән зоналарда да, башка төрмәләрдә дә очраша. Чистайда тоткыннарга йогынты ясауның әлеге ысулы иң камил, иң явыз дәрәҗәгә җиткерелә. «9 б» дип исемләнгән норма – өч кружка кайнаган су белән өч кисәк ипи, берәр төрле кайнар ризык исә көн аралаш кына. Калорияләр саны кеше организмының энергия чыгымнарын хәтта иң аз дәрәҗәдә дә канәгатьләндерми. Авыздан ацетон исе килә, аң бутала – болар ачлыкның кайбер билгеләре генә әле, тоткыннарны шулай ашатканда, алар берничә атнадан соң ук күренә башлый.

«Чистай төрмәсе чын психологик лаборатория иде», – дип бәян кыла танылган диссидент һәм сәяси эшлекле, берничә тапкыр Чистай төрмәсендә утырган Натан Щаранский соңрак елларда. Әйе, ул вакытларда Чистайда сүзнең туры мәгънәсендәге кыйнаулар булмый диярлек. Биредә мыскыллаулар, газаплаулар үткенрәк төс ала. Шуны да искә алып китәргә мөмкин: көчле музыка тавышы, ишегалдына йөрергә чыккач, тоткыннарга сөйләшергә ирек бирми, бу – сәяси блок тоткыннарын тоту өчен бик мөһим шарт була...

Сүз уңаеннан, Чистай төрмәсенең сәяси блогына эләгүчеләр арасында танылган шәхесләр – галим-нейрофизиолог Владимир Буковский, киләчәктә Гарвард хокук мәктәбе профессоры Михаил Казачков, Бөтендөнья психиатрия ассоциациясенең мактаулы әгъзасы, табиб Анатолий Корягин, туксанынчы елларда РФндә Кеше хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил булачак Сергей Ковалев һәм башкалар да бар. Сәяси блокта бер үк вакытта 15–17 тоткыннан артык тотмыйлар, иң күп дигәндә, 19 кеше була ала. Хәер, алар арасында кайберәүләрне «сәяси» тоткын дип түгел, азу ярган җинаятьчеләр, уголовниклар дип атау дөресрәк.

Марченко 25 нче камерага эләгә. Тик Чулман буендагы төрмәдә утырган кыска гына вакыт эчендә аңа әле камераны берничә тапкыр алыштырырга туры киләчәк. Күршеләрне дә. Ә аларны КГБ бик җентекләп, психологик яктан тәңгәл килмәү принцибын күздә тотып сайлап ала.

– Камерадагы киеренке хәл кешене шундый халәткә җиткерергә булыша ки, тоткын бу камерадан теләсә ничек чыгып китәргә омтыла һәм шуның өчен әләкче – стукач булырга да ризалаша, – дип искә алачак соңыннан Натан Щаранский.

Марченконы исә стукачлар белән генә тоталар һәм аның камерасы төрмәдә иң изоляцияләнгәне була, дип яза үзенең «Төрмә хатларында» («Тюремные записки») дусты Сергей Григорьянц.

«БЕЗ ҖИҢДЕК!»

Авызга ике тимер пластина – авыз ачтыргыч куела. Конвоир аның тоткасын әйләндерә һәм борылып килгән винт казналарны ике якка аера. Ачылган тишеккә зонд – зур резин «эчәк» тыгалар. Мускуллар спазмы тоткынны авыртудан калтыранырга мәҗбүр итә, аның һуш-акылы бозыла, күкрәге кысылып куя, һава җитми...

Ачлык игълан иткән тоткынны мәҗбүри ашату нәкъ менә шулай булырга мөмкин. СССР Генераль прокурорына мөрәҗәгатендә Марченко әлеге процедураны «физик йогынты ясауның мәкерле һәм тыелган формасы» дип атый. Ул чарасызлыкның соңгы чигенә җиткәнлектән башлаган тиңсез ачлыгын туктатсын өчен, төрмә җитәкчеләре барысын да эшли. Тукыклы катнашма махсус төрле куелыкта, кисәкле-төерле итеп әзерләнә – ризык кисәкләре шулкадәр эре ки, алар зонд аша узмый, шунда ук тыгылып калалар. Бу очракта аны чистарту башлана – бу эш шлангны ашказаныннан чыгармыйча гына башкарыла. «Соң андый шланг аша, теләк булганда, сыек ризык катнашмасын гына түгел, ә украин чумарларын яки себер пилмәннәрен бернинди тоткарлыксыз үткәрергә мөмкин бит», – дип шаяртырга омтыла Марченко прокурорга хатында. Бу октябрьдә – ачлыкның иң кызган чагында була. Шунысын да искә алу урынлы: ач торуының кырыгынчы көнендә генә аны көчләп ашата башлыйлар.

«Мондый эшкә алыну – иске, тузган көймәдә океан аша чыгарга маташуга тиң», – дип сөйли Натан Щаранский. Марченконың таләбе – Советлар Союзының барлык сәяси тоткыннарын азат итү – фантастик уйдырма кебек яңгырый, ләкин Анатолий искиткеч нык холыклы һәм башбирмәс була.

Тик дуслары кинәт аның ачлыкны туктатуын белеп ала. Бу яңалык Марченконың хаты аша килеп ирешә. Андый хатны тоткынга хатыны – кеше хокукларын яклаучы Лариса Богоразга атап язарга рөхсәт бирелә. Лаеш шулпасын шактый чөмергән тәҗрибәле диссидент тарафыннан сорап язылган азык-төлек исемлеге шактый сәер тоела. Анда сало, горчица һәм шоколад телгә алына. Дуслар бу үтенечне шифрланган юллама дип кабул итә. «Отщепенцы» документаль фильмында алар бу сүзләрнең үзләре өчен «Без җиңдек!» дигән мәгънә белдергәнен аңлатып бирә.

– Шулай килеп чыга ки, тормышның иң нәтиҗәле эш күрсәтердәй өлешен Толя төрмәдә уздыра. Ул үз гомерендә әллә ничә тапкыр ач тора, соңгысы – үзгәртеп



80 нче елларда Чистай төрмәсе.

Автор фотолары. СИЗО-5 музей почмагыннан

кору чорларына туры килә. Аны төрлечә буйсындырырга тырышалар. Ни өчен ул ачлыкны туктаткан? Минем – һәм минем генә дә түгел – нигезле фаразым: Толя «тоткыннар менә-менә азат ителә башлаячак» дигән ышандыргыч хәбәр алган. Ул ачлыкны болай гына туктата торган кеше түгел, – ди Сергей Ковалев.

– Моны төгәл әйтеп булмый, тик шундый фараз бар: эти илдәге вазгыятькә бәя биреп, үз таләбенең хәзер инде үтәлә алуын төшенгән. Һәм, мөгаен, ул хаклы булгандыр, – ди Павел Марченко.

9 декабрьдә сәяси блокның төрмә коридорында кычкырган тавыш яңгырый: «Мин төрмә башлыгыннан Марченконың кайда булуы турында аңлатма бирүен таләп итәм. Берничә көн элек аны хастаханәгә алып киткәннәрен беләм, ә идарә аның кайда икәнлеге хакында берникди дә аңлатма бирми. Мин иртәгә бер көнлек ачлык игълан итәм». Моны Сергей Григорьянц кычкыра. Кайчандыр «яшь социалистлар» яшерен төркеменең актив әгъзасы булган Михаил Ривкин да аның белән бергә ачлык игълан итә. Икенче көнне Ривкин камерасына үзенчәлекле кунак килә – отряд башлыгының тоткыннар янына элек беркайчан да кергәне булмый. Ул сәкегә утырып, тәмәке кабыза, тормыш-көнкүреш турында сорашып ала. «Беләсез инде, Марченко ачлыкны туктатты, өч көн элек аны этап белән Казанга хастаханәгә җибәрделәр. Ул, әлбәттә, бик хәлсезләнгән, әмма коридор буйлап үз аягында үтте, без аны бераз тотыбрак кына бардык. Хәзер ул дәвалана, акрынлап тернәкләнә», – ди ул сүз арасында. Ривкин боларның ялган икәнен иреккә чыккач кына белә: Марченко инде үлгән була.

Әйе, туганнарының, дусларының шатлыгы озакка бармый. Анатолий Тихоновичның организмы чыдый алмый. Ачлыкны туктатып ун көн узарузмас, ул хастаханәдә вафат була. Аның җәсәде дә туганнарына бирелми – Анатолий Марченконы Чистай зиратында җирлиләр.

– Марченко үлеме буенча җинаять эше җиде тапкыр кузгатылды, – дип сөйли тәрбия эшләре буенча төрмә башлыгының элеккеге урынбасары, диссидентларның мемуарларында еш искә алынган Владимир Чурбанов. – 90 нчы елларда Ковалев депутат комиссиясе белән килеп җитте. Махсус табиб-эксперт та алып килгән иде.

– Без Пермь лагерьларында булдык һәм, әлбәттә, Михаил Казачков төрмә җәзасын үтәүне дәвам иткән Чистайга да кагылдык, – дип сөйләде журналыбызга Ковалев. – Ул вакытка әле без «Сәяси репрессия корбаннарын реабилитацияләү турында» законны язарга өлгермәгән идек, әмма, белгәнегезчә, аклаулар инде башланган чак. Без ул чакта Толя Марченко үлеменең чын сәбәпләрен ачыкларга тырыштык.

Автор фотолары. СИЗО-5 музей почмагыннан



СИЗО-5: кайчандыр сәяси блок урнашкан Чистай төрмәсе, аның коридорлары һәм камералары бүгенге көндә.

Әлбәттә, аның үлеме – ачлык нәтиҗәсе иде. Мәҗбүри ашатылуга карамастан, ул бик йончыган, ябыккан була. Йөрәк һәм ашкайнату системасына бәйле җитди авырулар баш калкыта. Шәһәр хастаханәсендә йөрәккә массаж ясарга да туры килә. Ике кабыргасы сыну сәбәбе нәкъ менә шул булгандыр дип уйлыйм, чөнки бик арыклану аркасында сөякләр тиз сынучанга әйләнә. Бу табибларның ахыргы бәяләмәсендә дә теркәлгән. Тик ярдәм квалификациялерәк булса, бәлки, Толя исән дә калыр иде.

Сергей Григорьянц исә Марченконың үлеме очраклы түгел дип саный. «Бөтен дөньяга танылуы аркасында, Толяны беренчеләрдән булып иреккә чыгармыйча ярамый иде. Ә аны азат итү бик куркыныч – коммунистик үзгәртеп коруның рекламаланган башлангыч планнарына Анатолий Марченко һич туры килми. Аның өчен «Хорст Вессель җыры» һәм «Интернационал», Колыма һәм Освенцим, коммунистлар һәм фашистлар арасында аерма юк иде, ә диссидентларның күпчелеге һәм «алтмышынчы еллар зыялылары» шәхес турында кайгырткан, кешелекле коммунизмга омтыла иде бит… Революцион романтикадан Солженицын да, Сахаров та ерак тора, тик аларның берсе дә илгә кайтырга җыенмый, икенчесе – иреккә чыгар алдыннан гына политбюрога хат язып, иҗтимагый эшчәнлектән баш тартырга әзер булуын хәбәр итә. Ә Марченко монда ябуда тотылган, берни дә язмаган һәм КГБ күзлегеннән бик куркыныч саналган», – дип искә ала Григорьянц үз хатирәләрендә («Тюремные записки»). Аның фикеренчә, Марченкога табиб ярдәме күрсәтүдән ачыктан-ачык, җинаятьчел рәвештә баш тартканнар.

Аның үлеме Чистай төрмәсенең сәяси блогы тарихындагы иң җәнҗаллы вакыйгаларның берсе генә булып калмыйча, бөтен Советлар Союзындагы сәяси репрессияләрнең көчле кайтавазы булып яңгырый. Шул ук көннәрдә диярлек бөтен ил буенча сәяси тоткыннарны азат итүнең тәүге дулкыны уза. Аннан соң бер атнадан, 15 декабрьдә, Андрей Сахаровның сөргендәге фатирында телефон куела, ә икенче көнне аңа шылтыраталар да. Чыбыкның икенче очында Горбачев тавышы ишетелә: Сахаровка һәм аның хатыны Боннэрга Мәскәүгә кайтырга рөхсәт бирелә.

«Марченко турында бөтен кеше онытсын өчен, Сахаровны сөргеннән кайтаралар», – әйе, диссидент даирәләрендә мондый фикерләр дә әйтелә. «Бәлки, ирек бусагасындагы бу үлем башкалар өчен азатлыкка юлны җиңеләйткән һәм тизәйткәндер…» – дип яза «Мои показания» китабының илебездә чыккан басмасының кереш мәкаләсендә кайчандыр шундый ук сәяси тоткын булган сәнгать белгече Юрий Герчук. ■

СУ БУЕНДА УЧАК ЯНА…

«Татарстан» журналының бүгенге редакциясе 80 нче еллардан: йә бала чагы, йә яшьлеге шул елларга туры килә. Шуңа күрә «80 нче еллар буыны» проекты сезне балачакка, мәктәп елларына, институт-университетларга чакыра. Тагын әле төзелеш отрядлары, хезмәт лагерьлары, походлар… Бергәләп бәрәңгегә барулар, дискотекаларга йөрүләр, демонстрацияләргә чыгулар. Армия, практика еллары… «Әй, гитара, әй, гитара, нечкә икән кыллары», – дип җырлаулар, таң каршылаулар, беренче мәхәббәт… Боларның барысы да фотопроектыбызда чагылыш тапты…

Фотолар «Татарстан» журналы редакциясендә эшләүчеләрнең гаилә архивыннан алынды

Беренче Май демонстрациясендә.

Галстуклы балачак. 80 нче еллар пионерлары галстуклары белән горурлана иде.



Казан зоопаркында.
1980 ел.

Хезмәт лагеренда
Нептун көне. 1984 ел.

«Электрониклар» Советлар Союзының һәр мәктәбендә бар иде.

Тегү түгәрәгенә кызлар гына йөри дип кем әйтте?
1985 ел.

1984 ел.

Унынчы класс укучылары – яңа уку елына китаплар алгач.
1985 ел.

Калашников автоматын һәр комсомол тизлеккә җыя һәм сүтә ала. 1984 ел.

Казан тренеры Владимир Житлов һәм ул тәрбияләгән фехтование буенча Олимпия чемпионнары һәм призёрлары: Наилә Гыйләҗева, Валентина Никонова, Ольга Князева.

КАМАЗ тулай торагында. 1988 ел.

КДУның журфагында телеүзәк ачылды. 1989 ел.

Бәрәңгегә баруларны көтеп ала идек. 1983 ел.

Карате белән шөгыльләнү – модада. 1984 ел.

Вахтер әбиләр вакытны бушка уздырмый.

«Әй, гитара, әй, гитара, нечкә икән кыллары...»
Казан университеты тулай торагында. 1987 ел.

Борис Гребенщиковның Казандагы чыгышы.

Казан, 9 Май. Бөек Җиңүнең 40 еллыгы.

80 нче елларда журналистларны беренче тапкыр «ябык» саналган вертолёт заводына керттеләр.

Театрның яңа бинасын ачу тантанасы. Р. Мотыйгуллина, Ш. Биктимеров, А. Гайнуллина. 1986 ел.

КАБАН КҮЛЕНДӘГЕ СӘХНӘ

Тышкы яктан караганда, ул балкон-палубалары һәм витражлы тәрәзәләре булган зур затлы корабны хәтерләтә, пыялалары аша иркен мәрмәр фойе буйлап атлап йөрүче кешеләр күренеп тора. Эчендә барысы да – су һәм җил тематикасында, хәтта тамашачылар залындагы лоджиялар биек ярларга туктаган көймәләр кебек эшләнгән. Әлеге зур кораб-бина Кабан ярына 1986 елда урнаша, әйтерсең лә ул туп-туры Камал театры режиссеры Марсель Сәлимҗановның хыялларыннан йөзеп килә.

Автор:
Олеся Бондаревская

Корабның нәкъ менә шушы урында торуы турында риваять бар. Бервакыт Габдулла Кариев «Болгар» кунакханәсенә Тукай янына кунакка килә. Алар балконга чыгалар, һәм Кариев, күлнең ярына таба күрсәтеп, болай ди:

– Безнең театр биредә ачылса, ничек яхшы булыр иде!

Бинаны төзү эшләре исә алты дистә елдан соң гына башлана. Республиканың төп сәхнәсе өчен моннан да яхшырак урынны бүген – бигрәк тә бүгентабып булмас иде. Иске Татар бистәсе, аның тарихи һәм рухи үзәге булган Мәрҗани мәчете, «Печән базары» территориясе, тормыш кайнап торган Татарстан урамы, төбендә хәзинәләр ятуы турында риваятьләр йөргән Кабан күле, Меңьеллык паркы, «Тукай» метро станциясе, Казан зооботаника бакчасы, үзәк базар – болар әйләсендәге театр, әйтерсең, тарих, хәзерге заман һәм киләчәкнең кисешкән урыны булып тора.

– Безнең адрес – Татарстан урамы, 1нче йорт. Без монда «роза ветров» үзәгендә кебек, – ди Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев. – Төрле билгеләр, метафоралар эзли китсәң, бик күп табылыр.

Фотолар Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры архивыннан алынды

КАМАЛ ТЕАТРЫ «МАРСЕЛЬЕЗА»СЫ

Горький урамы, 13нче йорт адресы буенча урнашкан бина (хәзер биредә – К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры) XX гасыр башыннан алып камаллылар өчен туган йорт була. ТАССРның халык артистлары, актерлар Хәким Сәлимҗанов һәм Галия Нигъмәтуллинаның улы Марсель Сәлимҗановның балачагы узган янкорма (флигель) нәкъ менә шунда урнашкан инде. Чын мәгънәсендә сәхнәдә үскән Марсель дә, нәтиҗәдә, әти-әнисе юлыннан китә. ГИТИСны тәмамлап, Казанга кайта һәм 1966 елда туган театрын җитәкли. Пассионарий, экспериментатор һәм шул ук вакытта милли татар мәдәнияте өчен янып йөрүче Сәлимҗанов труппасын һәрвакыт алга алып бара. Һәм, күпмедер вакыттан соң, театрга үз бишегендә кысан була башлый, аңа зуррак урын, күбрәк мөмкинлекләр, күбрәк тамашачылар кирәк була.

Яңа бинага беренче нигез ташы 1972 елда салына. Проект зур күләмле була, шактый финанслау таләп итә. Илдәге икътисадый вазгыять яхшыруга таба бармый, һәм мондыйрак проектлар, гадәттә, озак вакытка сузыла. Әмма үз театрының мәнфәгатьләрен Сәлимҗанов кебек төрле дәрәҗәләрдә яклый белгән кеше булмаган, диләр. Бернигә дә карамастан, яңа бина төзелеше 1986 елда тәмамлана. Бу – юбилей елы була, татар телендәге беренче спектакльнең сәхнәгә чыгуына, ягъни татар театры оешуга 80 ел тула.



«Ахырзаман» спектакле репетициясендә.

АНЫҢ ИЗГЕ УРЫННАРЫ

1987 елда актер һәм Камал труппасының яшь режиссеры Фәрит Бикчәнтәев армиядән ялга кайта һәм шунда ук яңа бинаны карарга килә. Балконга менеп, бөтен труппа катнашында узучы «Зәңгәр шәл» спектакленең репетициясен күзәтә.

– Марсель Хәмитович мине аска чакырып төшерде һәм сәгать ярымга якын бинаны күрсәтеп йөрде. Бизәнү һәм эш бүлмәләренә алып керде, күн кәнәфиләрне һәм диварларны тоттырып карады, бөтен нечкәлекләренә кадәр сөйләп бирде, – дип искә ала Фәрит Бикчәнтәев. – Ниһаять, ул мине өченче катка алып менде һәм: «Ә хәзер мин сиңа бу бинадагы иң яраткан урынымны күрсәтәм», – диде. Без аның кабинетына ишекне ачып кердек – һәм мин хушсыз калдым. Бик иркен бүлмә, уртада зур түгәрәк өстәл, мөгаен, король Артурның рыцарьлары гына мондый өстәл артында утыргандыр. Өстәл өстендә аның иске кабинетыннан кителгән зур люстра эленеп тора. Марсель Хәмитович әйтә: «Мин Ульяновның Вахтангов театрында, Ефремовның МХАТында булдым. Ләкин бары тик минем генә шундый кабинетым бар...»

Иске бинадан яңа бинага күчкәндә идән тактасын алып китәләр. 1987 елның гыйнвары.

ШӘЛ НӘРСӘ ЯШЕРӘ?

Яңа сәхнәдә куярга премьера итеп Сәлимҗанов Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ен сайлый. Аның бу пьесаны 1970 нче елларда куйганы була, әмма яңа театрның тамашачылар өчен үз ишекләрен ачуы уңаеннан, спектакльнең 1987 нче елгы версиясе әзерләнә. Төп рольгә татар опера театры солисты Венера Ганиеваны чакыралар. «Һәр театрның үз тарихы белән бәйле спектакльләре бар. МХАТның – «Чайка», Вахтангов театрының – «Турандот». Ә безне, гастрольләрдә: «О, «Зәңгәр шәл» килде!», дип каршы алалар»,– дип сөйләде ул вакытта журналистларга режиссер.

«Зәңгәр шәл» – авылның беренче чибәре Мәйсәрә тарихы, аны мәҗбүриләп карт һәм комсыз ишанга бишенче хатын итеп бирмәкчеләр. Вакыйгалар кызган вакытта авылга аның сөеклесе Булат кайтып төшә. Мәхәббәт билгесе итеп ул кызга ефәк зәңгәр шәл бүләк итә, ә аннары сөеклесен яклап сугышкан вакытта Җиһаншаны үтерә. Булат урманга качарга мәҗбүр була, анда да үзе кебек үк качкыннарны оч-


«Ахырзаман» спектакле. Рольләрдә: Ә.Хисмәт, В.Шакирова.

рата. Алар бергәләп ишан йортыннан Мәйсәрәне коткару планын кора.

«Мин бу пьесаны яттан беләм, ләкин аны кабат-кабат карыйм», – ди спектакль репетициясендә драматург Туфан Миңнуллин. «Зәңгәр шәл»нең кайсы ягы белән үзенә тартып торуын аңлатып бетереп булмый – һәркем өчен аңлаешлы юмормы, Салих Сәйдәшевнең искиткеч музыкасымы (сүз уңаеннан, спектакльнең музыкаль фразасы бүгенге көндә театрда чакыру итеп кулланыла), күпкатлы метафораларамы яки милли тарихи вакыйгаларга кагылышлы яшерен сылтамаларамы.

«Син дә, Фәрит, минем сүзләремне исеңдә тот, син дә аны куярсың!» – дигән бервакыт Сәлимҗанов Бикчәнтаевка. Һәм ул хаклы булып чыга: озакламый үзенең 95 яшен билгеләп үтәчәк «Зәңгәр шәл» бүген дә камаллылар сәхнәсеннән төшми. Спектакль әле дә аншлаг җыя.

«АХЫРЗАМАН»НАН КУРЫКМАГАННАР

Зур сәхнә, искиткеч акустика (аны театрның рәсми ачылышында чыгыш ясаганда Илһам Шакиров үзе югары бәяләгән), техник мөмкинлекләр, тамашачыны яңача утырту – болар барысы да репертуарны принципиаль яктан яңадан карауны таләп итә. Һәм театр ва-банк ясый: 1987 елда татар режиссурасының «дуамал шайтан»ы Дамир Сираҗиев Чыңгыз Айтматовның «Ахырзаман» әсәрен сәхнәләштерергә алына. Айтматов үзе әсәрне куярга рөхсәт биреп телеграмма җибәрде, дип хәбәр итә ул труппага.

Сираҗиев әлеге кыю, катлаулы, үз заманының проблемаларын һәм кимчелекләрен ачып бирүче әсәрне сәхнәгә драматург Мансур Гыйләҗев белән бергә күчерә. Куелышта катнашучылар фикер алышып, тамашачыга нәрсә күрсәтергә кирәклеген хәл итә. Сценография белән рәссам Сергей Скоморохов шөгыльләнә. Бүре сукмаклары салынган кыяларны гәүдәләндерүче күчмә декорацияләр Акбүре белән Ташчәйнәрне тамашачыга әле якынайта, әле ерагайта, төп геройларның аягы астында чайкалучы кыр, куркыныч хәрәкәтләнүче пәрдәләр – болар һәм башка күптөрле чаралар тамашачыны бүреләр һәм кешеләр, намус һәм комсызлык, җәмгыять һәм кеше арасындагы каршылыкның фаҗигале тарихы атмосферасына чумдыра. Театр тарихында беренче тапкыр сәхнәгә гитаралар һәм синтезатор белән рок-ансамбль чыга, интрументлар куелыш өчен махсус сатып ала.

«Ахырзаман» тулы залларда уза, спектакльне башка шәһәрләргә гастрольләргә алып баралар, аны кызып-кызып сүгәләр һәм шулкадәр үк дәрәҗәдә мактыйлар да. Спектакль тирәсендәге шау-шу – узып баручы чорның шартлап сынуы, бу вакыйганы камаллылар үз куелышлары белән мәңгегә теркәп куялар. «Ахырзаман» видеога төшерелә. Бу язманы, башка архив спектакльләренең язмалары кебек үк, театрның ютуб-каналында карарга мөмкин.

СӘХНӘ АРТЫ ТӨРЛЕЛЕГЕ

Бүгенге театр бинасы – 1970 нче еллар авангардына хас интерьер, ягъни чех витражлары һәм ГДР люстрлары, өч бар һәм холлдагы фонтан. Тамашачылар өчен бу – әкият дөньясы. Дөрес, тамашачыны әсир итәрлек бина труппаның үзе һәм театр хезмәткәрләре өчен бик уңайсыз булып чыга. Декорацияләрне саклау һәм цехлар өчен бүлмәләр булмау, көндезге яктылык җитмәгән кечкенә гримеркалар, 1000 кешегә исәпләнмәгән парковка (зур һәм кече заллар шулкадәр тамашачыны сыйдыра), гастроль спектакле белән фураны бушату өчен Татарстан урамындагы хәрәкәтне туктатып тору – күп еллар дәвамында камаллыларга

Камал театры труппасы. 1988 ел.

шушы һәм башка кыенлыкларны җиңеп эшләргә туры килә. Алар түземсезлек белән реконструкцияне көтә, ул инфраструктура проблемаларының бер өлешен генә булса да хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Тик болар барысы да театр серләрен саклый торган сәхнә артына карый. Сүз уңаеннан, алар арасында берничә реликвия дә бар. Шул исәптән – ике көзге. Берсен театрга Галия Нигъмәтуллина бүләк иткән. Ул сәхнә артында тора һәм аңа һәркем тамашачы алдына чыгар алдыннан карый. Икенче көзге – бинаның хезмәткәрләр өлешендә, бизәнү бүлмәсе янында урнашкан. Кайчандыр ул «Сәйяр» труппасының тәүге актрисаларының берсе Фатыйма Ильскаяныкы булган.

Сәхнәнең тамашачылар өчен күренми торган тагын бер урынында Горький урамы, 13 йорттагы сәхнәдән китерелгән берничә идән тактасы бар, аны бирегә Марсель Сәлимҗанов белән Фәрит Бикчәнтәев сүтеп алып кайта. Театр корабы бүген дә киләчәккә таба йөзүен дәвам итә. Тарихы ышанычлы итеп йөрәгенең нәкъ түренә яшерелгән.

ТЕАТР ТӨЗЕГӘНДӘ КРАННЫ ОНЫТЫП КАЛДЫРГАННАРМЫ?

Интернетта театрның төзелеш эшләре баручы түбәсеннән кран күренеп торган фоторәсем бар. Версияләрнең берсе буенча, төзүчеләр машинага чыгу юлы калдырырга оныткан, түбәне җәеп бетергән вакытка кран эчтә торып кала. Янәсе, кранны вертолетлар белән күтәреп чыгарырга туры килгән. Бина төзелешендә участок җитәкчесе булган Расих Фәйзрахманов сүзләренчә, чынлыкта, фотодагы кранның конструкциясе җыелма булган һәм түбәне җәеп бетергәч, аны сүтеп кенә алганнар.

Фото: vk.com/kazancatru

ЧЫН ОСТАЛАР ЯЗГАН ТАРИХ

Безнең «80 нче еллар буыны» проекты укучыларга 1980 нче елларда оешкан һәм бүген дә актив эшләп килгән Татарстан компанияләре, учреждениеләре һәм предприятиеләре турында сөйли. Шундыйларның берсе – «ТРның төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» ДАУ, ул проектлау, төзелеш һәм эксплуатация стадияләрендә биналарның һәм корылмаларның ышанычлылыгын, куркынычсызлыгын тәэмин итү эшендә үзенә йөкләнгән төп миссияне 30 елдан артык нәтиҗәле башкара.

Мәҗит Салихов, «ТР ДЭБИ» ДАУ җитәкчесе

Татарстан лаеклы рәвештә илебезнең төзелеш өлкәсендәге алдынгы төбәкләреннән берсе дип санала – биредә югары темплар белән бик күп яңа торак төзелә, функциональ заманча инфраструктура объектлары булдырыла, сыйфатлы һәм ышанычлы юллар салына, республикада җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү белән дә актив шөгыльләнәләр. Куркынычсыз һәм сыйфатлы торак-биналар салу – шәһәр төзелеше сәясәтенең беренчел максаты булып тора һәм ТРның инвесторларны җәлеп итүчәнлегендә мөһим роль уйный.

ТАРИХИ КАРАР

Инвестиция-төзелеш юнәлешендә эш йөртә торган оешмаларның берсе – Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе. Аның тарихы 1988 елда башлана, ул вакытта мөстәкыйль статустагы «Ведомстводан тыш дәүләт экспертиза идарәсе» дәүләт учреждениесе гамәлгә куела.

Тәүге елда оешма тарафыннан гомуми бәясе 280 млн сумнан артык булган 68 проект тикшерелә, әлеге проектлар предприятиеләр, биналар һәм корылмалар төзү һәм реконструкцияләү белән бәйле була. Ул вакытта идарәдә нибары 10 кеше эшли. Сүз уңаеннан, 80 нче елларда «Дәүләт экспертиза идарәсе» белгечләре тарафыннан Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры проекты раслана. Хәзерге вакытта ул иң популяр милли театр, шәһәр халкының ял итү урыны һәм Казанның визит карточкасы булып тора. Шулай ук оешманың башлангыч чорындагы иң мөһим объектлар арасында Чаллыдагы «Ока» кече литражлы автомобильләр заводы проектын, Саескан тавы янындагы Чулман аша күперне, Казанда һәм республиканың башка шәһәрләрендә кибетләре, мәктәпләре, балалар бакчалары, шулай ук юллары һәм коммуникацияләре алдан планлаштырылган яңа микрорайоннар проектларын билгеләп үтү урынлы.

Татарстан ССР төзелгәч, Дәүләт экспертизасы идарәсенең эшчәнлеге үзгәрә башлый. Смета бәясенә бәйсез рәвештә төзелеш объектлары экспертизага җибәрелә, ә элек бәясе 4 млн сумга кадәр булган объектлар гына тикшерелгән була. Бу вакытта экспертиза аша күпсанлы сәнәгать һәм төзелеш комплекслары проектлары, коммуналь хуҗалык һәм юл төзелеше өлкәсендәге проектлар уза. Алар арасында – «Татэнергострой» дәүләт төзелеш-җитештерү берләшмәсенең кирпеч заводы, Түбән Камада Агач эшкәртү комбинаты, Казан ТЭЦ-1 станциясен яңадан үзгәртеп кору, Урыссу ГРЭСын реконструкцияләү һәм башка проектлар бар.

ЯҢА ЗАМАН

Еллар уза, учреждение дә актив үсә – 2001 елда Яшел Үзән, Яр Чаллы, Бөгелмә шәһәрләрендә (2018 елдан – Әлмәттә) зона бүлекләре оештырыла. 2015 елның февралендә, икътисадый идарә эшенең алымнарын камилләштерү, ТР төзелеш тармагын үстерү максатыннан, «ТР төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» Дәүләт автоном учреждениесе төзелә, ул ике учреждениене берләштерә – Татарстан ведомстводан тыш экспертиза идарәсе һәм Республика инженер-техник үзәге бер оешмага әйләнә. Учреждениенең яңа үсеш этабын зирәк җитәкче, тәҗрибәле профессионал – Мәҗит Салихов исеме белән бәйлиләр. Хәзер «ТР ДЭБИ» ДАУ ел саен гомуми бәясе 194 млрд сумнан артык булган 5 меңнән артык объектны тикшерә. Экспертиза идарәсе 2013 елда Казанда узган Бөтендөнья җәйге Универсиаданың, 2018 елгы футбол буенча FIFA дөнья чемпионатының, «Worldskills» стандартлары буенча һөнәри осталык дөнья чемпионатының әһәмиятле объектларына тикшерү уткәрә. Мәҗит Салиховның эше лаеклы дип бәяләнде һәм иң югары дәрәҗәдә билгеләп үтелде, моны күпсанлы бүләкләр һәм мактау хатлары раслый.

РЕСПУБЛИКА ГОРУРЛЫГЫ

ТАССР Министрлар Советы бүлегенең экспертиза бюросыннан алып хәзерге дәүләт учреждениесенә кадәр үтелгән озын юл данлы хатирәләр генә түгел, саллы нәтиҗәләр белән дә тарихка керә. «ТР ДЭБИ» ДАУ хезмәткәрләре эше нәтиҗәсендә республиканың йөзе матурланды, чөнки учреждение күп кенә федераль һәм республика программалары буенча бихисап эш башкара, ә бу – төзелгән һәм төзекләндерелгән меңнәрчә объектлар, торак йортлар, мәктәпләр, балалар бакчалары, технопарклар, иҗтимагый, мәдәни, көнкүреш, спорт, сәламәтлек саклау, мәдәни мирас объектлары, парклар һәм скверлар дигән

Фото «ТР ДЭБИ» ДАУ тарафыннан тәкъдим ителде

Реклама

Галиәсгар Камал исемендәге театр бинасы төзелеше өчен мәйданчык.

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры бүгенге көндә.

сүз. Хәзерге вакытта Татарстанның төзелеш комплексын проектларга сыйфатлы экспертиза ясау идарәсеннән башка күз алдына да китереп булмый. Бүген «ТР ДЭБИ» ДАУ – Идел буе федераль округында иң эре эксперт үзәкләренең берсе, ул дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган экспертиза ясау, проект документациясен һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләрен тикшерү, төзелештә бәячыгымнарны билгеләү, тарификация һәм ТКХ өлкәсендә экспертиза юнәлешендә киң спектрлы хезмәт күрсәтә. Учреждение инновацияләрне актив рәвештә кулланышка кертә, мәсәлән, электрон дәүләт хезмәтләре аша эш итү, мәгълүмати модельләштерү технологияләрен кулланып экспертиза үткәрү – шундыйлардан. 2016 елда, төзелеш һәм ТКХ тармагы өчен кадрлар әзерләү максатыннан, учреждение үзенең «Профстандарт» уку-укыту үзәген ачты, анда тармак семинарлары һәм курслары уза, «ТРның иң яхшы сметачысы» һөнәри осталык конкурслары оештырыла.

– Безнең ерак 80 нче елларда оешкан коллективыбыз күркәм традицияләрне һәм тупланган тәҗрибәне саклап, бүгенге көннәргә кадәр китереп җиткерә алды. Бу вакыт эчендә учреждение, республика төзелеш тармагының сыйфат брендына әверелеп, үзенең абруен исбатлады. Уникаль кадрларга, үз эшенең чын осталарына ия булып, ныклы матди-техник базага таянып, без республика һәм ил җитәкчелеге куйган бурычларны уңышлы хәл итеп киләбез, – дип сөйли Мәҗит Хаҗипович. – Бүгенге көндә ТР дәүләт экспертизасының бәяләмәсе проектлаштыру этабында булачак объектның сыйфатын һәм куркынычсызлыгын раслау булып тора. Бу татарстанлыларның тормышын һәм сәламәтлеген саклауны да аңлата.

КЕШЕ – ТӨП БАЙЛЫК

Заманча торак комплексмы ул, матур спорт объектымы, бик шәп уңайлы паркмы, әллә дәрәҗәле мәктәпме – һәр объектка учреждение белгечләренең зур хезмәте салынган, дип ышаныч белән әйтергә мөмкин. Мондый зур күләмле эшне чын профессионаллар командасы гына башкарып чыга ала: учреждениедә 140 тан артык белгеч эшли, шул исәптән махсус аттестацияләнгән 50 гә якын эксперт бар, күбесенең һөнәри эшчәнлек стажы 25 елдан артып китә. Хезмәткәрләр арасында тырышлыклары, фидакарь хезмәтләре өчен медальләр, «Төзелеш даны» мактаулы билгесе белән бүләкләнгән атказанган һәм мактаулы төзүчеләр, архитекторлар, энергетиклар, табиблар, гыйльми дәрәҗәгә ия белгечләрне күрә алабыз. Аларны лаеклы рәвештә ТР төзелеш комплексының «интеллектуаль элитасы» дип атыйлар.

ИЗГЕ ГАМӘЛЛӘР

Учреждение зур иҗтимагый эш белән дә шөгыльләнә һәм тарихи мирас объектларын реконструкцияләүгә, Изге Болгар һәм Зөя утрау-шәһәрен торгызуга, бик авыр хәлдәге хасталар өчен терапия җәмгыятьләре төзүгә, авылларда мәдәни-агарту комплекслары төзүгә, спорт командаларына һәм иҗтимагый чаралар оештыруга даими ярдәм итә. Учреждение җитәкчесе Мәҗит Салихов республика активы вәкилләреннән санала, төрле объектлар төзү һәм мөһим чаралар үткәрү эшендә Балтач районына һәрьяклы ярдәм күрсәтә. Әлеге хәйрия ярдәме Балтач районында малайлар өчен пансионат төзергә, ел саен мөселман балалар Сабантуе үткәрергә, балаларны мәктәпкә әзерләргә, дини учреждениеләрнең эшен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Учреждение хезмәткәрләре актив тормыш тарафдары булу һәм сәламәт яшәү рәвеше белән аерылып тора – Дәүләт экспертизасы идарәсендә мини-футбол һәм волейбол буенча ике команда бар.

30 ел эчендә күп нәрсәләр башкарылды, тик бу әле эшләрнең башы гына. Алда республика иминлеге хакына яңа проектлар көтә.

ГАУ «УГЭЦ РТ»

1980 нче еллар

ВИДЕО, ВИДЕО – БИК ТАНСЫК ТАМАША...

Автор: Дамир Үтәмешев

Узган гасырның 80 нче елларында СССР телевидениесендә күңел ачу-танып белү тапшырулары күп булып, аларның барысының да башлану вакыты программада төгәл күрсәтелә һәм һәркем, шуңа кадәр бөтен эшен бетереп, телевизор каршында урын алып калырга ашыга иде: «Вокруг смеха», «Кабачок 13 стульев», КВН, «А ну-ка, девушки!»...

Совет халкы фәнни-популяр программаларны да үз итә. «Клуб путешественников», «В мире животных» һәм «Очевидное-невероятное» телевизор экраннары янына бөтен гаиләне җыя. Популяр чит ил һәм совет музыкасы белән хозурланыр өчен, бөтен кеше һәр атна саен якшәмбедә «Утренняя почта» тапшыруын көтеп ала. Ел саен Яңа ел алдыннан «Песня года» һәм «Голубой огонек» тапшыруларына зарыгып торалар. Балалар «Будильник», «В гостях у сказки», «АБВГДейка» кебек игелекле программалар йогынтысында тәрбияләнә, «Спокойной ночи, малыши» тапшыруы һәркемнең күңеленә бик якын җыры белән үтеп кереп йоклата.

Ә менә нәфис фильмнарны халык туйганчы карый алмый. Бик күбесе «киштәдә ята» – аларны эфирга цензура чыгармый. Күрсәтелә торганнарыннан Гайдайның мәңге искермәс комедияләре, «Тегеран-33», «Огарёва-6» кебек кырыс хәрби фильмнар, «Одиноким предоставляется общежитие», «Вокзал для двоих» кебек мәхәббәт турындагы драма һәм мелодрамалар уңыш казана... 80 нче елларны сагынучылар әлеге фильмнарны бүген дә ярата. Әмма алар «тимер пәрдә» артында яшәгән чорда чит илдә төшерелгән шәп фильмнарны бик тансыклый. Киноны күбрәк һәм ешрак карыйсылары килә! Һәм нәкъ менә шул чакта тамаша тансыклаган совет халкы өчен рәхәт заман башлана – видеосалоннар ачыла. СССРда туучыларга Голливудта төшерелгән шәп фильмнарны карау мөмкинлеге тудырыла.

Шул данлыклы видеозаман хакында хатирәләре белән эшкуар, 80 нче елларда видеосалон хуҗасы булган Константин Небрежный уртаклаша.

I НЧЕ ТАРИХ. ЯПОН ВИДЕОМАГНИТОФОНЫН БЕР БҮЛМӘЛЕ ФАТИРГА АЛЫШТЫРЫП БУЛА ИДЕ

– Видеосалон ачу идеясе дустым белән минем башта очраклы рәвештә туды. Бу 80 нче еллар уртасы иде. Дустым Александр – «Аэрофлот» пилоты. Бервакыт Япониягә очкач, ул аннан Panasonic NV 2000 видеомагнитофонын алып кайтты. Бу бик кыйммәтле, дәрәҗәле әйбер иде.

Союзда да видеомагнитофоннар җитештерелә, нигездә бу «Электроника ВМ-12» иде. Әмма алар бик еш кына пленканы «чәйни», япон техникасы исә Швейцария сәгате кебек төгәл, ышанычлы, сыйфатлы! Ул елларда япон видеомагнитофонын арзанлы машинага, хәтта бер бүлмәле фатирга ук алыштырырга мөмкин: «Электроника» видеомагнитофоны – 1200 сум, Panasonic – 2000 сум тирәсе, фатир исә 3000 сум чамасы тора иде.

– Алыштыру теләге тумадымы?

– Чит илдән алып кайткан шундый кыйммәтле әйберне без берниндн машинага яки фатирга да алыштырмас идек. Видеомагнитофонлы булу – искиткеч дәрәҗә! Ул чакта бөтен нәрсәгә кытлык иде бит, башкасы турында әйтәсе дә юк, хәтта ашамлык та табып булмый иде. Кирәкле кешеләрне белергә, кемнедер «майларга», атналар буе көтәргә кирәк... Нәкъ менә шуңа күрә дә япон видеомагнитофонын шундый кыйбатлы әйберләргә алыштырып була иде.

– Яки видеосалон ачарга ниятләдегез?

– Без үзебезнең видеосалонны тулай тораклың Актлар залында ачтык. Бик зур булмаган бүлмәдә өч-дүрт рәт урындык тезелгән, түрдә тумбочкада телевизор тора, шуңа видеомагнитофон тоташтырыла. Беренче көнебезне яхшы хәтерлим – планлаштырылган тамашачыларның яртысы гына килде. Ә инде икенче көнне бөтен теләүчеләр өчен урындыклар да җитмәде.

– Сезнең кинотеатрга билет ничә сум тора иде соң?

– Бер сум! Бүгенгедәй хәтерлим. Мөгаен, башкалар да хәтерлидер. Чөнки бу онытылмас еллар иде. Көненә без өч-дүрт фильм әйләндердек. Сеанс саен 20–25 кеше, һәркайсыннан 1 сум – көненә уртача 80 сум чамасы җыйнала иде. Чагыштыру өчен – бер килограмм шикәр дә 1 сум тора. Нәкъ менә шуңа күрә без үзара сөйләшкәндә клиентларыбызны «шикәрле» дип йөрттек тә.

– Нинди фильмнар күрсәтә идегез?

– Хәзерге кебек зур сайлау мөмкинлеге юк иде әле ул чакта. Әмма булган фильмнар да җитеп торды. Киносеанслар репертуар буенча үткәрелде. Көндез – мультфильмнар, нигездә Дисней мультикларын күрсәттек. Кичен исә «Рембо: Первая кровь», «Хон Гиль Дон», «Терминатор», «Кошмар на улице Вязов» кебек боевиклар һәм куркыныч

Фото: Дамир Үтәмешев



фильмнар әйләндердек. Тәрҗемә шундый начар – тыңкыш тавышлы иде...

– Өлкәннәргә генә тәгаенләнгән фильмнарны да күрсәттегезме?

– Әйе, әлбәттә. «Эммануэль», «Греческая смоковница», «Табу 3». Бу – махсус жанр, алар аншлаг белән бара иде. Әмма әлеге ленталарны кичке сәгать тугыздан соң гына һәм 18+ публикасына гына күрсәттек.

– Салым органнары? Милиция? ОБХСС? КГБ? Янгын сүндерүчеләр? Сезнең салонны нинди дә булса «җәза бирү» органнары тикшерә идеме? Ул легаль булмаган бит...

– «Красный рассвет» фильмын күрсәткәндә булды иң хәтердә калган очрак. Бу бит чын «антисоветчина» инде. Аны күрсәткән өчен төрмәгә утыртулары да мөмкин. Гомумән, 80 нче елларның беренче яртысында хосусый видеокараулар закон буенча эзәрлекләнде. Шунлыктан әлеге фильмга участковый килеп кергәч, без тиз арада берәр чара күрергә җыендык, ул исә гаиләсе белән кино карарга гына килгән икән. Ул да кеше бит, аның да үзенә һәм якыннарына нинди дә булса игелек кыласы килгәндер. Менә хәзер ОБХСС хезмәткәрләре килеп керер инде, дип курка-курка күрсәттек без ул көнне киноны. Әмма барысы да тыныч үтте. Ул көнне дә, башка көннәрдә дә.

– Мөгаен, сезнең «түбәгез» булгандыр?

– Әйе, әлбәттә. Бер коммерсант та яклаучысыз эшли алмый иде ул чакта. Югыйсә, без видеомагнитофоннан да, телевизордан да, тотрыклы керемнән дә колак кагар идек.

– Аларның «хезмәте» өчен күпме түләргә кирәк иде соң?

– Керем-төшемнең 30%ын, тагын аларның үзләре һәм әшнәләре өчен бушлай сеанслар. Шуңа күрә без тынычлап эшли алдык.

– Ничек тукталды бу эшчәнлегегез?

– Ничектер үзеннән-үзе килеп чыкты шулай... Без күрсәткән фильмнарны бушлай күрсәтә торган федераль каналлар пәйда булды, инде видеомагнитофон да һәркемнең диярлек үзенеке бар иде. Шунлыктан без, беренчеләрдән булып, видеокассета прокаты салоны ачтык. Әмма, Леонид Семёнович Каневский әйтергә яратканча, монысы инде – бөтенләй башка тарих.

Икенче тарихны исә 80 нче елларда Казан университетында укыган Алинә Заһидуллина сөйләде.

2 НЧЕ ТАРИХ. ИТАЛИЯДӘ МОНДЫЙ ВИДЕОАППАРАТУРА ГОМЕРДӘ ДӘ БУЛМАГАН!

– Безнең төркемдә ике дус кыз – Лена белән Марина укый иде. Фамилияләрен әйтмим, язманы укысалар, үпкәләүләре бар... Алар бер сыйныфта укыганнар һәм инде мәктәп елларыннан бирле берберсен уздырырга тырышып яшиләр иде. Ата-аналары шактый бай, яраткан кызлары өчен акча кызганмыйлар, һәм безгә, тулай торакта яшәүчеләргә, аларның яңа әйберләренә, модалы киемнәренә кызыгырга гына кала иде... Көнләшерлек нәрсәләр күп! Әгәр Лена нинди дә булса суперваренка киеп килсә, икенче көнне үк Марина баштанаяк модалы джинсыдан килә. Әгәр Марина тәмәке тарткан вакытта: «Әй кызлар, бүген төшемдә әтием миңа «юеш асфальт» төсендәге «девятка» бүләк итте», – дип сөйләнсә, иң күп дигәндә, бер атнадан Лена чия төсендәге өр-яңа «девяткага» утырып килеп җитә. Ул чакта университет янында машиналар бөтенләй юк иде! Моны күз алдыгызга китерә аласызмы?! Хәзер инде мин дә күз алдыма китерә алмыйм. 80 нче еллар азагында исә анда ике данә машина бар иде: берсе – ниндидер профессорныкы, икенчесе – Ленаныкы!

Икенче курста ике кыз да кияүгә чыкты. Марина ниндидер Сызрань миллионерына, Лена исә... Италиядә үзенең кунакханәләр челтәре булган италия кешесенә.

Кем текәрәк – совет миллионерымы, әллә италияле магнатмы? Ул чакта миллионерларны әллә ни мөһим кешегә санаучы юк иде – совет дәүләтендә каян килсен алар? Ул чакта бөтен кеше чит илгә китү турында хыялланганга, Марина үзенең дус кызыннан күбрәк көнләшүләрен сизә. Ниһаять, ул аннан уздырганмыни? Моны кичекмәстән ачыклар өчен, икесе дә читтән торып укуга күчкән кызлар кунакка җыена: берсе – Италиягә, икенчесе – Сызраньга.

Кышкы сессия вакытында Казан университетының икенче бинасында 13 нче катта Марина безгә тәмләп менә нәрсә сөйләде:

– Бардым мин ул Италиягә, бернинди кызыгырлык нәрсәләре дә юк... Лена исә, бездәге видеоаппаратураны күргәч, аңын җуеп егыла язды: бөтенесе шундый ачык күрсәтә, тавышы шундый чиста, барысы да бик кыйммәтле! Аларның Италияләрендә гомердә дә шундый видеоаппаратура буласы юк! Иреннән шундыйны даулый башлады, тик ул кайдан алсын аны? Аның «видик» алырлык акчасы да юк әле!

Без баш селкеп тордык. Ышанасызмы-юкмы, тик ул чакта видеомагнитофон – бик кәттә әйбер иде. Һичшиксез, Италиядән дә кәттәрәк!

«80 нче еллар дискотекасына» нигез салучы, шоумен, продюсер Валерий Колоколов 2013 елда бакыйлыкка күчте. «Татарстан» журналының 90 еллыгын билгеләп үткәндә ул безгә үзгәртеп кору чоры Казаны һәм андагы яшьләр тормышы, Татарстанда клублар барлыкка килү тарихын сөйләгән иде.

«ТАТАРСТАН» АРХИВЫННАН

«80 НЧЕ ЕЛЛАР ДИСКОТЕКАСЫ» – 90 ЕЛЛАРДАН

«Бүген кеше авыр ритмнардан арыды, ул 80 нче еллардагы романтиканы һәм җырларны кире кайтарырга тели», – ди шоумен, продюсер һәм «Дискотека-80» гә нигез салучы Валерий Колоколов.

Текст:
Алинә Миңнебаева

– Казанда 80 нче еллар дискотекасы ничек башланды?

– Ул ике тапкыр башланды. Беренче мәртәбә 80 нче елларда – «Бони Эм», «Чингисхан», «Оттаван» һәм итальяннар «тимер пәрдәләр» аша СССРга үтеп кергәндә. 90 нчы елларда халык яңа музыка – драм-энд-бас, ар-н-би, техно белән мавыга башлады. Ул бөтен җирдә – мәйданчыкларда, клубларда, колакчыннарда яңгырый иде. Әмма ахыр чиктә текстсыз, текстлары булган очракта да, мәгънәсез авыр ритмнар халыкны туйдырды. Шулвакытта 80 нче еллар дискотекасы икенче мәртәбә популярлык алды. Бу 1996 елга туры килә, мин эшләгән «Азия» һәм «Шерше ля фам» төнге клубларында башланды. Анда без пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә рус музыкасы уйната идек.

2001 елда мин Мәскәүгә киттем. Төрле мәйданчыкларда өч ел эшләп, Леша Щукин («Комиссар» төркеме), Наталья Гулькина, Александр Айвазов белән мин бу концертларны алып бардым һәм 80 нче еллар стиленнән беркая да тайпылмадым. Казанга әйләнеп кайткач, кабат күңелгә якын музыканы яңгыыратырга булдым. Иң башта 80 нче еллар өчен «изге» урынны – «Идел» лагерендагы мәйданчыкны яңартырга ниятләдем, анда ул чактагы иң яхшы төркемнәр чыгыш ясый иде. Ул чорда тагын бер танылган мәйданчык – Яшьләр үзәге бар иде. Анда без зур зал фойесында, өстәлләр куеп, программа эшләдек. Бу да һәркемнең күңеленә хуш килде – барысы да әлеге чорны сагына иде!

Бер елдан соң инде мин КТҮ (ЦКЖ) гә күчтем, һәм анда без дүрт сезон рәттән чын хитлар яңгыраттык. Җырбию, такмаклар белән мин ике сәгать буе халыкны үземә каратып тота идем. Бу мәйданчык стадион эффекты булдыру мөмкинлеген бирә – залның бер башында сызгырсаң, кайтавазы икенче ягыннан әйләнеп килә. 2004–2005 елларда без «Шүрәле» паркында ике ай буе атнасына өчәр көн 80 нче еллар дискотекасын гөрләттек.

– Ул музыканың бүгенге хитлардан аермасы нидә?

– Аларның мелодикасы үзенчәлекле, ә хәзер үз йөзе булмаган җырлар бик күп. Әлбәттә, ул чакта да кабатлаулар, «Модерн токинг», Си Си Кетчтан үзләштерүләр бар иде. Кайвакыт радиодан башта хәтта аңлашылмый да, «Мираж» җырлыймы анда, әллә нинди дә булса Көнбатыш музыкасы яңгырыймы. Әмма элегрәк текстларда мәгънә бар иде. Әшәкелек, рухи шакшылык юк, романтика бар иде.

– 80 нче еллардагы Казан шоу-бизнесының үзенчәлекләре нинди?

– Ул чакта бераз рокка таба юнәлгән иде ул. Нindидер мәгънәдә без Казан шоу-бизнесының ыру башы булганбыздыр – дискотекаларга беренче булып үзебезнең рок-группаларны чыгардык. Аннары Свердловскидан, Мәскәүдән, Питердан төркемнәр чакырдык: «Чайф», «Настя», «Урфин Джюс» һ.б.

Әкренләп минем исемдәге продюсерлык үзәге булдырдык. 90 нчы еллар башында «Teen Star – Юная звезда» фестивален оештырдык, аны хәзер «Созвездие-Йолдызлыкка» әйләндерделәр. Миндә «Макс и компания» – ул чакта әле «Холи» төркеме, мәктәп балаларының «НЗ» төркеме – хәзерге «Волга-Волга», ул вакытта тугызынчы сыйныфта укыган Марина Максимова, һәм «Принцесса» төркеменнән хәзер инде вафат булган Дима Комаров җырлый иде.

– Ә Казан публикасының үзенчәлеге бар идеме?

– Әлбәттә, «Казан феномены» шәһәребезгә начар реклама булды. Әмма дискотекаларда эшләү чыннан да катлаулы иде. Ул чакта без Төзүчеләр мәдәният сарае мәйданчыгында беренче тапкыр ОМОН күрдек. Элегрәк шундый бүлекчә барын ишетеп кенә белә идек... Алар бронемашинада һәм каскалар кигән иде, чөнки безгә дискотекага «Караваево» үсмерләре килде. Аларның Совет районынныкылар белән сугышырга җыенганын миңа Эчке эшләр идарәсе башлыгы әйтте. Бернәрсәдән дә курыкма, дискотеканы тыныч кына алып бар, биет үзләрен, диде. Һәм алар ОМОН килгәнче биеде дә. Чукмарлары белән шакып, калканнарын алга сузып, «кунаклар» үсмерләр төркемен ике өлешкә бүлде һәм «Каравайныкыларны» җәяү трамвайга кадәр озатып куйды. Алар утырып киткәнче, безнекеләр мәйданчыкта биеде.

Гомумән алганда, ул чакларда диск-жокей, бигрәк тә алып баручы, сәер нәрсә иде. Хәер, эш хакы да бик аз иде, кайвакыт акча очны-очка ялгарга да җитми. Без гопниклар белән дус идек. Алар үз акчаларына миңа бер шешә сөт, бер бөтен икмәк, эретелгән сыр яки томат соусындагы килька консервасы алып бирә, аннары янәшәмдә утырып, ашап бетергәнче янымa беркемне дә китермичә, саклап тора иделәр.

– 80 нче еллар карап торышка нинди иде?

– Соры төркем. Без, артистлар, буйбуйлы, шакмаклы, кызыл, зәңгәр яки башка җете төстәге киемнән. Күн кепка, киң ак күлмәк, көндез ут яндырып эзләсәң дә табып булмый торган»казаки» ботинкасы. Зур кроссовкиларның, тагын да зуррак күренсен өчен, шнурларын буш кына бәйлисең. Төп масса исә соры иде. Алар зәңгәрле-яшелле олимпийкалардан һәм лампаслы чалбардан булса да, безнең өчен барыбер төссез тоела иде. 200 әр кешелек «тартма» булып биегән һәм урам буйлап монтировка күтәреп йөргән соры масса. Аларның барысының да «прощайкалары» да бертөсле, чәчләре дә бертөрле кырылган иде.

– Тоташ дефицит һәм чикләнгән бюджет чорында ни рәвешле бәйрәм ясый ала идегез соң?

– Мин, күңеллерәк булсын өчен, һәрвакыт нинди дә булса фишкалар уйлап табарга тырыша идем. Бервакыт спорт товарлары кибетеннән бик күп кечкенә сыбызгы сатып алдым да, дискотекада тараттым. Рәхәтләнеп сызгырдылар. Иртән мине мәдәният йорты директоры чакыртып ачуланды: минем дискотекага килүчеләр бөтен районга төн буе йокларга бирмәгән икән!

Хәлдән килгәнчә кыландык инде, «махсус эффектлар» да ясый идек. Глобуска фольга ябыштырып, дискотека өчен көзгеле шар әмәлләдек. Танышлар аша «мигалкалар» юнәттек: сусиптергеч машиналардан – кызылны, милиция машиналарыннан – зәңгәрне. Мин әле тагын үзем сабын куыклары очыра торган җайланмалар да ясадым.

Безнең ничек итеп төтен чыгаруыбыз исә – аерым бер тарих. Төтен машинасы ясадык. Электр плитәсенең спираленә бер тапкыр кулланылышлы металл тәлинкә куясың да, шуңа аммоний хлориды саласың. Ул эри. Зал зәһәр куе төтен белән тула. Аны ничек булса да тарату өчен, артта вентиляторлар тора, тәмсез исен бетерү өчен, әлеге кушылмага хушбуй өсти идек. Ярыйсы гына килеп чыга.

80 нче еллар һәркемнең үзенеке иде шул. Өлкәнрәк дусларны Әфганстанга җибәрделәр. Мин үземнең Саранск шәһәренә кайтам да, дусларым белән рәхәтләнеп сөйләшәсе урынга, аларның каберләре янында аптырап йөри идем. Әмма, тулаем алганда, бу барыбер күңелле чаклар иде. Киләчәк тормыш, пенсия нинди булыр дип уйланмыйча, рәхәтләнеп яшәдек. Күңелле яши һәм бергәләп җырлый идек: «Наступает ночь, зовет и манит, чувства новые тая». Төн чыннан да яңа хисләргә бай була, аннары яңа көн туа, һәм без шул көн белән генә яши идек. Яңа хит чыгар, без аны бу җомгада дискотекада уйнатырбыз, дип көтә идек. Һәм моның үз рәхәтлеге бар иде. Мин 80 нче елларга рәхмәтлемен.

80 нче еллар афишасы

DEEP PURPLE УРЫНЫНА «КАРА КАҺВӘ»

Совет чорында күренекле булган «Черный кофе» металл-төркеме үзенең беренче концертын 1984 елда бирә. Озакламый СССРның Мәдәният министрлыгы аны «кара исемлек»кә кертә, ә бу исә бик күп «өметсез» дип исәпләнгән мәдәният әһелләре өчен үзенә күрә бер сыйфат билгесе дигән сүз була. Алаймы-түгелме, һәрхәлдә, Казанның Спорт сараенда узган концертларына зал тутырып килә халык. Һәм менә сәхнәгә ул чор өчен гадәти булмаган музыкантлар чыга – күн һәм джинсы киемнәрдән, ябык гәүдәле, тузган башлы егетләр. Аларның сәхнәгә ни рәвешле бизәнеп чыгуын күрүгә кайбер казанлылар канәгатьсезлек белдерә. Шундый макияж буламы? Егетләргә нинди генә сүзләр әйтеп кычкырмыйлар – концерт башланып, берничә минут үткәнче җирле бандитлар металлистларга традицион булмаган сексуаль ориентация дип, яла ягып өлгерәләр. Аларга җавап көтелмәгәнчә була: Британиянең легендар төркеме Deep Purpleның «Lady Luck» җырын башкаруга зал аягүрә баса, хәтта теләсә нәрсә кычкыручылар да битараф кала алмый. Башкача музыкантларга яман сүзләр әйтүче калмый. «Чын рокерлар!» – Казан аларны шулай дип хәтерләп кала.

НАРАЯМА ТУРЫНДА РИВАЯТЬ ЯКИ БУЛМАГАН ҖИРДӘ СЕКС

«СССРда секс юк!» дигән канатлы гыйбарә кемнең исендә юк? 1988 елда проблема хәл ителә. Үзгәреш җиле көтелмәгән яктан исә башлый – Кояш беренче булып чыга торган илдән. 36 нчы Халыкара Канн кинофестивалендә «Алтын пальма ботагы»на ия булган «Нараяма турында риваять» нәфис фильмы совет кешеләренең күзләрен ача. Сүз уңаеннан, ул елны фестивальдә Тарковскийның «Ностальгия»се дә катнаша. «Нараяма турында риваять» премьерасы СССРга биш елга диярлек соңарып килеп җитә, әмма ул вакытта моңа берәүнең дә эче пошмый. Казанда ул «Родина» кинотеатрында күрсәтелә – сеанска билет табу мөмкин түгел дирлек! Соңгы сеанс төн уртасы узгач кына тәмамлануга карамастан, «артык билет булмасмы» дип теләнүче билетсызлар төркеме иртәнге бишкә үк килә – беренче сеанс әнә шул вакытта үк башлана. Залда алма төшәр урын да калмый. Дөресен генә әйткәндә, кинонуң сюжеты әллә ни кызыксындырмый, күбесе мәгълүм эпизодны көтә. Сорау: авторлык хокуклары турында белмәгән совет цензорлары мондый урыннарны ничек кисми калдырды икән? Күрәсең, ул өлеше дә япон хезмәтчәннәренең авыр тормышының бер якты эпизоды булгандыр инде...



НЕМЕЦЧА РОК ҺӘМ ЯҢА ЯҢГЫРАШ

Әлеге концерт 1980 еллар меломаннарының хәтеренә, мөгаен, иң сыйфатлы яңгырашы белән уелып калгандыр. ГДРдан килгән VIR рок-төркеме музыкантлары Казанга үзләре белән тау кадәр аппаратура алып килә! Нәтиҗәдә, Спорт сараеның ян яклары буйлап тавыш көчәйтүче һәм башка аваз «хәзинәләре»ннән пирамидалар үсеп чыга. Немецлар берничә концерт бирә, һәм һәркайсы аншлаг белән үтә – кайберәүләр хәтта барысын да тамаша кылу мөмкинлеген таба. «Чит ил» яңгырашын гына ишетергә булсын! Немецларны яратып калалар. Ә менә советларның җылы мөнәсәбәтен музыкантлар үзләре тоя алгандырмы – моны бүген берәү дә әйтә алмый инде. Европа публикасыннан аермалы буларак, безнең тамашачылар рок-концерт буена кымшанмыйча да урыннарында утыра. Рокерлар алар белән турыдан-туры аралаша да алмый кала: «Голубой огонек» традицияләре буенча «ГДРдан килгән кадерле кунаклар» белән конферансье таныштыра.

«ЗЕМЛЯНЕ» «МАРАТТА» КУНАКТА

Сиксәненче еллар уртасында бик популяр булган «Земляне» төркеменең 1986–1988 елларда Татар дәүләт филармониясе составында торуын бик азлар гына беләдер әле. «Земляне»-нең исемлеге ул вакытта 39 пунктка җитә, башында күренекле Владимир Киселев тора – барабанчы, ВИАның сәнгать җитәкчесе һәм администраторы. Ул вакытта коллектив аена утыз аншлаг концерт бирә, шуның бер өлеше Казан залына да туры килә. Музыкантларга моның ни файдасы булган соң? Шактый зур дип әйтергә кирәк: хезмәт хакыннан тыш, филармония аларның костюмнарын тектерүне үз өстенә алган, хәтта аппаратура да аның балансында торган. Ул елларда Татар дәүләт филармониясенең җитәкчесе легендар Марат Таҗетдинов була.Нәкъ менә ул Казанда «Машина времени», Алла Пугачева, Геннадий Хазанов, Владимир Высоцкий, Михаил Жванецкий һәм, әлбәттә инде, «Земляне» концертларын оештыра. Бу йолдызларның барысы да «Казанга, Маратка» килә, Таҗетдиновның шәхесе уникаль була – аның белән дуслашмый мөмкин түгел. «Земляне» төркеменең Казандагы концертлары һәрвакыт аншлаг белән үтә! Гадәттә, тыйнак кына утырып, концерт караган совет публикасы «Земляне» ритмнарына, торып, бии башлый торган була.

ЕВГЕНИЙ ЕВТУШЕНКО ҺӘМ АНЫҢ КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЛАРЫ

«Урыннар юк!», – дип кычкырып җибәрә «Волга» кунакханәсенең йокылы-уяулы утырган дежурные, ишек катында чандыр гәүдәле озын ир-атны күрүгә. Җавап итеп, шигырь юллары белән әйтелгән көлкеле сүз ишетә. «Сез чирлеме, шагыйрьме?» – дип сорый аннан соң, ачуы килеп. «Әйе, әлбәттә, шагыйрь мин!» «Евтушенко дип әйт инде!» «Әлбәттә!» – дип, паспортын суза төнге кунак. Аңа дигән номер шунда ук табылуы турында әйтеп торырга кирәкмидер инде. Казанга Евтушенконың үзгә мәхәббәт була. Ике яклы, билгеле. Сиксәненче елларда ул Казанга ике тапкыр килә. 1984 елда тарихи актлар залында беренче тапкыр аның «Әни һәм нейтрон бомба»сы яңгырый, ә 1987 елда ул Спорт сараенда һәм Ленин исемендәге Мәдәният йортында чыгыш ясый.

1000 СУМГА НӘРСӘ АЛЫРГА БУЛА?

...1980 нче елларда:

- 200 шешә «Советское» шампан шәрабе
- яисә базарда 200 кг сыер ите
- яисә социалистик илләргә ике путевка (ике атнага: юл, отельдә яшәү чыгымнары, экскурсияләр, трансфер)
- яисә «Иж-Планета» мотоциклы
- «Горизонт» төсле телевизоры, 61 см диагональле (730 сум тора, дефицит)

РФ буенча уртача хезмәт хакы (1980 нче еллар уртасы мәгълүматы)
180 сум

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ

ТАТАРСТАН КОММУНИСТЫ

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ
ТЕОРЕТИК ҺӘМ ПОЛИТИК ЖУРНАЛЫ

1920 елның декабреннән бирле чыга

3
(677)
1989
МАРТ

АЙГА БЕР ТАПКЫР
ТАТАР ҺӘМ РУС
ТЕЛЛӘРЕНДӘ
БАСЫЛА

КАЗАН

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ
НӘШРИЯТЫ

ЭЧТӘЛЕК

К. ГЫЙЗЗӘТОВ. Милләтара мөнәсәбәтләр үзгәртеп кору призмасы аша 3
Интернационализм принципларында 9
А. КӘРИМОВ. Сайлау системасын радикаль яңарту 12

М. АГАФОНОВА. Сайлаулар альтернативалы булмаска мөмкинме? 17

ЭКОНОМИКА — ҮЗГӘРТЕП КОРУНЫҢ НИГЕЗЕ
Ю. ЛЮБИМОВ. Алга бару җиңел түгел 22

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ: ЯҢАЧА ФИКЕР ЙӨРТЕРГӘ ҺӘМ ЭШЛӘРГӘ
Партия комитеты: эзләнүләр чоры. «Түгәрәк өстәл» 28

ИДЕОЛОГИЯ ЭШЕ: НӘТИҖӘЛЕЛЕК ҺӘМ СЫЙФАТ
В. ШЕВЧУК. Мөстәкыйльлек плюс ышаныч 37
Р. ГУРЬЯНОВА. Аеклык мәктәбе 43

ПОЛИТИК ҺӘМ ЭКОНОМИК УКУ СИСТЕМАСЫНА ЯРДӘМГӘ
Н. ЗАХАРОВ. Советларның тулы властьлылыгы — социалистик дәүләтчелекнең һәм халык үзидарәсенең нигезе 45

ФӘН ҺӘМ МӘГАРИФ
Р. ӘДҺӘМОВ. Вуз фәнен — хуҗалык исәбе рельсларына 50
Статистика теле белән 56

ТАССРның 100 еллыгына багышлана

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ

Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!

ТАТАРСТАН КОММУНИСТЫ

3
1989